3 ◦ 2016

# ФӘННИ ТАТАРСТАН



ISSN 2499-9741

КАЗАН

***Журнал «2014 — 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән,
мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ФӘТТАХОВ Э.Н., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары —
мәгариф һәм фән министры (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**

КИМ МӨГАЛЛИМ улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ДӘҮЛӘТШИНА Л.Ш. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХАЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты)

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

Я.М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Е.Ф. ЛУКЬЯНЧЕНКО

**БУ САНДА**


**ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНӘ – 25**

*Саләхов М.Х.* Татарстан Фәннәр академиясе: үткәннән – киләчәккә! . 7

**ТЕЛ БЕЛЕМЕ**

*Йосыпов Р.Г.* Татар һәм рус телләре фразеологизмнарының үзара нисбәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12

*Ибраһимов Т.И., Сәйхунов М.Р.* Хәзерге татар сөйләм теле: сузык авазлар составы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35

*Хәкимов Б.Э.* Татар тел белемендә корпус технологияләрен куллану . 48

**ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ**

*Әхмәдуллин А.Г.* Үзенчәлекле пьесалар *(Эсфир Яһудин драматургиясе хакында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52

*Каюмова Г.И.* Курчаклар уенында – кешеләр язмышы... *(«Курчак туе» һәм «Кәләпүшче кыз» әсәрләренә чагыштырма анализ)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58

*Мотыйгуллин Җ.Н., Мотыйгуллина М.Җ.* Г.М. Тукайның «Яшьләр» һәм М.Ю. Лермонтовның «Дума» әсәрләрендә яшь буын . . . . 68

**ХАЛЫК ИҖАТЫ**

*Дәүләтшина Л.Х.* Татар мифологиясен өйрәнү юлында . . . . . 76

**ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ**

*Беккин И.Р.* Бер дуслык тарихы: Г. Баязитов һәм В.С. Соловьев . 88

**МИЛЛИ МӘГАРИФ**

*Мортазина Л.Р.* Мөхәммәтхан Фазлуллинның (1883–1964) фәнни-педагогик эшчәнлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105

**ТӨГӘЛ ФӘННӘР**

*Галимҗанов Ә.Ф., Гыйлемҗанов А.Ф., Миңнегалиева Ч.Б.* Махсус интерполяцион полиномиаль оператор нигезендә төзелгән квадратур формулалар . . . . . . . . . . . . . . . . 111

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙГА – 130**

*Миңнуллин К.М.* Тукайны өйрәнү фәне: үткәне, бүгенге казанышларыбыз, киләчәк хакында уйланулар . . . . . . . . . 122

*Галиева Р.М.* «Ватаным Татарстан» газетасында Г. Тукай темасының куелышын өйрәнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

*Абзалина Р.Ә.* Тукайның иҗади васыяте . . . . . . . . . . . . . . 135

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Закирова И.Г.* Татар фольклорының Урманче мәктәбе . . . . . 140

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Халык җәүһәрләреннән якты алып... *(Күренекле тюрколог, фольклорчы галим Фатих Урманчега – 80 яшь)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

**ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР**

*Ризаэддин Фәхреддин.* Көтебе ситтә . . . . . . . . . . . . . . . . 149

**СӘНГАТЬ**

*Шкляева Л.М.* Урта Идел буе татарларының агачка рәсем төшерү сәнгате үсешенең тарихи-мәдәни этаплары . . . . . . . 160

*Герасимова Н.В.* 1920 елларда Татарстанның кантон (район) музейларындагы сәнгати коллекцияләрнең торышы (ТАССР мәгариф халык комиссариаты (ТНК) Академүзәге музей комиссияләре анкетасы буенча) . . . . . . . . . . . . . . 169

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Заһидуллин И.К.* Киләчәккә үсеш юлларын билгеләп (җиде томлык «Бик борынгы заманнан башлап татар тарихы» басылып бетү уңаеннан) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

*Ахунов А.М.* Мөселман Петербургына сәяхәт . . . . . . . . . . . 180

## В НОМЕРЕ

### АКАДЕМИИ НАУК ТАТАРСТАНА – 25

*Салахов М.Х.* Академия наук Татарстана: от прошлого к будущему! . 7

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Юсупов Р.А.* Соотношение татарских и русских фразеологизмов . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
*Ибрагимов Т.И., Сайхунов М.Р.* Современный татарский разговорный язык: состав гласных звуков. . . . . . . . . . . . 35
*Хакимов Б.Э.* Корпусные технологии в татарском языкознании . 48

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Ахмадуллин А.Г.* Своеобразные пьесы *(драматургия Эсфира Ягудина)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
*Каюмова Г.И.* Кукольные игры – человеческие судьбы *(сравнительный анализ произведений «Курчак туе» и «Кәләпүшче кыз»)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
*Мотигуллин Дж.Н., Мотигуллина М.Дж.* Молодое поколение в произведениях Г.М. Тукая «Яшьләр» и М.Ю. Лермонтова «Дума» . 68

### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Давлетшина Л.Х.* На пути исследования татарской мифологии . 76

### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Беккин И.Р.* История одной дружбы: А. Баязитов и В.С. Соловьев . 88

### НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Муртазина Л.Р.* Научно-педагогическая деятельность Мухамметхана Фазлуллина (1883–1964) . . . . . . . . . . . . 105

### ТОЧНЫЕ НАУКИ

*Галимзянов Ә.Ф., Гилемзянов А.Ф., Миннегалиева Ч.Б.* Квадратурные формулы на основе специального интерполяционного полиномиального оператора . . . . . . . . . 111

### АБДУЛЛЕ ТУКАЮ – 130

*Миннуллин К.М.* Тукаеведение: прошлое, современные достижения, размышления о будущем . . . . . . . . . . . . . 122
*Галиева Р.М.* Тема Г. Тукая на страницах газеты «Ватаным Татарстан» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
*Абзалина Р.А.* Творческое завещание Тукая . . . . . . . . . . . . . 135

### ПЕРСОНАЛИИ

*Закирова И.Г.* Школа Ф. Урманче в татарской фольклористике . 140
*Мухаметзянова Л.Х.* Озаряясь светом народной мудрости... *(знаменитому тюркологу, фольклористу Фатиху Урманче – 80 лет)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

**НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ**

*Ризаэддин Фәхреддин.* Көтебе ситтә . . . . . . . . . . . . . . . 149

**ИСКУССТВО**

*Шкляева Л.М.* Историко-культурные этапы развития искусства резьбы по дереву татар Среднего Поволжья . . . . . . 160

*Герасимова Н.В.* Состояние художественных коллекций кантонных (районных) музеев Татарстана 1920-х гг. (по анкетам музейной комиссии Академцентра ТНКТ) . . . . . . 169

**НОВЫЕ КНИГИ**

*Загидуллин И.К.* Определяя перспективные пути развития (к завершению издания «Истории татар с древнейших времен» в 7 томах) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

*Ахунов А.М.* Северная Пальмира в лицах и событиях: неспешные прогулки по мусульманскому Петербургу . . . . . . 180

*М.Х. Саләхов,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты*

## ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ: ҮТКӘННӘН – КИЛӘЧӘККӘ!

Бүген, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе оешуга 25 ел вакыт узганнан соң, Татарстан җитәкчелегенең республика күләмендә фәнни эшчәнлекне җәелдерә, фәнни гыйлемнәрнең өстенлекле юнәлешләре буенча тикшеренүләр алып бара торган интеллектуаль үзәк ачу карарының никадәр дөрес булганлыгы аеруча ачык күренә. Чыннан да, күпчелек алдынгы дәүләтләр фәнни өлкәдә оештыру эшләрен, төпле тикшеренүләргә ярдәмне нәкъ менә милли академияләр аша хәл итә. Өметле фәнни эшләрдә фундаменталь гыйлемнәрсез алга таба адым атлау мөмкин түгел: икътисадта булсынмы, социаль өлкәдәме – киләчәккә юл ача торган технологияләрнең нигезендә торган яңа белемнәр белән бары ул гына тәэмин итә ала.

Татарстан Фәннәр академиясенең нинди шартларда формалашуын искә төшерү зарур. 1990 еллардагы система кризисы вакытында гамәли һәм тармак фәне зур югалтуларга дучар булды. Академик төзелешнең тотрыклылыгы фундаменталь гыйлемнәрне саклап калырга ярдәм итте. Татарстан Президенты М.Ш. Шәймиевнең 1991 елның 30 сентябрендәге Указы нигезендә «үзебезнең» Фәннәр академиясен төзү шулай ук фундаменталь белемнәрнең дәрәҗәсен күтәрүгә, социаль-икътисади һәм рухи тормышта аларның ролен көчәйтүгә юнәлтелгән иде.

Татарстан озак вакытлар дәвамында булдырылган фәнни базаны саклау юлын Академия төзүдә күрде. Аның үрнәгенә берничә милли республика ярде, Башкортстан, Саха (Якутия) һәм башка республикаларда шулай ук Фәннәр академияләре төзелде. Аларның һәркайсы үз төбәгендә фәнни фикерне саклауга һәм тагын да көчәйтүгә хезмәт итте. Үзенең Академиясен булдыру Татарстанның милли-дәүләти статусын күтәрүдә зур роль башкарды, республиканың Россия Федерациясе составындагы мөстәкыйльлеге фикерен тормышка ашарлык эчтәлек белән баетты. Бүгенге көндә Фәннәр академиясе Татарстан Республикасының якты символларыннан берсе булып тора.

Безнең республикада Академия күренекле фәнни мәктәпләрне саклауда, фәнни-техник дәрәҗәне ныгытуда, фәнни җәмәгатьчелекне бергә туплауда, фән һәм техника үсешенең әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итүдә, фәнни оешмаларны, югары уку йортларын һәм предприятиеләрне берләштерүдә хәлиткеч роль уйный. Ул фән һәм техника өлкәсендә республика сәясәтен оештыруда һәм тормышка ашыруда җаваплы үзәкләрнең берсенә әйләнде.

Академиянең фәнни активлыгын кырыктан артык чит ил һәм Россия Федерациясе төбәкләрендәге фәнни оешмалар белән багланышлар булдырылуы дәлилли. Академия халыкара һәм чит ил фәнни үзәкләре белән бергә уртак проектларны гамәлгә ашыруга кереште. Бу аеруча мөһим күренеш, чөнки Татарстанны чын мәгънәсендә төрки һәм ислам дөньясы белән Россия арасындагы «капка» дип атарга мөмкин. Татарстан Көнбатыш һәм Көнчыгыш тоташкан урында тотрыклы үсешкә мисал булып тора, Академиянең гуманитар фән вәкилләре татар халкының мәдәниятен, тарихын һәм менталитетын өйрәнү юнәлешендә шактый эш башкарды.

Академиянең үсеш чоры күренекле галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе М.Х. Хәсәнов җитәкчелегендә узды. Җитәкчелек дилбегәсе аның кулында чакта татар халкының милли мәдәниятен һәм Татарстан халыкларының мәдәни-тарихи мирасын төрле яклап өйрәнү мәсьәләсе күтәрелде. Мансур Хәсән улы 1990 елларда үзе үк нигезләгән Татар энциклопедиясе институтын җитәкләде. Әлеге фәнни оешма бүгенге көндә күп томлы «Татар энциклопедия»сен әзерләде. Асылда, әлеге хезмәт Татарстанда мәдәниятнең тарихи үсешен, фән һәм мәгариф өлкәсенең төп үзенчәлеген чагылдыра.

Мөһим мәсьәләләрне шулай ук нефть һәм газ эшкәртү, нефть чистарту технологиясе барышлары, газ һәм нефть матдәләрен күкертле кушылмалардан арындыру өлкәсендәге галим Әхмәт Мазһар улы Мазһаровка хәл итәргә туры килде.

Бүгенге көндә Фәннәр академиясенә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, «Гамәли семиотика»институты, Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты, Икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге, Ислами тикшеренүләр һәм башка фәнни үзәкләр керә. Академиядә барлыгы 412 кеше хезмәт куя, шулардан фәнни хезмәткәрләр саны– 305 (74%), 46 сы фән докторы булса (15%), 138 е (45%) – фән кандидаты.

Академия үз эчендә 40 хакыйкый, 80 мөхбир, 29 шәрәфле һәм 14 чит ил әгъзасын берләштерә. Академиянең күпчелек әгъзалары федераль уку йортларын, фәнни-җитештерү оешмаларын җитәкли, шулай ук фән, технология һәм техника үсешенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләүчеләр булып тора. Алар – академик фикер белән гамәлне республиканың фәнни-сәнәгать, мәгариф һәм социаль-мәдәни өлкәләренә күчерүчеләр, академик, тармак институты һәм югары уку йортларында уздырыла торган фәнни-тикшеренү эшләрен оештыручылар, ТР Министрлар Кабинеты йөкләмәләре нигезендә Татарстанның ике дистәләп фәнни оешмасында фәнни-методик эшкә җитәкчелек итүчеләр.

Республикадагы фәнни тормышның барлык өлкәләре дә берберсе белән тыгыз багланышта

булганлыктан, институтлар һәм Академия бүлекләре, югары уку йорты һәм академик фән арасындагы аерманы ачык билгеләү мөмкин түгел сыман. Академиянең төп максаты да шул инде – республикадагы барлык фәнни оешма коллективларын үзара килештереп, яраклаштырып эшләү.

Фәнни тикшеренү бурычларын башкарып, конференцияләр уздыруга, хезмәтләрне бастырып чыгаруга ярдәм итә торган төрле республика программаларында катнашып, Академия үзенең нәтиҗәле эшли торган фәнни-тикшеренү үзәге икәнлеген раслап килә.

Академиянең ике фәнни советы, Хөкүмәт карары нигезендә, фәнни-сәнәгать комплексы үсешенә, матди һәм рухи мәсьәләләргә кагылышлы республиканың эре проектларына тикшерү уздыра. Академия шулай ук җирле грант сәясәтен алып бара, ел саен яшь тикшеренүчеләр өчен грант һәм республика фәнни премияләренә конкурслар уздыра. Татарстан Республикасы Президенты фәрманы нигезендә 2015 елда беренче тапкыр инженер фәннәре өлкәсендә эшләгән яшь галимнәр өчен булдырылган А.Н. Туполев исемендәге Халыкара һәм В.Е. Алемасов исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе тапшырылды.

Тикшеренү, тикшерү һәм оештырудан тыш, Академия ТР Дәүләт бүләкләре тапшыру Комитеты вазифасын башкара, «Фәндәге казанышлар өчен» алтын һәм көмеш медальләре,тугыз исемдә премия булдырды, кадрлар әзерләү буенча 18 аспирант белгечлегендә катнаша, Фән һәм мәгариф министрлыгы, Инвестиция-венчур фонды белән берлектә ел да «Татарстан Республикасы өчен илле иң яхшы инновацияле идея» конкурсын оештыра.

Мәдәни-мәгърифәтчелек үзәге буларак, Татарстан халыкларының тарихи-мәдәни мирасын һәм фәне казанышларын пропагандалый, җирле төбәкне өйрәнү музейларына фәнни-методик ярдәм күрсәтә. Алар арасында ТР Археология музее, Зөя утраушәһәрлегендәге «Татар бистәсе» музее һ.б.лар бар.

Хәзерге чор исә Фәннәр академиясенең 2020 елга Стратегик үсешен гамәлгә ашыру белән бәйле. Ул 2015 елның 24 декабрендә Академиянең гомуми җыелышында кабул ителде.

Академиянең стратегиясе республикадагы фәнни тикшеренүләрнең үсеш юнәлешен һәм хәзерге халәтен тикшерүгә таяна. Аның төп үзенчәлеге шунда – ул Татарстан Республикасының 2030 елга кадәрге социаль-икътисади үсеш стратегиясе бурычларына йөз тота.

Безнең Стратегия Татарстан Республикасы максатларына яраклашкан мегапроектларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән. Академия инде бүген «Татар халкының милли бердәмлеген саклау (2014–2016 еллар)», «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «2014–2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка

ашыру» дәүләт программаларында катнаша. Ул исә өлгергән фәнни проблемаларны, министрлык һәм идарәчелекнең гамәли йөкләмәләрен, төпле тикшеренүләрне хәл итүдә таяныч булып тора.

Академия стратегиясенең төп максаты булып республикадагы фәнни көчнеберләштерү һәм аны җитештерүгә, икътисадның инновацияле тармагына юнәлтү, заманга ярашлы фәнни система буларак үстерү, яшь буынны ватанпәрвәрлек, югары әхлаклылык һәм гражданлык җаваплылыгы хисе белән тәрбияләү тора. Шулардан чыгып фәнни өстенлекләр билгеләнә. Кайбер төпле һәм гамәли тикшеренүләр – татар халкының теле, тарихы һәм мәдәнияте темасы; ТР Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре; татар халкының һәм республикадагы халыкларның тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү, саклау һәм аны дөньяга таныту; нефть табу, нефть чистарту һәм нефтехимия; Татарстандагы социаль-икътисади барышларны өйрәнү темасы – берничә дистә еллар дәвамында уңышлы үсеш кичерә.

Әлеге юнәлешләр буенча төпле фәнни тикшеренүләр уздырылды, югары квалификацияле иҗади коллективлар оешты. Экология мәсьәләләрен өйрәнүдә тәҗрибә тупланды, нефть табу, чистарту һәм нефтехимия өлкәсендәге фәнни-тикшеренү эшчәнлеге республиканы алдынгы төбәкләр рәтенә чыгарды.

Экология өлкәсендә «Нефть һәм җир», «Чиста һава», «Чиста су», «Аеруча саклана торган табигый территорияләр» кебек проектларны гамәлгә ашыру, табигый һәм шәһәрләшкән территорияләрдәге төбәкара табигый байлыклардан файдаланугагадел бәя бирә торган яңа фәнни-җитештерү проблемаларын эшләү киләчәктә мөһим бурычларны хәл итүгә илтәчәк.

Иҗтимагый тикшеренүләр өлкәсендә Идел-Кама, Кырым, Алтай, Түбән Идел буе халыкларының матди, рухи, этник тарихын һәм мәдәниятен торгызу буенча комплекслы масштаблы фәнни чаралар ниятләнелә. «Мирасханә» язма һәм музыкаль мирас фондындагы материалларны тирәнтен өйрәнү өчен Академия һәм республиканың башка мәгариф учреждениеләре көче белән яңа мөмкинлекләр ачыла. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларының бердәм исемлеген булдыру уйланыла, Идел буе һәм Урал алды төбәгендә эпиграфика истәлекләрен өйрәнү буенча зур масштаблы проект башланып китте. Әлеге мегапроектларның һәммәсе дә академик институтларның алдагы бишьеллык планына кертелгән, Академия бүлекчәләренең өстәмә тәкъдимнәре исемлегенә өстәлгән.

Академия шулай ук Татарстан һәм татар халкы читтә тупланып яшәгән урыннарда социомәдәни һәм тарихи мирас, республикадагы милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр, исламны өйрәнү кебек өметле фәнни юнәлешләрне үстерергә ниятли.

Социогуманитар тикшеренүләр күренекле урын алып торган академиябез өчен иң бе-

ренче чиратта күпмилләтле һәм поликонфессиональ Татарстанның мәдәният, тел һәм тарих проблемаларын эшләү мөһим.

Иҗтимагый фәннәр белән бертигез дәрҗәдә табигать фәннәре өлкәсендә дә тикшеренүләр алып барылачак. «Стратегия-2030» кагыйдәнамәсе нигезендә республика җитәкчелеге Академияне югары уку йортлары һәм фәнни-сәнәгать комплексының төп фәнни компанияләре, аеруча нефть һәм газ тармагындагы оешмалар белән уртак эшләргә йөз тотарга чакыра. «Татнефть» компаниясе белән берлектә геология, нефть табу һәм эшкәртү өлкәсендә 2015–2025 елларга өстенлекле фәнни тикшеренүләр програмасы эшләнде. «Татнефть» ААҖ тарафыннан финансланган әлеге программаны Академия җитәкчелегендә республиканың фәнни оешмалары эшләячәк.

Перспективалы эзләнүләр институты үзе өчен яңа булган юнәлешкә – нефть белән газ секторының фәнни-техник проблемаларын хәл итүгә кереште. Шуңа да бу юнәлешкә без аеруча игътибар бирәбез, икътисадта кулланыла торган тармаклы тикшеренүләрнең даими үсешенә омтылабыз.

Мәгълүм булганча, нефть табу белән эшкәртү тирә-як өчен билгеле бер күләмдә хәвеф-хәтәр дә тудыра. Шул сәбәпле ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы йөкләмәсе белән Экология проблемалары институты Түбән Камада техноген тәэсирнең тискәре йогынтысын тикшерде, зарарлы матдәләрне һавага чыгара торган Чаллы һәм Түбән Каманың өч йөздән артык предприятиесенең исемлеген булдырды. Тикшеренүләрнең нәтиҗәсе табигатьне саклау чараларын нигезләү һәм шәһәр төзелеше өчен карарлар кабул иткәндә мөһим. Болардан тыш, нефть һәм нефть матдәләренең рөхсәт ителгән калдык микъдары нормативлары эшләнде. Болар Татарстанның көньяк-көнчыгыш территориясендә яңадан торгызу эшләренең сыйфатын арттыруга ярдәм итә.

Гомумән алганда, фән һәм инновацияләр өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыру катлаулы бурыч булып кала бирә. Монда мәгариф, төпле фәннәр, эшлекле секторның бердәм хәрәкәт итүе, алга баруы таләп ителә. Җирле һәм халыкара фәнни эшләнмәләр, төпле һәм гамәли фәннәр, яңа белемнәр үсеше белән коммерция эшчәнлеге арасында тигезлек табарга тырышу кебек катлаулы мәсьәләләрне хәл итү бурычы тора. Безнең илдә исә шушыларга тагын фәнни нәтиҗәләргә тиешле дәрәҗәдә ихтыяҗ булмавы да өстәлә. Әмма алар, һичшиксез, белемнәрнең инновацияле-икътисади формалашуында хәл ителәчәк.

Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе, республиканың фәнни-тикшеренү өлкәсендәге уникаль торышыннан, ягъни Академиягә тапшырылган фәнни тикшеренүләрне планлаштыру һәм фәнни инфраструктура белән җитәкчелек итүдәге өстенлекләрдән чыгып, әлеге мәсьәләләрне уңай хәл итүдә катнашырга омтыла.

УДК 811.512.145´373

*Р.Г. Йосыпов*

# ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРЫНЫҢ ҮЗАРА НИСБӘТЕ

В условиях все более развивающегося двуязычия в Республике Татарстан сопоставительное изучение фразеологизмов татарского и русского языков имеет большое теоретическое и практическое значение. В фразеологических сочетаниях наиболее ярко проявляются взаимосвязи и взаимодействие различных средств контактирующих языков. В этом отношении особенно заметно влияние русского языка на татарский, благодаря чему значительно обогатился фразеологический фонд татарского языка. Определенное воздействие на развитие фразеологизмов русского языка оказывает и татарский язык, что происходит в основном в процессе перевода произведений татарской художественной литературы.

Все эти и некоторые другие вопросы рассматриваются в данной статье.

**Ключевые слова:** соотношение, взаимосвязи, взаимодействие, татарский и русский языки, общность, особенности, фразеологизмы, перевод, развитие, двуязычие.

Фразеологик әйтелмәләр телдә гаять әһәмиятле роль уйный. Алар, гади сүз һәм сүзтезмәдән аермалы буларак, төшенчәне, фикерне сурәтле, бизәкле, тәэсирле итеп белдерәләр, димәк, коммуникатив вазифа башкарудан тыш, эстетик бурыч та үтиләр. Сүз күрке – мәкаль, ди халык. Кеше үзенең сөйләмендә мәкаль-әйтемнәрдән, фразеологик берәмлекләрдән ни дәрәҗәдә мул һәм уңышлы файдаланса, аның фикере кешеләргә шул дәрәҗәдә җиңелрәк, тизрәк һәм тәэсирлерәк барып җитә.

Фразеологизмнарда, бигрәк тә мәкаль-әйтемнәрдә, халыкның тормыш тәҗрибәсе, фикер йөртүе, милли үзенчәлекләре чагылыш таба. Шуңа күрә бу тел җәүһәрләреннән тулы һәм оста файдалану, аларны үстерү каләм ияләренең мөһим бурычларыннан санала.

Татар-рус икетеллелеге шартларында фразеологик фондның баюы, тапкыр, хикмәтле тәгъбирләрне дөрес куллану мәсьәләсе аеруча зур әһәмияткә ия.

Фразеологик әйтелмәләргә саф фразеологик әйләнмәләр (берәмлекләр, сүзтезмәләр) һәм мәкаль-әйтемнәр керә. Дөрес, алар арасында берникадәр аерма бар. Мәкаль, фразеологик берәмлектән үзгә буларак, дидактик характерда була, логик эчтәлеге белән хөкемнән гыйбарәт, формасы буенча – җөмлә (ә саф фразеологизм – сүзтезмә). Ләкин мәкаль-әйтемнәр белән фразеологизмнарның уртак сыйфатлары аермалы якларыннан күбрәк: аларның икесе дә тотрыклы, бөтен әйтелмә, гомуми мәгънәне аерым сүзләр мәгънәләренең суммасы тәшкил итми. Фразеологизмнарга да, мәкаль-әйтемнәргә дә күчерелмә мәгънәлелек

(метафоралылык), образлылык, экспрессив-тәэсирлелек (сурәтлелек-бизәклелек) хас.

Фразеологик әйтелмәләргә канатлы сүзләр белән афоризмнар да якын тора. Шуңа күрә бу мәкаләдә сүз, фразеологизм, мәкаль-әйтемнәр белән бергә, алар турында да барачак.

Фразеологик әйтелмәләрдә телләрнең үзара бәйләнеше һәм бер-берсенә тәэсир итүе нәтиҗәсендә үсеше бигрәк тә нык чагылыш таба. Татар һәм рус телләренең бер-берсенә, аеруча рус теленең татар теленә бу мәсьәләдә уңай йогынтысы зур. Татар телендә рус теле тәэсирендә ясалган бик күп фразеологизмнар кулланылышта йөри. Русчага тәрҗемә ителгән матур әдәбият әсәрләрендә татар теле чаралары үрнәгендә төзелгән фразеологик әйтелмәләр дә шактый күп.

Фразеологизмнарның бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү юлларын, бер тел чаралары өлгесендә икенче телдә яңа фразеологик әйтелмәләр ясалу ысулларын, бу процесстагы уңышлы һәм уңышсыз якларны тикшерү ике тел ияләренең сөйләм культурасын үстерү өчен әһәмиятле.

Төрле телләрнең күчерелмә мәгънәсе һәм образлылыгы үзара туры килә торган һәм, димәк, тәэсирлелек, сурәтлелек көче дә бердәй фразеологик әйтелмәләре гомуми чаралардан санала. Гомуми фразеологизмнар компонентларының (аерым сүзләрнең) төп номинатив мәгънәләре буенча тәңгәл киләләр яки бер-берсенә якын булалар. Бердәй мәгънәле, ләкин төрле образларга корылган һәм төрле мәгънә белдерә торган фразеологизмнар телләрнең специфик чараларын тәшкил итә. Специфик фразеологизмнарның аерым элементлары гадәттә төп, туры мәгънәләре буенча бер-берсенә туры килми.

Татар һәм рус телләрендә мәгънәләре һәм образлары бердәй яки якын фразеологик әйләнмәләр меңнәрчә.

Ике тел фразеологизмнарындагы мондый зур гомумилекнең ике җирлеге бар. Беренчесе – фикерләү процессындагы төп элементлар барлык халыклар өчен дә бердәм. Шул исәптән төрле халыкларның сәнгатьле фикерләвендә дә гомуми сыйфатлар күп. Тотрыклы әйләнмәләрнең иң зур күпчелеге сүзтезмә һәм җөмләләрнең күчерелмә мәгънәдә кулланылуына нигезләнгән. Бу исә кешеләр тормышындагы, аларның эшләрендәге, үз-үзләрен тотышындагы, иҗтимагый мөнәсәбәтләрдәге күренешләрне табигать күренешләренә охшатуга, чагыштыруга, шулай ук кешенең бертөрле эшләрен икенче төрләре белән, бигрәк тә физик эшләрен акыл эшләре белән чагыштыруга кайтып кала. Реаль чынбарлык, табигать күренешләре барлык халыклар өчен дә, нигездә, бердәм, һәм төрле телдә сөйләшүче кешеләрнең характерында, үз-үзләрен тотышында, мөнәсәбәтләрендә, яшәү рәвешендә уртаклыклар зур булганлыктан, боларның барысын да чагылдыра торган фразеологик әйләнмәләрдә дә гомуми сыйфатлар булмый кала алмый.

Икенче җирлек үзара мөнәсәбәттәге тел ияләренең күптәннән дәвам итеп килә торган

тыгыз бәйләнешләреннән гыйбарәт. Ул бәйләнешләр сәнгатьле фикерләүнең бердәм характерына нигезләнгән ике тел фразеологик гомумилекләренең артуына ярдәм итә.

Гомумилек барыннан да бигрәк төрле халыкларда бердәй мәгънәле тотрыклы әйтелмәләр булуда күренә. Күп кенә халыкларда, хәтта бер-берсеннән бик ерак яшәгәннәрендә дә бер үк фикер, бер үк мораль белдерә торган мәкаль-әйтемнәр бар. Һәр халыкта дуслыкка тугрылыклы булу, тату яшәү, гаделлек, тырышлык, акыллылык, батырлык, кыюлык, укымышлы, белемле булу, изгелек, ягымлылык һ.б. сыйфатларны белдерә торган образлы чаралар табарга мөмкин.

Мәсәлән, ялгыз гына уңышка ирешеп булмый, бердәмлек кирәк дигән фикер рус һәм испан телләрендә – *Бер карлыгачтан яз булмый;* татар телендә – *Бер тарыдан ботка пешми;* данияле телендә – *Бер җептән ситсы булмый;* хакас телендә – *Ялгыз агач җилдә тиз сына;* бенгаль телендә – *Бер чәчәктән яз булмый;* гарәп телендә – *Бер йон сакал түгел;* кумык телендә – *Бер таш стена түгел;* абхаз телендә – *Бер казыктан киртә кормыйлар;* серб телендә – *Бер имән имәнлек түгел;* сингал телендә *Бер куак бакча түгел* дигән мәкальләр белән белдерелә.

Үзенә күрә эше, үзенә күрә дусты һәм иптәше дигән фикер татар телендә – *Чиләгенә күрә капкачы;* әфган телендә – *Урманына күрә җиләге, агачына күрә җимеше;* кытай телендә – *Казанына күрә чүмече;* корея телендә – *Боравына күрә тишеге;* вьетнам телендә – *Җиренә күрә җимеше;* тат телендә – *Һәр корабның үз дулкыны;* рус һәм немец телләрендә *Сәламе нинди, җавабы шундый* дигән мәкальләр ярдәмендә тәгъбир ителә.

Бер үк вакытта ике эшне эшләп булмый дигән фикер рус телендә – *Берьюлы ике куянны куып булмый;* татар телендә – *Берьюлы ике көймә койрыгын тотып булмый;* әфган телендә – *Берьюлы бер итеккә ике аякны тыкмыйлар;* чуваш телендә – *Ике тәртә арасына берьюлы ике ат җигеп булмый;* украин телендә – *Берьюлы ике туйда биеп булмый;* осетин телендә – *Ике җәнлекне кусаң, берсен дә тота алмассың;* немец телендә – *Бер сугуда ике чебенне үтереп булмый;* француз телендә – *Бер ташны ике кошка тидереп булмый;* кытай телендә *берьюлы ике көймәдә торуы кыен* дигән мәкальләр белән белдерелә.

Мәгънәләре бердәй, образлары төрле мәкаль-әйтемнәрне телләрнең семантик гомумилеге дип атарга мөмкин.

Татар һәм рус телләренең үзара күп гасырлар буена бәйләнештә булуы аркасында бу ике телдә күп санлы семантик-структур фразеологик тәңгәллекләр урнашкан. Алар төрле телләрдә бердәй мәгънә белдерә торган һәм бер үк образга корылган тотрыклы әйтелмәләр.

Рус һәм татар телләрендәге күп санлы семантик-структур фразеологик тәңгәллекләр арасында аеруча киң кулланылган әйтелмәләрдән торган төп фондны аерып карарга мөмкин.

Бу фондка кергән тотрыклы әйләнмәләр чыганагы буенча төп ике төркемгә: 1) гомумкешелек логикасы нигезендә барлыкка килгән фразеологизмнарга һәм 2) рус теле әйтелмәләренең семантик-структур өлгеләре белән ясалган фразеологизмнарга бүленә.

Мәгънәсе, образлылыгы һәм башка сыйфатлары белән рус теле фразеологизмнарына туры килгән тотрыклы әйтелмәләрдән чыганагы буенча татарларның үзләренеке дип фараз ителерлекләрен карап китү кызыклы. Бу чаралар төрле семантик төркемнәргә керә һәм күбесенчә аерым предметларны, кешенең төп эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләрдән төзелгән була. Шунысы игътибарга лаек: ике тел ияләренең дә тормышында аеруча киң кулланыла һәм күп очрый торган предмет, күренешләрнең мәгънәләрен белдергән сүзләр ярдәмендә ясалган фразеологизмнарда тәңгәллекләр күбрәк очрый. Мәсәлән, ике телдәге соматик фразеологизмнар арасындагы тәңгәллекләрне карыйк:

1. *Баш (голова)* сүзе белән төзелгән фразеологизмнар: *баш вату (ломать голову); башка килү (приходить в голову); баштан сыйпау (гладить по головке); баш югалту (терять голову); баш белән җавап бирү (отвечать головой); баш әйләндерү (вскружить голову); баш салу (сложить голову); башымны кисәргә бирәм (голову даю на отсечение); баш күтәрү (поднимать голову)* һ.б.

2. *Аяк (нога)* сүзе белән ясалган фразеологизмнар: *аяксыз калу (остаться без ног); аякка бастыру (ставить на ноги); аяк сузу (протянуть ноги), аяк чалу (подставлять ногу); аяк басмаган (нога не ступала); сул аяк белән тору (вставать с левой ноги); бер аягың монда, икенчесе тегендә (одна нога здесь, другая там); аяк астында җир яна (земля горит под ногами)* һ.б.

3. *Кул (рука)* сүзе белән төзелгән фразеологизмнар: *кул күтәрү (поднимать руку); кул селтәү (махнуть рукой); кул кычыта (руки чешутся); кул җитми (руки не доходят); кулга ирек бирү (давать волю рукам); кулга өйрәтү (приучить к рукам); кул кушырып утыру (сидеть сложа руки); ике кулсыз калу (как без рук); кулдан кулга (из рук в руки); кулы җиңел (лёгкая рука); уң кулы (правая рука); кулда тоту (держать в руках); кулга алу (взять в руки); алтын куллы (золотые руки); ярдәм кулы сузу (протянуть руку помощи); кул астында (под рукой); кулга эләгү (попадать в руки); кулы кыска (руки коротки); кулны бәйләү (связывать руки)* һ.б.

4. *Тел (язык)* сүзе белән ясалган фразеологизмнар: *тел әйләнми (язык не поворачивается); телнең сөяге юк (язык без костей); теле(-м, -ң) корысын (отсохни язык); уртак тел табу (находить общий язык); тел йоту (проглотить язык); теленнән тартып сөйләтү (тянуть за язык); телне тешләү (прикусить язык); тел кычыта (язык чешется); озын тел (длинный язык); усал телле (злой на язык); телеңә тилчә чыккыры (типун тебе на язык)* һ.б.

5. *Күз (глаза)* сүзе белән төзелгән фразеологизмнар: *күзгә-күз (с глазу на глаз); күз алдында (перед глазами); күз уйнату (играть глазами); күзгә карау (смотреть в глаза); күз яна (глаза горят); күз йому (закрывать глаза); күзем күрмәсен (глаза бы (мои) не видели); күз ачыла (глаза открываются); күзгә ташлана (бросается в глаза); күзгә керү (лезть в глаза); күздән яшерү (скрывать от глаз)* һ.б.

6. *Авыз (рот)* сүзе белән ясалган фразеологизмнар: *авыз ачу (открывать рот); авыз томалау (затыкать рот); авызга карау (смотреть в рот); авызга алмау (в рот не брать)* һ.б.

7. *Борын (нос)* сүзе белән төзелгән фразеологизмнар: *борын тыгу (совать нос); борын күтәрү (задирать нос); борын астыннан (из-под носа)* һ.б.

8. *Муен (шея)* сүзе белән ясалган фразеологизмнар: *муенга камыт кию (надевать хомут на шею); муен сындыру (сломать шею); муенга менеп атлану (садиться на шею); муенга асылыну (вешаться на шею)* һ.б.

Татар һәм рус телләрендә кешенең башка әгъзаларын йөрәк, күкрәк, җилкә, арка, йөз, ирен, чәч, бармак, колак, маңгай, корсак, эчәк, үкчә һ.б.), хайван, кош-корт гәүдәсенең кайбер өлешләрен (койрык, канат һ.б.), көнкүреш предметларын, каралты-кура һәм аларның төрле кисәкләрен, үсемлекләрне һәм аларның өлешләрен, хайваннарны, табигать күренешләрен, кыйммәтле ташларны, кием-салым, ашамлыкларны һ.б. белдерә торган сүзләр ярдәмендә төзелгән фразеологизмнарда да тәңгәллекләр күп: *җилкәдән тау төшү (гора с плеч); чәчләре үрә торды (волосы дыбом встали); теш кайрау (зубы точить); иңгә-иң (торып) (плечом к плечу); тиресен тунау (шкуру снимать); терсәкне тешләп булмый (локоть не укусишь); җиң сызганып (засучив рукава); бугазга ябышу (взять за глотку); стенага борчак сипкәндәй (как об стенку горох); койрыгына басу (наступить на хвост); канатларын кисү (подрезать крылья); судан коры чыгу (выйти сухим из воды); ике ут арасында (меж двух огней); камыт кию (надевать хомут); диңгез тубыктан (море по колено); энә өстендә утыру (сидеть на иголках); тамыр җибәрү (пускать корни); комы коела (песок сыплется); тавык көләр (курам на смех); тавык төшенә тары керә (голодной курице просо снится); күркә кебек кабарыну (надуться, как индюк); сай йөзү (мелко плавать); су сибеп тә аера алмау (не разлить водой); утка-суга керү (в огонь и в воду); җир белән күк арасында (между небом и землёй); каракның бүреге яна (на воре шапка горит); җиде кат үлчә, бер кат кис (семь раз отмерь, один раз отрежь); чебешне көз көне санныйлар (цыплят по осени считают); алма агачыннан ерак төшми (яблоко от яблони далеко не падает); без капчыкта ятмый (шило в мешке не утаишь); кем эшләми, шул ашамый (кто не работает, тот не ест); ни чәчсәң, шуны урырсың (что посеешь, то и пожнёшь); күп белсәң,*

*тиз картаерсың (много будешь знать, скоро состаришься)* һ.б.

Кешенең психологик халәтен, акыл һәм рухи үсешен, характерын, үзара мөнәсәбәтләрен чагылдыра торган фразеологик тәңгәллекләр дә шактый күп: *төштә күргән кебек (как во сне); сүз бирү (дать слово), тавыш күтәрү (поднимать шум); күңеле урынында түгел (сердце не на месте)* һ.б.

Монда шуны искәртергә кирәк: бәлки, әле мисал итеп китерелгән һ.б. фразеологизм тәңгәллекләренең кайберләре бик күп вакытлар элек рус теленнән калькалаштырып алынгандыр. Мәгълүм ки, татарларның руслар белән мөнәсәбәтләре күп йөз еллар дәвам итә. Бик ихтимал: рус телен яхшы белгән татар кешесе сөйләмендә рус әйтелмәләре үрнәгендә үзе ясаган фразеологизмнардан файдалангандыр, һәм соңыннан ул яңа чаралар татар телендә үзләштерелгәндер, һәрхәлдә, хәзер телдә андый киң кулланылышлы фразеологизм тәңгәллекләренең кайсысы татарның үзенеке, кайсысы рус теле йогынтысында ясалган икәнлеген анык билгеләү авыр, ә кайбер очракларда бөтенләй мөмкин дә түгел.

Шулай да, ике телдәге кайбер күренешләрне һәм рус, татар халкы тормышындагы үзенчәлекләрне исәпкә алып, күп кенә гомуми фразеологизмнарны, бигрәк тә Октябрь революциясеннән соңгы чорда барлыкка килгәннәренең чыганагын ачыкларга була. Моңа түбәндәгеләр ярдәм итә:

1) фразеологизмнарның узган гасырда яшәгән халык тормышын, дәүләт структурасын, фән-техника, мәдәният үсешен чагылдыра торган семантикасы;

2) фразеологизм составындагы калькалаштырылган сүзләр;

3) тотрыклы әйтелмәдәге рус алынмалары һәм интернациональ сүзләр;

4) сүзтезмә һәм җөмләнең структур-семантик үзенчәлекләре;

5) фразеологик әйтелмәдәге рус халкының тормышына хас предмет һәм төшенчәләрне белдергән сүзләр;

6) үзара мөнәсәбәттәге ике телнең һәркайсы өчен типик фразеологизмнарны һәм гомумән ике телнең дә фразеология байлыгын яхшы белү.

Менә шушы факторларны исәпкә алып, без түбәндә мисал итеп китерeләчәк һәм башка шундый күп кенә фразеологизмнарның, шул исәптән мәкаль-әйтемнәрнең дә рус теле әйтелмәләре өлгесе белән ясалган чаралар дип тәкърарлый алабыз.

*Техниканың соңгы сүзе белән (по последнему слову техники); мәсьәләне кабыргасы белән кую (ставить вопрос ребром); нокта кую (ставить точку); икенче яшьлеген кичерү (переживать вторую молодость); дарыны коры тоту (держать порох сухим); миләрне чистарту (очистка мозгов); тегермәнеңә су кою (лить воду в мельницу); үз көчендә калу (оставаться в силе); бармак аша карау (смотреть сквозь пальцы); түшәмнән алу (брать с потолка); күзгә төтен җибәрү (пускать пыль в глаза); болганчык суда балык тоту (в мутной воде рыбу ловить);*

*ике җирдә икең дүрт кебек (как дважды два – четыре); кызыл әтәч җибәрү (пускать красного петуха); бер пот тоз ашау (съесть пуд соли); уң кулы булу (быть правой рукой); күңеленә ачкыч табу (найти ключ к сердцу); туйга хәтле төзәлер (до свадьбы заживёт); сәхнәдән төшү (сходить со сцены); суга сәнәк белән язылган (на воде вилами писано); безнең урамда да бәйрәм булыр әле (и на нашей улице будет праздник); бер стакан судагы давыл (буря в стакане воды); тормышта үз урынын табу (находить своё место в жизни); эткә бишенче аяк кирәк булган шикелле (как собаке пятая нога); кеше кешегә – дус, иптәш һәм туган (человек человеку – друг, товарищ и брат); кешене урын бизәми, урынны кеше бизи (не место красит человека, а человек красит место); кылыч күтәргән кылычтан үлә (поднявший меч от меча гибнет); уртак тел табу (находить общий язык); таякны артык бөгеп ташлау (перегнуть палку); бер чиктән икенче чиккә ташлану (бросаться из одной крайности в другую); аяк астында җир яна (под ногами земля горит); зур корабка зур диңгез (большому кораблю большое плавание); каләм белән язганны балта белән юнып булмый (что написано пером, не вырубишь топором); сүз эзләп кесәгә керми (за словом в карман не полезет)* һ.б.

Болар һәм рус теле чаралары үрнәгендә ясалган башка шундый фразеологизмнарның күбесе мәгълүмат чаралары телендә, халыкның җанлы сөйләмендә күп кулланыла һәм, димәк, телебезнең үз хәзинәсенә әверелеп китә. Мәсәлән: *Юл хезмәткәрләре теле белән әйтсәк,* ***«бөке» ясалыр иде*** (М. Мәһдиев); ***Таулар белән таулар очрашмый,*** *кеше белән кеше очраша* (Ә. Атнабаев);

*Ә бюрократ,*
*Күз дә салмый аның хатына,*
*Берәр гаризадыр дип уйлап,*
***Тыгып куйды сукно астына.***
(Ә. Исхак)

Татар телендә рус теленнән калькалаштырып алынган канатлы сүзләр, афоризмнар, әйтемнәр дә бар. Мәсәлән: *чорыбызның акылы, намусы, вөҗданы (ум, честь и совесть нашей эпохи); сәламәт тәндә сәламәт акыл (в здоровом теле здоровый дух); бөек башлангыч (великий почин); дәүләт – без ул (государство – это мы); уңышлардан баш әйләнү (головокружение от успехов); очкыннан ялкын кабыныр (из искры возгорится пламя); аю хезмәте күрсәтү (оказание медвежьей услуги); чуртан кушуы буенча (по щучьему велению)* һ.б.

Рус теле аша Көнбатыш Европа телләреннән калькалаштырылган канатлы әйтемнәр, шулай ук Борынгы Греция һәм Рим чорыннан ук килә торган канатлы сүзләр: *дәүләт эчендә дәүләт (государство в государстве); аппетит ашаганда килә (аппетит появляется во время еды); кызыл җеп булып үтү (проходить красной нитью); дәүләт машинасы (государственная машина); канатлы сүз (крылатое слово); вакыт – иң кырыс һәм гадел судья (время – самый строгий*

*и верный судья); чебеннән фил ясау (из мухи делать слона); ызгыш алмасы (яблоко раздора); акчаның исе юк (деньги не пахнут)* һ.б.

Канатлы сүзләр, афоризмнар һәм әйтелмәләрнең күбесе бер телдән икенче телгә калькалаштырып алына. Фразеологизмнарның бер телдән икенче телгә үтеп керүе берьяклы гына процесс түгел: ул рус теленнән татар теленә генә түгел, бәлки татар теленнән рус теленә дә алына. Татар әдәбиятының күп кенә әсәрләрен русчага тәрҗемә итү нәтиҗәсендә, татар теле фразеологизмнарының күбесе рус теленә калькалаштырыла. Бу тәрҗемә теориясендәге мондый принципка нигезләнгән: оригинал фразеологизмнары, бердәй мәгънә һәм образлылыкны, сурәтлелек, җыйнаклылыкны тел нормасын бозмыйча сакларга мөмкин булганда, тәрҗемәдә бирелергә, ягъни төп мәгънәле тәңгәллекләре белән тәрҗемә ителергә тиеш. Бу принцип русчадан татарчага һәм татарчадан русчага тәрҗемә практикасында тормышка ашырыла. Соңгы елларда матур әдәбият әсәрләренең русчага тәрҗемәләрендә татар фразеологизмы үрнәгендә уңышлы гына төзелгән тотрыклы әйтелмәләр барлыкка килде. Мәсәлән: *поговорить с перцем и солью (тозлап-борычлап сөйләшү); соль на рану (ярасына тоз салу); струнку тронуть (кылын чиртү); посадить на пенёк (төп башына утырту); мозг кипит (ми кайный); протянуть через игольное ушко (энә күзеннән үткәрү); правда камни рубит (туры сүз таш яра); отрезанный ломоть не пристанет (бер кискән икмәк кире ябышмый); негде иголку воткнуть (энә төртерлек тә урын юк); словно во рту кашу варит (авыз эченнән ботка пешерү); рука легка (кулы җиңел); молоко не высохло на губах (ирененнән сөт кипмәгән әле); о завтрашнем дне пускай ишак думает (иртәгесе көн өчен ишәк кайгырсын); железный гребень на собственную голову (авыртмаган башка тимер тарак)* һ.б.

Бер телнең тотрыклы әйтелмәләрен икенче тел чаралары белән кабат төзү мөмкинлеге нәрсә белән аңлатыла, һәм ни өчен бер төрле фразеологизмнарны калькалаштырып була, ә икенче төрлеләрен юк?

Бер тел фразеологизмнарын икенче тел чаралары белән шуның өчен кабат төзеп була: беренчедән, телдәге фразеологик тезмәнең күчерелмә мәгънәсе һәм мәкальнең морале (фикере) икенче тел ияләренә дә якын һәм таныш була, чөнки ул фразеологизмнар чыганак тел ияләренең тормышын гына түгел, бәлки башка халыкларның, аерым алганда үзара мөнәсәбәттәге икенче тел ияләренең тормышын да чагылдыра. Икенчедән, тотрыклы әйтелмәләр иректе сүзтезмәләрдән килеп чыккан, һәм алар составына кергән сүзләр мөстәкыйль мәгънәләрен югалтып бетермәгән. Менә шушы үзенчәлекләр аларны икенче телгә калькалаштырып, ягъни төп мәгънәләрендәге тәңгәллекләре белән тәрҗемә итеп алырга мөмкинлек бирә. Фразеологизмны икенче телгә төп номинатив,

туры мәгънәдәге тәңгәл сүзләр белән күчерү аркасында аның күчерелмә мәгънәсе белән образлылыгы саклана да инде.

Фразеологизмнарны икенче телгә төп мәгънәсендәге тәңгәллекләр, ягъни туры тәңгәллекләр белән тәрҗемә итү мөмкинлеге үзара мөнәсәбәттәге ике тел фразеологизмын тәшкил иткән сүзләрнең бергә килә алу (бәйләнешкә керү) үзенчәлегенә бәйле. Бер телдәге тотрыклы әйләнмә сүзләренең икенче телдәге төп номинатив тәңгәллекләре бергә килә, ягъни мәгънә бәйләнешенә керә алмаса, фразеологизм икенче телгә туры тәңгәллеге – образлары да туры килә торган тәңгәллеге белән күчерелми. Мәгълүм булганча, төп мәгънәләре бердәй ике тел сүзләренең кайберләре башка сүзләр белән бәйләнешкә керә, кайберләре исә керә алмый. Әйтик, рус телендәге *крупный* һәм *зерно* сүзләре дә, аларның татар телендәге туры тәңгәллекләре *эре* һәм *орлык* та, үзара бәйләнешкә кереп, сүзтезмәләр тәшкил итә ала: *крупное зерно – эре орлык.* Рус телендәге *крупный* һәм *учёный* сүзләре, бергә килеп, бу тел өчен табигый сүзтезмә төзи ала, аларның татар телендәге туры тәңгәллекләре *эре* һәм *галим* исә табигый әйтелмә төзи алмый (татарча *эре галим* димиләр); бу очракта чыганак сүзтезмәсенең мәгънәсе татарча *зур* һәм *галим* сүзләре белән белдерелә *(зур галим).* Шулай ук рус телендәге *усы* һәм *мотать* сүзләре белән аларның татарча туры тәңгәллекләре *мыек* һәм *чорнау* үзара бәйләнешкә керү сәләте буенча бертөрле булалар, һәм шуның аркасында *мотать на ус* татарчага калькалаштырыла да *(мыекка чорнау). Надуть (надувать)* белән *губы* сүзләре һәм аларның тәңгәллекләре *кабарту* белән *ирен* сүзләре бәйләнешкә керүләре ягыннан бертөрле түгел: төгәлрәк итеп әйткәндә, рус сүзләре, үзара бәйләнешеп, фразеологизм төзи *(надуть губы – ачулану, үпкәләү* мәгънәсендә), татар сүзләре исә үзара бәйләнми, һәм, димәк, тотрыклы әйтелмә дә тәшкил итә алмый (татарча андый мәгънәдә *иренен кабарткан* димиләр, бәлки *авызын турсайткан* диләр).

Фразеологизмнарга, мәкальәйтемнәргә аерата җыйнаклык, кыскалык, ритмлылык, аллитерация һәм өлешчә рифмалылык хас. Мәкальләр – бик оста эшләнгән, сәнгатьлелек ягыннан камил әйтелмәләр. Кайчакта фразеологизмнарның мондый сыйфатларга ия булуы икенче телдә бердәй мәгънәле һәм образлы, бер үк дәрәҗәдә җыйнак, шома тел чаралары ясарга мөмкинлек бирми: тәңгәл сүзләрнең авазлар сүрүе төрлечә булуы аркасында, тәрҗемә иткәндә, чыганак тел фразеологизмының өлешчә күләме бозыла, ритмы, аллитерациясе һәм рифмасы югала. Әйтик, рус халкының *поспешишь – людей насмешишь; тише воды, ниже травы; добрая слава лежит, а худая по свету бежит* дигән мәкаль-әйтемнәрен татарча туры тәңгәллекләре белән шуның өчен биреп булмый: оригиналда рифмалашып килгән һәм ритмга корылган *поспешишь – насмешишь; тише – ниже; лежит – бежит* сүзләренең татарча

туры тәңгәллекләре *ашыксаң – көлдерерсең* (сүзгә-сүз: *ашыксаң, кеше көлдерерсең); әкрен – түбән (судан әкрен, үләннән түбән); ята – йөгерә (чаба) (яхшы хәбәр ята, яман хәбәр дөнья буйлап йөгерә (чаба)* рифмалашмыйлар, һәм аларның ритмнары да юк. Шулай булгач, алар оригинал кебек хисле-тәэсирле дә була алмый, һәм бу очракта чыганак тел фразеологизмнарына күчерелмә мәгънәләре һәм сурәтлелек, тәэсирлелек көче буенча тиң, ләкин образлары икенче төрле чаралар эзләп табарга туры килә.

Фразеологизмнар икенче телгә компонентлары бик нык береккән, катып калган һәм мөстәкыйль мәгънәләрен югалтканда һ.б. сәбәпләр аркасында да туры тәңгәллекләре белән бирелми. Аларны җентекләбрәк карап китик:

1. Фразеологизм составына тотрыклы әйтелмә барлыкка килгән чактагы мәгънәсен югалткан сүзләр керә: *не на живот, а на смерть* (*живот* сүзе *тормыш* дигән мәгънәне аңлаткан булган); *от корки до корки* (*корка* – китап, дәфтәр һ.б. тышы); *ни кола, ни двора* (*кол* – борынгы җир үлчәве) һ.б.

2. Фразеологизм составында лексик архаизмнар һәм историзмнар була: *попасть впросак (бау ишү станогына эләгү); турусы на колёсах* (крепостьларны камау өчен күчереп йөртелә торган манара); *гол как сокол* (шомартылган багана, таран) һ.б. Хәер, мондый фразеологизмнарның кайберләре тәрҗемә ителә: *как зеницу ока – күз карасы кебек (зеница – зрачок).*

3. Тотрыклы әйтелмә искергән грамматик формаларга корылган була: *темна вода во облацех (в облаках)* – нинди дә булса аңлаешсыз нәрсә турында әйтелә; *пуститься во вся тяжкая* – (Борынгы Русьтагы зур кыңгыраулар; *притча во языцех* (халыкларда) һ.б.

4. Кайбер фразеологизмнарны компонентлары арасында җанлы, хәзерге синтаксик бәйләнеш булмаган тотрыклы сүзтезмәләр тәшкил итә: *себе на уме; почём зря; во что бы то ни стало.*

5. Әйтелмәнең нигезендә яткан фактлар, вакыйгалар, ышанулар һ.б.лар инде бөтенләй онытылган була һәм хәзер аңлашылмый: *козёл отпущения; коломенская верста; дело в шляпе; драть как Сидорову козу; в ногах правды нет.*

Шулай итеп, фразеологизмнарны турыдан-туры тәрҗемә итеп, ягъни икенче телдә тәңгәл тотрыклы әйтелмә ясап булмауның төп сәбәпләреннән берсе – әйләнмәнең беренчел мәгънәсе белән күчерелмә мәгънәсе арасында бәйләнеш югалган булуда.

Фразеологизмнарның турыдан-туры тәрҗемә ителүенә мөмкинлек бирми торган факторларга таянып, без тотрыклы әйтелмәләр икенче телгә түбәндәге очракларда төп тәңгәллекләре белән күчерелә ала дигән нәтиҗә ясыйбыз:

– Чыганак тел фразеологизмын тәшкил иткән сүзләр мөстәкыйль мәгънәләрен югалтып бетермәгән, һәм алар тотрыклы әйтелмәнең гомуми мәгънәсенә берникадәр нигез булып тора.

Фразеологизмда компонентларның мөстәкыйль мәгънәләре беленеп тору һәм билгеле бер тел ияләренең тотрыклы әйләнмәне күчерелмә мәгънәдә аңлый алулары икенче телдә дә шундый фразеологизм төзергә мөмкинлек бирә: төрле телләрдә төп мәгънәләре бердәй сүзләрнең бертөрле күчерелмә мәгънә белдерә алуы аркасында икенче тел чараларыннан ясалган яңа әйләнмәнең күчерелмә мәгънәсе дә ул тел ияләренә аңлашыла, һәм ул фразеологизм составына кергән сүзләр дә мөстәкыйль мәгънәләрен югалтып бетермәгән була.

– Чыганак тел фразеологизмын тәшкил иткән сүзләрнең һәм аларга төп мәгънәләрендә туры килә торган икенче тел сүзләренең башка сүзләр белән бәйләнешкә керү мөмкинлекләре бертөрле була.

– Чыганак тел фразеологизмы составында лексик архаизмнар һәм тарихи сүзләр, искергән грамматик формалар булмый.

– Фразеологизм күптән онытылган фактларга, вакыйгаларга нигезләнеп төзелмәгән була.

– Чыганак тел фразеологизмы составында татар теленең *син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала* әйтелмәсендәге кебек специфик реалия исемнәре булмый.

– Оригинал әйтелмәсен төп мәгънәле тәңгәллекләр белән тәрҗемә итү икенче телдә кытыршы, ямьсез, табигый булмаган әйләнмә барлыкка китерми, тел нормаларын бозмый.

Ике тел фразеологизмнарының нисбәте турында сөйләгәннәрдән шул аңлашыла: бер телдә икенче тел үрнәгендә яңа тотрыклы әйтелмәләр ясау калькалаштыруга һәм ярымкалькалаштыруга нигезләнгән. Калькалаштыру ул – икенче төрле әйткәндә, чыганак тел фразеологизмы составына кергән сүзләрнең икенче телгә төп номинатив мәгънәдәге тәңгәллекләре белән күчерелүе. Бу очракта оригиналның мәгънәсе һәм образлылыгы тулысынча саклана. Ярымкалькалаштырылганда исә беренче тел фразеологизмы компонентларының тотрыклы әйтелмәне төзүдә иң әһәмиятле роль уйнаганнары икенче телгә күбесенчә төп тәңгәллекләре белән бирелә, калган сүзләре исә үзгәрешкә дучар ителә: номинатив мәгънәләре белән оригиналга туры килми торган сүзләр кулланыла, кайбер сүзләр төшереп калдырыла, чыганак тел әйтелмәсендә булмаган кайбер сүзләр өстәлә. Мондый үзгәреш нәтиҗәсендә төзелгән фразеологизмның күчерелмә мәгънәсе чыганак телдәгенеке белән бертөрле, образлылыгы якынча була.

Бер тел әйләнмәсен икенче телгә болай берникадәр үзгәртеп күчерү яңа фразеологизмны, оригиналның мәгънәсе белән образлылыгын, шулай ук сурәтлелек-бизәклелеген, тәэсирлелеген саклаган хәлдә, икенче тел ияләре өчен табигый, ятышлы, җыйнак итеп төзү максатында эшләнә.

Рус теле фразеологизмнарын татар теле үзенчәлекләренә яраклаштырып төзү ике телдә эшләүче каләм ияләренә шактый күптөрле һәм катлаулы бурычлар

йөкли. Шуларның кайберләренә тукталып китик:

1. Чыганак тел фразеологизмының нинди дә булса бер компоненты икенче телдә шактый үзгә сүз белән бирелә: ул сүз оригиналга төп мәгънәсе белән туры килми, ләкин якын семантик төркемгә караган лексема (сүз) буларак, бу контекстта чыганак тел мәгънәсен дөресрәк, сурәтлерәк итеп бирә. Мәсәлән, *достать птичье молоко (күгәрчен сөте табу)* фразеологизмын татарчага күчергәндә, *птичье* сүзе төп тәңгәллеге белән бирелми, моның өчен семантикасы буенча аңа якын торган *күгәрчен* сүзе файдаланыла, чөнки татар кешесе өчен *күгәрчен сөте* төшенчәсе оригиналны төп тәңгәллекләре белән тәрҗемә итүдән барлыкка килә торган *кош сөте* сүзенә караганда аңлаешлырак, табигыйрак һәм сурәтлерәк. *Не лезет в рамки* фразеологизмының тәрҗемәсендә *(киртәгә сыймый) рамка* сүзе *киртә* белән алмаштырылган, чөнки ул бу контекстта оригинал мәгънәсен табигыйрак та, дөресрәк тә бирә. *Сводить концы с концами* үрнәгендә ясалган *очны очка ялгау* әйтелмәсендә дә шул ук күренеш: *сводить* төп тәңгәллеге белән түгел, бәлки *ялгау* сүзе белән белдерелгән. Хәлбуки фраза, гомумән алганда, эчтәлеге белән дә, формасы белән дә оригиналга туры килә. *Утка керосин сибү (лить масло в огонь); кылыч күтәргән кылычтан үләр (кто с мечом придёт, от меча погибнет)* кебек әйтелмәләр шулай яраклаштырып ясалган фразеологизмнар исәбенә керә.

2. Алучы тел фразеологизмына чыганак тел әйтелмәсендә булмаган сүзләр өстәлә. Бу – фразеологизмның мәгънәсе һәм образлылыгы тулы, әйләнмә шома, ятышлы булсын өчен эшләнә. Мәсәлән, *твёрдый орешек* гыйбарәсенең туры тәрҗемәсе – *каты чикләвек.* Ләкин бу татар кешесе өчен табигый түгел. Шуңа күрә чыганак тел әйтелмәсенә бер сүз *(кабыклы)* өстәлеп, *каты кабыклы чикләвек (орешек с твёрдой скорлупой)* дигән фразеологизм ясала: монысы инде татар кешесе тарафыннан үз тәгъбире булып кабул ителә. *Искать днём с огнём – көндез чыра яндырып эзләү (искать днём, зажигая лучину).* Бу тәрҗемәдә *яндыру* сүзен өстәү шуның белән аңлатыла: татар телендә чыганак тел фразеологизмының мәгънәсе нәкъ менә шушы сүз кулланылганда тулырак белдерелә. Бу фразеологизмнар да шундый кечерәк кенә үзгәреш кертеп ясалган: *кулың белән биргәнне аягың белән йөреп аласың (отдашь руками, вернёшь ногами); бер көнлек юлга чыксаң, атналык азык ал (едешь на день – бери хлеба на неделю); авырткан җирдән кул китми, сөйгән кешедән күз китми (где больно, там рука, где мило, там глаза).*

Чыганак тел фразеологизмын, эчтәлек һәм образлылыгын җитди үзгәрешләргә китермәслек итеп, берникадәр үзгәртеп кору күренеше татар әйтелмәләре өлгесе белән ясалган русча фразеологизмнарда да очрый. Мәсәлән, *тәвәккәлдә тау көче – кто рискнёт, тот гору свернёт;*

*арысланның – ялы, ирнең – сакал-мыегы – льва красит грива, мужчину – усы и борода.*

Татар фразеологизмына рус әйтелмәсендә булмаган сүз өстәү татар мәкаль-әйтемнәре төзелешендәге үзенчәлекләр белән дә бәйләнгән. Шундый үзенчәлекләрнең берсе – күп кенә мәкальләрнең *булу* ярдәмче фигыле белән тәмамлануы. Шуның аркасында рус теленнән калькалаштырып ясалган мәкальгә, оригиналда тәңгәллеге булмаса да, *булу* сүзе өстәргә туры килә: *первый блин комом – беренче коймак төерле була; нет ума у голодного – ачның акылы булмый; домом не управил – так и волостью не управит – үз өендә баш булмаган өязгә чыгып баш була алмас; и не красива, да счастлива – буең булмасын, бәхетең булсын* һ.б.

Татар мәкальләренең сүз өстәүгә, дөресрәге, сүзне кабатлауга китерә торган тагын бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: компонентлары арасында капма-каршылыклы мөнәсәбәт булган тезмә кушма җөмләдән торган рус мәкалендә фигыль-хәбәр кушма конструкциянең беренче кисәгендә генә кулланылса, шундый ук мәгънәле татар мәкалендә исә бер үк фигыль-хәбәр аның икенче кисәгендә дә куела. Мәсәлән: *больной умирает раз, а ленивый – каждый день – авыру бер үләр, ялкау көн дә үләр; не конь везёт, а овёс – ат тартмый, солы тарта.* Кайвакыт мондый төзелешле мәкальләрнең барлык сүзләре дә төп мәгънәле тәңгәллекләре белән тәрҗемә ителә: *готовь сани летом, а телегу – зимой – чананы – җәйдән, арбаны кыштан әзерлә.*

Татар фразеологизмнары үрнәгендә төзелгән рус әйтелмәләрендә теркәгечләр өстәлә: *бәхет күктә булмый, кулда була – счастье не в небесах, а в руках; дуслык ашаганда беленми, эшләгәндә беленә – дружба познаётся не за обедом, а за делом; халык, әйтсә, хак әйтер – если народ скажет, то не оговорится.* Өстәмә теркәгечләр куллану рус теленең синтаксик үзенчәлекләренә бәйләнгән.

Рус мәкальләренең кайбер компонентлары төрле телләрдә сүзләр бәйләнешендәге үзенчәлекләр аркасында үзгәртелергә мөмкин. Мәсәлән, *соловья баснями не кормят* мәкалендәге *басня* сүзе *җыр* белән алмаштырыла, чөнки оригиналның сүзгә-сүз тәрҗемәсе *(сандугачны мәсәл белән сыйлау)* татарча табигый яңгырамый.

3. Бер телдә икенче тел әйтелмәсе үрнәгендә бердәй мәгънәле яңа фразеологизм ясаганда, чыганак телнең кайбер элементлары төшереп калдырыла. Мондый үзгәреш интонация – табигыйрак, фразеологик берәмлек бизәклерәк булсын өчен кертелә. Матур яңгырашлы, җыйнак, үзенчәлекле интонацияле һәм төзелешле мәкальләрне калькалаштырганда, оригинал әйтелмәсенең кайбер сүзләрен төшереп калдырырга туры килә. Оригинал фразеологизмы сүзләренең барысын да икенче телдә бирү ул тел өчен табигый әйләнмәләр төзергә мөмкинлек бирмәс иде. Төшереп калдыру мондый сүзләргә карата кулланыла:

а) төшереп калдыргач та, тәрҗемә теле фразеологизмының мәгънәсе үзгәртелми торган мөстәкыйль сүзләр: *весна красна цветами, а осень – плодами – яз – чәчәге белән, көз – җимеше белән* (тәрҗемәдә *красна* сүзе чагылыш тапмый, аның мәгънәсе исә татар әйтелмәсендә контексттан аңлашыла; әйтем *красна* сүзенең тәңгәллеге *матурдан* башка җыйнаграк, шомарак – нәкъ традицион татарча әйтем *кош – канаты, ир – аты белән* рәвешендә); *если ложкой не наелся, языком не налижешься – ашап туймаганны ялап туймассың* (татарча, *ложкой* һәм *языком* сүзләре бирелми, әмма аңа карап әйтелмәнең эчтәлегенә дә, аһәценә дә зыян килми, киресенчә, хәл яхшы якка үзгәрә генә); *не рой другому яму, сам в неё попадёшь – кешегә баз казыма, үзең төшәрсең (в неё* сүзенең мәгънәсе татарча мәкальдә контексттан аңлашыла, аның тәңгәллеген куллану *(аңа* сүзен өстәү) татар теле өчен табигый мәкаль төзелешенә зыян китерер иде);

б) рус телендә мөнәсәбәтле сүзләр белән төзелгән иярченле кушма җөмләләр татар телендәгегә караганда күбрәк кулланылганлыктан, кушма җөмлә белән бирелгән мәкальләрне тәрҗемә иткәндә, мөнәсәбәтле сүзләр кайчак төшереп калдырыла: аналитик төзелешле җөмләләр синтетик җөмләләр белән бирелә. Мәсәлән: *каково лукошко, такова ему и покрышка – чиләгенә күрә капкачы; кто посеет ветер, тот пожнёт бурю – җил чәчкән давыл урыр; кто правду сказал, тот родне не угодил – туры әйткән туганына ярамаган.* Хәлбуки татарларда төзелеше белән русларныкына туры килә торган мәкаль-әйтемнәр дә аз түгел. Аларның кайберләре аналитик вариантта да, синтетик вариантта да кулланыла: *кто не работает, тот не ест – кем эшләми, шул ашамый (эшләмәгән ашамый); каково дерево, таков и плод – агачы нинди, җимеше шундый (агачына күрә җимеше)* һ.б. Аналитик төзелешле мәкальләр рус теле йогынтысында татар теленә күбрәк керә бара.

Татар теленнән тәрҗемә итеп алынган русча мәкальләрдә мөнәсәбәтле сүзләр чыганак тел чараларында булмаганда да кулланыла.

Татар мәкальләренең бер аермалы ягы шунда: катлаулы төзелешле рус мәкалендә кушма конструкция составындагы җөмләләр, гадәттә, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешкә керә, бердәй мәгънәле татар әйтелмәсендә теркәгечләр вазифасын тиешле интонация башкара, татар мәкальләренә теркәгечләр (бигрәк тә каршы куючы теркәгечләр) хас түгел. Монда татар теле үсеше характерындагы шундый бер үзенчәлек күренә: башлангыч чорда кушма җөмләләр теркәгечләрдән башка гына формалашкан. Бу үзенчәлек сөйләм телендәге сурәтләү чараларының иң борынгы формаларыннан берсе булган мәкальләр төзелешендә чагылыш тапкан. Шуңа күрә дә татар телендә рус әйтелмәләре үрнәгендә мәкальләр ясалганда, чыганак тел теркәгечләре (союзлары) күбесенчә төшереп калдырыла, һәм бу – татар

телендәге калькалаштырылган мәкальләрнең җыйнаклыгына, аһәңлелегенә ирешүдә нәтиҗәле юлларның берсе: *ум не в летах, а в голове – акыл яшьтә түгел, башта; была бы шея, а хомут найдётся – муены булса, камыты табылыр; береги платье снову, а честь смолоду – киемеңне – яңа чагыннан, намусыңны яшьтән сакла; вырасти вырос, а ума не вынес – буе үскән, акылы үсмәгән* һ.б.

Мәкальләрдәге теркәгеч – интонация нисбәтенә карата белдерелгән фикер – матур әдәбият әсәрләрендә очрый торган киная-ле әйтелмәләрнең тәрҗемәсенә дә карый. А.С. Пушкинның «Капитан кызы» повестеннан бер мисал: *Будет дождик, будут и грибы, а будут грибы, будет и кузов. Яңгыры булса, гөмбәсе булыр, гөмбәсе булгач, кызавы да табылыр.*

4. Ике телнең дә күп кенә фразеологик әйтелмәләре, бигрәк тә мәкаль-әйтемнәре, аллитерациягә (сүзләрнең беренче авазлары бертөрлелегенә һәм охшашлыгына), ритм һәм рифмага корылган була. Нәфислек, аһәңлелек, тәэсирлелек шактый дәрәҗәдә әнә шул сыйфатларга нигезләнгән дә инде. Мисал өчен ике телдән дә берничә фразеологик берәмлек күрсәтеп китик:

Рус фразеологизмнары: *ни свет, ни заря; ни пуха, ни пера; ни дать, ни взять, ни встать, ни сесть; ум за разум заходит; не на жизнь, а на смерть; тише воды, ниже травы; огнём и мечом; один на один; раз за разом; так ли, сяк ли; то так, то сяк; там и сям; то там, то сям; из уст в уста; чин чином; будь что будет; шиворот-навыворот; яснее ясного; наводить тень на ясный день* һ.б.

Татар фразеологизмнары: *бер балык башын чәйнәү; бер кармакта биетү; бер алга, биш артка; берне биш итү; беткән баш беткән; биш былтыр; биш бармак кебек (белү); буш бугаз; бушны бушка бушату; исәп белән исерү; иштең, ишәк чумарын; коры куык очырту; кызыл кар яугач; көтә-көтә көтек булу; күңел күзе; салпы ягына салам кыстыру; сафсата сату; серкәсе су күтәрми; суган суы суыру; тел-теш тидерү; теш-тырнак тидермәү; теңкәгә тию; типсә тимер өзү; җиде буынга җиту; үгезне мөгезеннән эләктерү; ярма яру; эттән алып этка салу; элеп алу, селкеп салу* һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, фразеологизмнар төзелешендә шундый бер принцип сакланган: аларның компонентлары авазлар охшашлыгын, иҗек саны тигезлеген, сүзләрнең озынлыгын-кыскалыгын һ.б. исәпкә алып сайлап алынган, һәм бу процесста еш кына теге яки бу сүзнең мөстәкыйль лексик мәгънәсе нинди булу роль уйнамый, бәлки яңгырашы буенча әйтелмәнең башка сүзләренә охшаш булуы беренче планга куела. Әйтик, *кызыл кар яугач* дигән әйтелмәдә *кызыл* сүзе яңгырашы буенча *кар* сүзенә охшаш булганлыктан алынган дип фараз итәргә нигез бар, чөнки монда карның нинди төстә булуының әһәмияте юк (фразеологизмның гомуми мәгънәсе өчен барыбер: кызылмы ул, яшелме, зәңгәрме, сарымы һ.б.).

Күчерелмә мәгънәдәге (беркайчан да булмаслык нәрсә) бу фразеологизм өчен мөһиме шул: кар ак түгел, һәм аның инде ак төстән башка теләсә нинди төстә булуы процессның, күренешнең реаль булмавына ишарә ясый. Әмма кызылдан башка берәр төс исеме кулланылса *(зәңгәр кар, яшел кар* һ.б.), яңгырашы, аһәңлелеге *кызыл карда*гыга караганда начаррак, һәм әйтелмәнең тәэсир итү көче дә кимрәк булыр иде. *Кылны кырыкка яру* дигән әйтелмәдә *кырык* сүзе шулай ук *кыл* сүзенә охшатып алынган, югыйсә ул сүзнең төп лексик мәгънәсе бу очракта исәпкә алынмый: фразеологизмның гомуми мәгънәсе өчен барыбер – кырыкка ярылумы, иллегәме, йөзгәме һ.б. Ләкин әйтелмәнең матур яңгырашы өчен нәкъ менә *кырык* сүзе кирәк булган.

*Тише воды, ниже травы* дигән рус фразеологизмында *воды* һәм *травы* сүзләре урынына нинди дә булса башка сүзләр алынмыйча, нәкъ менә шуларның үзләре кулланылуда беренче планда рифмалаштыру максаты күздә тотылган, чөнки бу очракта *вода* һәм *трава* сүзләренең лексик мәгънәләре әһәмиятле роль уйнамый: *тын, түбән булу (тише, ниже* мәгънәләре) сыйфатларына ия булган башка күптөрле табигать күренешләре исемнәреннән дә файдаланырга мөмкин. Ләкин монда фразеологизм иҗатчысының игътибарын нәкъ менә шушы охшаш яңгырашлы *вода, трава* сүзләре җәлеп иткән.

Мәкаль-әйтемнәр төзелешендә аллитерация, ритм, рифма һ.б. саф фразеологик тезмәләргә караганда зуррак роль уйный. Мәкаль-әйтемнәрнең күбесе – сәнгатьле, бизәкле, нәфис итеп эшләнгән камил сурәтләү чаралары. Аларның матур яңгырашлы булуына җөмләнең үзенчәлекле төзелеше – симметрия, параллелизм, контрастка корылган булуы да ярдәм итә. Фразеологик әйтелмәләрнең мондый сәнгатьлелек үзенчәлекләре журналистларга һәм гомумән ике тел белән эш итүче каләм ияләренә аларның бер тел фразеологизмын икенче телгә күчерү эшендә катлаулы бурычлар йөкли. Бу катлаулылык менә нәрсәгә бәйләнгән: тәрҗемәче алдында чыганак тел әйләнмәсен икенче телгә мәгънәсен дә, образлылыгын да һәм сәнгатьлелек-сурәтлелеген дә мөмкин булганча саклап күчерү бурычы тора. Мәгънәне, образлылыкны оригинал фразеологизмының компонентларын төп мәгънәсендәге тәңгәллекләре белән бергәндә генә саклап була. Ләкин чыганак әйтелмәдә аллитерация, ритм, рифма тәшкил итә торган сүзләрнең икенче телдәге тәңгәллекләре, бердәй мәгънәле төрле тел сүзләренең авазлар сүрүе төрлечә булганлыктан, оригиналдагы бизәккә, сәнгатьлелек сыйфатларына ия була алмыйлар. Бу каршылыкны бетерү ике тел белән эш итүче каләм иясеннән зур осталык, иҗадилык таләп итә.

Бер тел фразеологизмының сәнгатьлелек сыйфатларын бердәй мәгънәле икенче тел әйтелмәсенә күчерү – иҗади эш, һәм моның төрле алымнары бар. Әйтергә кирәк, татар-рус

икетеллелеге практикасында бу мәсьәләнең уңышлы хәл ителүенә мисаллар күп.

Хәзер фразеологизмнарның аллитерация, ритм, рифма кебек сыйфатларын икенче телдә бирү ысулларының кайберләренә – аеруча киң кулланылыштагыларына тукталып китәбез.

Башта шуны искәртеп куйыйк: бер тел фразеологизмнарының сәнгатьлелек үзенчәлекләрен икенче телдә саклау турындагы сүз күчерелмә мәгънәләре ике телдә дә бердәй әйтелмәләргә карата гына алып барыла. Мәгънәләре төрле әйтелмәләр чагыштырма өйрәнү һәм телләрнең үзара йогынтысы нәтиҗәсендә фразеологик системаның үсешен тикшерү объекты була алмый.

Оригинал әйтелмәсенең образлылыгын икенче телдә тулысынча һәм өлешчә саклаган хәлдә аллитерация, ритм, рифманы мондый юллар белән бирергә мөмкин:

а) ике структур кисәктән торган чыганак тел мәкаль-әйтемнәренең рифмалашкан соңгы сүзләренә икенче телдә дә үзара рифмалашырлык бер семантик төркем тәңгәллекләре, ягъни якын мәгънәле тәңгәллекләр табыла. Мәсәлән: *глупый судит, а умный рассудит – тиле гаеп итәр, акыллы фикер итәр; где хочу, там и топчу – кая телим, шунда йөрим; колхоз – дело это добровольное, хочешь – иди, хочешь – со стороны гляди – колхоз ул – ихтыяри эш, теләсәң – кер, теләмәсәң, читтән карап тор* һ.б.;

б) икенче телдә оригинал мәкаль-әйтемендәге рифмалашып килгән сүзләрнең тәңгәллекләрен рифмалаштырырга мөмкин булмаса, башка сүзләрнең тәңгәллекләре рифмалашып килерлек итеп сайлап алына: чыганак тел әйтелмәсенең гомуми эффекты болай эшләгәндә дә бирелә. Мәсәлән: *каков батька, таковы и детки – атасы нинди, баласы шундый; за добро не жди добра – ит яхшылык, көт яманлык; гордись не ростом, а умом – буй белән түгел, уй белән; не имей сто рублей, а имей сто друзей – йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын* һ.б.;

в) оригиналдагы рифма бизәген икенче телдә рифма белән биреп булмаса, чыганак тел чарасының рифма ярдәмендә ирешелгән сурәтлелеген, тәэсирлелеген аллитерация, ритм белән бирергә мөмкин. Мәсәлән: *всякий дурак красному рад – тиле кызылга кызыга; кто правду сказал, тот родне не угодил – туры әйткән туганына ярамаган* һ.б.;

г) оригинал чарасы аллитерация белән рифмага нигезләнмичә, ритмга гына корылган булса, икенче тел әйтелмәсе дә мөмкин булганча ритмлы итеп төзелә. Мәсәлән: *и волки сыты, и овцы целы – сарык та исән, бүре дә тук; ум не в летах, а в голове – акыл яшьтә түгел, башта; волков бояться – в лес не ходить – бүредән курыксаң – урманга бармыйсың* һ.б.

Чыганак тел фразеологизмын икенче телгә компонентларының төп тәңгәллекләре белән, ягъни образлылыгын саклап бирергә мөмкин булмаса, оригинал чарасы аңа күчерелмә мәгънәсе һәм сурәтлелеге-бизәклелеге

буенча туры килә торган, ләкин икенче образга корылган әйтелмә белән алмаштырыла. Мондый алмаштыру юлы белән аерым сүзләрнең мөстәкыйль мәгънәләре сизелми торган һәм кайчак, үзләрен генә алганда, хәзерге телдә бөтенләй аңлашылмый да, кулланылмый да торган, нык береккән әйтелмәләр (идиомалар) тәрҗемә ителә. Мәсәлән: *зла на зло не воздавай – таш атканга аш ат; ни рыба, ни мясо – ни он, ни йон; каков привет, таков ответ – соравына күрә җавабы (соравы нинди, җавабы шундый); когда густо, когда и пусто – бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй; бедному Кузеньке бедная и песенька – ярлыга ярык төймә; не дорог подарок, дорога любовь – инә дә бүләк, дөя дә бүләк; кто выбирает, тот век измеряет – сайлаган – сазга, очраган – тазга; снаружи мило, а внутри гнило – тышы ялтырый, эче калтырый; из грязи в князи – сәнәктән көрәк булган.*

Һәр телнең фразеологик системасы күләмле һәм катлаулы була. Тотрыклы әйтелмәләр мәгънәләре, образлары, төзелеше, сәнгатьлелек-сурәтлелек чаралары буенча күп төрле. Аларның бер телдән икенче телгә күчү мөмкинлекләре дә бертөрле генә түгел: кайберләренең, күргәнебезчә, мәгънәләрен дә, сәнгатьлелек сыйфатларын да тулысынча саклап, икенче телгә күчереп була. Кайберләренең исә тәрҗемә иткәндә мәгънәләре бирелә, сурәтлелек-бизәклелеге югала. Ә кайбер фразеологизмнарга икенче телдә бердәй күчерелмә мәгънә белдерә торган образлы-сурәтле тәңгәллек тә табып булмый: андый очракта оригинал мәгънәсе туры мәгънәсендәге сүз яки сүзтезмә белән белдерелә.

Фразеологизмнарның нинди төрләрен бер телдән икенче телгә төп тәңгәллекләре, ягъни чыганак телдәге мәгънәсе һәм образлылыгы белән күчереп була, нинди төрләрен булмый һәм кайсы очракта оригинал үрнәгендә икенче телдә яңа чара төзергә кирәк, кайсы очракта оригинал фразеологизмын аңа мәгънәсе буенча туры килә торган икенче тел әйтелмәсе белән алмаштырырга туры килә дигән сорауларны ачыклап китү әһәмиятле.

Фразеологизмнарның төп номинатив тәңгәллекләре белән, гадәттә, компонентлары мөстәкыйль мәгънәләрен югалтып бетермәгәннәре һәм үзара нык берекмәгәннәре тәрҗемә ителә. Һәм, димәк, бер тел чараларының икенче тел йогынтысында үсүе дә фразеологизмнарның әнә шундый төрләре исәбенә бара.

Монда бер нәрсәне ачыклап китәргә кирәк. Бер телдә икенче тел фразеологизмыныкы кебек мәгънәле әйтелмә булмаганда һәм ул телдә оригиналның компонентларына төп мәгънәләре белән туры килерлек сүзләр булганда, фразеологизмны тәрҗемә итәргә кирәклеге көн кебек ачык. Еш кына болай да була: чыганак фразеологизмындагыча мәгънәле әйтелмә тәрҗемә телендә дә бар, әмма ул башка төрле образлылыкка корылган. Мондый очракта оригинал әйтелмәсен икенче телгә компонентларының төп тәңгәллекләре белән күчерергәме, әллә ул телнең бердәй

мәгънәле, ләкин икенче образга корылган фразеологизмы белән алмаштырып кына куяргамы дигән сорау туа. Тәрҗемә теориясенә һәм практикасына таянып, бу сорауга болай җавап бирәбез: бер тел фразеологизмын икенче телгә, бердәй мәгънәле, образы башка төрле әйтелмә булса да, номинатив тәңгәллекләре белән (яки кайбер сүзләрен бераз үзгәртеп) күчерергә кирәк. Тәрҗемә теоретигы М. Заверин болай дип яза: «Бер халык тарафыннан икенче телдән тәрҗемә ителгән яки ике телдә дә берьюлы барлыкка килгән мәкаль-әйтемнәрне яңадан тәрҗемә итеп торуның кирәге юк. Ә менә морале – бер, образлар эчтәлеге төрле булганнарын тәрҗемә итәргә кирәк һәм мөмкин, чөнки ул мәкаль-әйтемнәрдә аларны иҗат иткән халыкның күп гасырлар буена тупланган тәҗрибәсе, чынбарлыкны танып белү нәтиҗәсе чагыла». Мисал итеп М. Заверин *рис рассыплешь – собрать можно, слово скажешь, назад не вернёшь* дигән кытай мәкален китерә. Ул мәкальне күчерелмә мәгънәсе, эмоциональлеге буенча аңа тиң *слово не воробей, вылетит – не поймаешь* дигән рус мәкале белән алмаштыру дөрес булмас иде, алай эшләгәндә, мәкальнең милли үзенчәлеге югалыр иде, ди автор.

Татар-рус икетеллелеге практикасы күрсәткәнчә, рус фразеологизмнары, татар телендә андый мәгънәле әйтелмәләр булса да, образлары бертөрле булмаса, калькалаштырып алына. Әйтик, безнең телдә арттырып, күпертеп сөйләү, сүзне, эшне кирәксезгә зурга җибәрү мәгънәсендәге *төймәдән дөя ясау* дигән фразеологизм бар. Рус телендә мондый мәгънәне *из мухи делать слона* дигән әйтелмә белдерә. Тәрҗемә процессында рус фразеологизмын татарча фразеологизм белән алмаштырырга мөмкин булса да, оригиналны тулырак бирү максатында чыганак әйтелмә компонентларының тәңгәллекләре белән тәрҗемә ителә: *чебеннән фил ясау. Посадить в галошу* һәм *төпсез чуманга утырту* фразеологизмнары *кыен хәлдә калдыру* мәгънәсен белдерәләр. Бердәй мәгънәле булсалар да, образлары төрле булганлыктан, русчадан татарчага *посадить в галошу* төп тәңгәллекләре белән күчерелә: *галошка утырту. Палец о палец не ударить* (бернәрсә дә эшләмәү) мәгънәсе татар телендә *кыл да кыймылдатмау* фразеологизмы белән бирелә, ләкин тәрҗемәдә оригинал чарасы чыганак телдәге образлылыкны белдерерлек итеп күчерелә: *бармакны бармакка сукмау.*

Болай бер тел фразеологизмнары үрнәгендә икенче телдә яңа әйтелмәләр ясау мөмкинлекләре зурая. Әйтик, әлегә татар телендәге *бик күп, тыгыз, тулы* мәгънәсен *энә кадарлык та урын юк* дигән әйтем белдерсә, рус телендә андый мәгънәдә *яблоку негде упасть* фразеологизмы йөри. Тәрҗемә процессында яисә гомумән икетеллелек йогынтысында шушы рус әйтелмәсе үрнәгендә татар теленә дә *алма төшәрлек тә урын юк* дигән фразеологик әйтелмә кереп китте. Шулай ук, мәсәлән, рус телендәге *дерево корнями сильно,*

*человек – друзьями* мәкале үрнәгендә татар телендә *агач – тамырлары белән, кеше дуслары белән көчле* дигән яңа әйтелмә ясарга мөмкин. Рус телендә дә татар фразеологизмнары үрнәгендә яңа әйтелмәләр ясала. Әйтик, *кызыл кар яугач* дигән әйтем өлгесе белән *когда красный снег выпадет* дигән фразеологизм ясап булыр иде, хәлбуки рус телендә бу мәгънәдәге *когда на горе рак свистнет* дигән әйтелмә бар, һәм, үз чиратында, бу фразеологизм үрнәгендә татар телендә дә *тау башында кысла сызгыргач* кебегрәк яңа әйтем төзергә мөмкин. Телләрнең үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә фразеологик системаның баюы, үсүе әнә шул рәвештә бара.

Бер телдә икенче тел үрнәгендә яңа фразеологик берәмлек ясаганда, һәрвакыт сүзгә-сүз тәрҗемә итеп кенә уңышка ирешеп булмый, әлбәттә. Яңа әйтелмә чын, камил фразеологизм, ягъни табигый, шома, җыйнак, бизәкле, сурәтле, тәэсирле булсын өчен, күрсәтелгән төрле алымнарны кулланып, кальканы иҗади «эшкәртергә», кабул итеп ала торган тел үзенчәлекләренә яраклаштырырга кирәк.

Мәгълүм булганча, фразеологик әйтелмәләр эмоциональлек, тәэсирлелек дәрәҗәсе, сәнгатьчә эшләнеше буенча бертөрле генә булмыйлар. Бер телдән икенче телгә күбрәк аларның эмоциональлек дәрәҗәсе түбәнрәк, нейтральрәк булганнары күчә. Сәнгатьчә эшләнеше югары дәрәҗәдәгеләрен икенче телдә шундый ук дәрәҗәдә төзү (ә ул шулай булырга тиеш) җиңел эш түгел, һәм бу кайчак барып та чыкмый. Чыганак тел фразеологизмы бик тәэсирле, эмоциональ булып, калькалаштырылганнан соң ул төссезләнеп, көчсезләнеп кала торган булса, яңа әйтелмә төзү уеннан кире кайтып, икенче телнең үзендәге әзер фразеологизмнан (ул икенче образга корылган булса да) файдалану хәерлерәк. Мәсәлән, *бик тәмле* мәгънәсендәге *пальчики оближешь* әйтелмәсен татарчага калькалаштырып ясалган *бармагыңны яларсың* оригиналдагы тәэсирлелеген бирә алмый. Татар теленең үзендә эмоциональ, сурәтле чара – *телеңне йотарсың* фразеологизмы бар, һәм бу очракта *пальчики оближешь*ны шуның белән алмаштырырга кирәк. *До седых волос дожить* әйтелмәсен беренче карашка калькалаштырып була кебек *чәчкә чал кергәнче яшәү* яки *чәче чаларганчы яшәү*. Ләкин бу очракта татар телендәге *ашын ашаган, яшен яшәгән* дигән эмоциональрәк, сурәтлерәк әйтемне куллану һичшиксез уңышлырак булыр иде. Шулай ук, мәсәлән, татар теленең үзендә *ни он, ни йон* дигән әйтем бар икән, *ни рыба, ни мясо* дигән фразеологизмны калькалаштырып алуның кирәге юк, чөнки *ни балык, ни ит* сурәтлелек-бизәклелек ягыннан татар фразеологизмыннан калыша (*ни он, ни йон* рифмага корылган, матур яңгырашлы).

Димәк, бер телдә икенче тел чарасы үрнәгендә яңа фразеологизм ясаганда, аның сурәтлелек-бизәклелек сыйфатлары турында һич кенә дә онытырга ярамый: фразеологик әйтелмә

төшенчәне гади генә итеп атап, битараф фикер генә белдереп калмый, бәлки хисле, тәэсирле итеп, бизәкләп-сурәтләп белдерә, шулай булгач, чит тел өлгесе белән яңа төзелгән әйтелмә дә сәнгатьлелек сыйфатлары буенча үз үрнәгеннән калышмаска һәм кабул итеп ала торган тел ияләре өчен табигый, үз чаралары кебек булырга тиеш.

Фразеологик әйтелмәләрнең компонентлары үзара бик тыгыз береккән һәм мөстәкыйль мәгънәләрен югалтканнары (андый берәмлекләрне **идиомалар** дип атыйлар) икенче телгә төп мәгънәле тәңгәллекләре белән күчерелми. Идиоматик әйтелмәләр рус телендә дә, татар телендә дә күп. Аларның бер өлешен гади сөйләм фразеологизмнары һәм дин-шәригать, мифлар белән бәйләнешле тотрыклы берәмлекләр тәшкил итә. Мисаллар китерәбез:

Рус телендә: *бить баклуши; точить лясы; собаку съел; так себе; куда ни шло; была не была; то и дело; хоть куда; выкидывать кренделя; намылить голову; гнуть в бараний рог; праздновать труса; диву даться; ни в зуб ногой; остаться на бобах; дать крюку; кровь с молоком; нести околесицу* һ.б.

Татар телендә: *бер кашык су белән йотарлык; җиде бабасына җиткү; кырыкмаса-кырык (төрле); тузга язмаган; үз туксаны туксан; авыз суын корыту; түбәсе күккә тию; җиде юл чаты; сангa сукмау; күңел күзе; тетмәсен тетү; ләчтит сату; тырай тибеп йөрү; күз көеге; уҗым бозавы; ис китү; теңкәгә тию; сару кайнату; кот чыгу; җан өшү; җик күрү; ай күрде, кояш алды; агач атка атландыру; иллә мәгәр* һ.б.

Мондый фразеологизмнарны бер телдән икенче телгә компонентларының төп тәңгәллекләре белән күчерергә тырышу нәтиҗә бирми; бу башка телдә аралашучыларга аңлашылмый һәм, әлбәттә, аларда бернинди хис, тәэсир уятмый торган сүзләр җыелмасы гына булып кала. Шунлыктан, идиоматик фразеологизмнарны тәрҗемә иткәндә, оригинал әйтелмәсе мәгънәсе һәм сәнгатьлелек сыйфатлары буенча аңа тиң икенче тел чарасы белән алмаштырыла. Әйтергә кирәк, рус һәм татар фразеологизмнары арасында семантик тәңгәллекләр шактый күп. Мәсәлән: *очки втирать – күз буяу; галду набивать – колак итен ашау; лясы точить – ләчтит сату; ни в зуб ногой – селексәң, бер хәреф тә төшми; для милого дружка и серёжку из ушка – син дигәндә, аяк идәндә; каковы сами, таковы и сани – җиренә күрә җиләге (чиләгенә күрә капкачы); по шерсти кличка – исеменә күрә җисеме; рано пташечка запела, как бы кошечка не съела – иртә кычкырган күкенең башы авырта; плетью обуха не перешибёшь – чебен дулап тәрәзә вата алмый; входящее в уста не оскверняет – ризыкның языгы юк; что было, то быльем поросло – буласы булган, буявы уңган; похож ежа в ежу – ике тиен бер акча; в нужде и кулик соловьём свищет – башыңа төшкәч, башмакчы булырсың; долг платежом красен – кунак ашы кара-каршы; мал золотник, да дорог –*

*кечкенәнең эче тулы төш кенә; с песни короткий спрос – җырның ертыгы юк* һ.б.

Ике тел белән эш итүче журналистларга фразеологизмнар өлкәсендә шуны да белү әһәмиятле: бер телдәге идиоматик (специфик) әйтелмәләрнең икенче телдә барысының да семантик тәңгәллекләре булмый. Мәсәлән, рус телендәге *нашла коса на камень; купить кота в мешке; из рук вон; как пить дать; не в своей тарелке; наломать дров; бузу тереть; держать в ежовых рукавицах; не так норовим, чтоб в рот, как чтобы в карман* кебек фразеологизмнар, татар телендәге *алып мактарлык, салып таптарлык түгел; ай күрде, кояш алды; уң аягын атлаганчы, сул аягын эт ашый; типсә тимер өзәрлек; акылың алтын икән; өлешенә тигән көмеше; серкәсе су күтәрми; сөйкемле сөяк* кебек әйтелмәләр шундый бер телгә генә хас, семантик тәңгәллексез идиомалар исәбенә керә.

Мондый әйтелмәләрне тәрҗемә итү компенсация алымы белән башкарыла. Әйтик, бер урында *из рук вон* дигән тотрыклы әйләнмәне *бик начар* дип гади сүзтезмә белән тәрҗемә итәбез икән, икенче бер урында *красивый* дигән гади сүз мәгънәсен фразеологизм белән *сөйкемле сөяк* дип бирәбез. Нәтиҗәдә тәрҗемә, гомумән алганда, оригиналга якын, тулы кыйммәтле булып чыга. Компенсация бер текст эчендә һәм бер персонаж сөйләмендә генә булырга тиеш.

Татар-рус икетеллелеге шартларында тәрҗемә практикасында рус теленең тотрыклы әйтелмәләре үрнәгендә татар телендә уңышсыз, ясалма фразеологизмнар төзү очраклары бар. Бу, нигездә, ике тел фразеологизмнарының үзенчәлекләрен белеп бетермичә, чыганак тел әйләнмәсенең компонентларын ялгыш безнең телгә аларның төп мәгънәле тәңгәллекләре белән генә күчерү аркасында килеп чыга. Чыганак тел әйләнмәсен калькалаштырганда, аны икенче тел фразеологизмнарының табигатенә яраклаштырып шомартмыйлар, «эшкәртмиләр». Бу өлкәдә кайбер газета-журналлардагы җитешсезлекләрне аерым-аерым карап китик:

1. Кайбер мәкаль-әйтемнәргә кыскалык, шомалык, аһәңлелек җитми, артык сүзләр кулланыла: *эт өреп арыса да, бүре йөреп туктамас – собака лаять устанет, а волк ходить не перестанет (эт өрер, бүре йөрер* кирәк); *өеңдә нәрсә булганын күршедән чыгып сора – о своих делах узнавай всегда у соседа (өеңдәген күршедән сора* кирәк); *нинди сәлам бирсәң, шундый җавап алырсың – каков привет, таков ответ (соравы нинди, җавабы шундый* яки *соравына күрә җавабы* кирәк); *кемгә күп бирелгән, шуңардан күп сорала да – кому много дано, с того и спросится (күп бирелгәннән күп сорала да* кирәк).

2. Күчерелмә мәгънәсе татар кешесенә аңлашылмый торган, ят, сәер әйтелмәләр барлыкка килә: *авызың сары бит әле синең – рот ведь жёлтый ещё у тебя; кем үзен кыю тота, шул пуля йота – кто смел, тот пулю съел; берәүләр карбыз ярата, икенчеләре – дуңгыз кимерчәге –*

*один любит арбуз, а другой – свиной хрящик* (*җаны теләгән елан ите ашаган* дип әйтергә була); *җимешне таный икән үзе – губа не дура; борыныңа киртләп куй – заруби себе на носу* (татарча *колагыңа киртләп куй* диләр); *башыннан алып үкчәсенә кадәр – с головы до пят* (татарлар *башыннан аягына кадәр* диләр); *турылык күзне төртә – правда глаза колет; җиде бәлагә бер җавап – семь бед – один ответ; чиста суга чыгару – выводить на чистую воду.*

*Менә сиңа, әби, Юрий көне! – Вот тебе, бабушка, Юрьев день!* әйтелмәсенең хәрефкә-хәреф тәрҗемәсе – уңышсыз тәрҗемә.

*Була шундый сәфәрләр:* ***ак көнләшү*** *белән көнләшеп, шул ук вакытта гарьләнеп кайтасың.* Мондагы *ак көнләшүне* русчага тәрҗемә итеп карап кына аңларга мөмкин. *Ак көнләшү* татар теле өчен табигый әйтелмә түгел.

*Күсәк белән оҗмахка кумыйлар.* Бу фразеологизм да аңлашылмый һәм татарча сәер яңгырый.

*Кулны йөрәккә куеп әйткәндә... (положа руку на сердце* фразеологизмыннан; татарча табигый түгел).

*Эшчеләр, ниһаять, хезмәт хакына* ***тере акча*** *ала башладылар. Тере акча* татарча сәер яңгырый: аны төшереп калдырып, *Хезмәт хакын акчалата ала башладылар* диярргә була.

*Хәзер «Ока»ның яңа* ***йөзе өстендә эшлиләр*** (*йөзе өстендә эшләү* – уңышсыз калька).

Хәзерге икетеллелек шартларында татар һәм рус телләренең фразеологизмнарын чагыштырып өйрәнү зур теоретик һәм практик әһәмияткә ия.

***Йосыпов Рүзәл Габдуллаҗан улы,***
*филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы*

УДК 811.512.145´342

***Т.И. Ибраһимов, М.Р. Сәйхунов***

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР СӨЙЛӘМ ТЕЛЕ: СУЗЫК АВАЗЛАР СОСТАВЫ

В работе с применением методов фонологической оппозиции и дистрибутивного анализа уточняется состав гласных фонем татарского разговорного языка. В рамках учения Бодуэна де Куртенэ о фонетических изменениях в языке объяснены особенности частотного распределения отдельных гласных фонем.

**Ключевые слова:** татарский язык, фонема, речевой звук, система гласных, дистрибуция, квазиомоним, аллофон, контекст, артикуляция.

Бүгенге фәндә, лингвистика – тел ярдәмендә хәбәрләшүне өйрәнә торган фән, дип йөртелә. Шушы билгеләмәгә нигезләнеп әйткәндә, фонетика хәбәрләшүнең төп формасын тәшкил иткән сөйләм эшчәнлеген (речевая деятельность) өйрәнә. Сөйләм эшчәнлеге, икенче төрле әйткәндә, мәгълүмат алмашу, сөйләүче, тыңлаучы һәм билгеле бер физик берәмлекләр системасы катнашында башкарыла. Тел белемендә сөйләүченең авазлар тудыру эшчәнлеге – артикуляцион фонетикада, сөйләүче тудырган тавыш дулкыннары системасы – акустик фонетикада, тыңлаучының ишетү әгъзалары эшчәнлеге перцептив фонетикада өйрәнелә.

Физик-физиологик планда, ягъни тавыш дулкыннары, артикуляция һәм ишетү әгъзаларының эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, татар сөйләм теле шактый дәрәҗәдә өйрәнелгән. Ә менә физик берәмлекләр системасын лингвистик планда, мәгънә аеру үзенчәлекләренә бәйләнештә тикшерү тиешле дәрәҗәдә башкарылган дип әйтеп булмый. Тәкъдим ителгән хезмәт шушы хәлне күздә тотып башкарыла. Аның максаты – алда торган мәсьәләләрне ачыклау, лингвистик аспектта татар сөйләм теленең сузыклар составын һәм системасын барлап чыгу.

Сөйләм авазлары системасы ике төрле – буынлы (сегмент) һәм буынсыз (суперсегмент – буынлы авазлар өстенә өелә торган) берәмлекләрдән тора. Буынлы берәмлекләр, ягъни бер-бер артлы тезелеп килгән авазлар үзара бәйләнгән булсалар да, әйтелешләре һәм яңгырашлары белән нык аерылалар. Буынсыз берәмлекләр дигәндә, басым, интонация төрләре күздә тотыла. Алар йогынтысында буынлы авазлар тезмәсенең мәгънә төсмере үзгәрергә яки яңа эчтәлеккә күчергә дә мөмкин.

*Әни, әти* сүзләре [н] һәм [т] тартыклары ярдәмендә аерымланалар. *Саламы* (исем), *саламы* (фигыль) сүзләре аерым әйтелгән очракларда бер-берсенә буынсыз берәмлек, ягъни фраза басымы (аерым әйтелгән сүзләр фразага хас басымда яңгырыйлар) ярдәмендә каршы куелалар. Шуңа охшаш хәлгә тыңлаучы «*Хәмидә әби күршесе Минзифаның*

*киленен ошатмады»* җөмләсендә дә юлыгырга мөмкин. Пауза *«әби»* сүзеннән соң күзәтелсә, *«Минзифаның киленен»* Хәмидә әби үзе, ә инде *«күршесе»* сүзеннән соң күзәтелсә, Хәмидә әбинең күршесе ошатмаган булып чыга.

Сөйләм теленең мәгънә аеру чаралары, билгеле, бу әйтелгәннәр белән генә чикләнми. Сүзләрнең морфологик структурасы, авазлар, иҗекләр, сүзләрнең кулланылу ешлыклары, позицияләре, бер-берсе янәшәсендә килү яки килә алмау үзенчәлекләре – телне сыйфатлау белән бергә мәгънәләр белдерү вазифаларын да башкаралар.

Лингвистикада сөйләм фонетика һәм фонология тармакларында тикшерелә. Фонетика – сөйләмнең авазлар тышчасын (звуковая оболочка) артикуляцион, акустик һәм лингвистик аспектлардан чыгып өйрәнүче фән. Максатта бәян ителгәнчә, мәкаләдә бары тик татар сөйләм теленең сузык авазлар системасын ачыклау, сузыкларның фонемалар алфавитын төзү күздә тотыла.

Фонетика фәненең нигез берәмлекләре – аваз һәм фонема. Сөйләм авазы – мәгънә аеруда сөйләүче файдаланган иң кечкенә фонетик берәмлек. Димәк, аваз – ул индивидуаль һәм материаль сыйфатларга ия берәмлек. Шуның белән бергә авазлар, телнең төп функциясе булган мәгълүмат тапшыру вазифасын да башкаралар. Димәк, авазлар индивидуальлек сыйфаты белән бергә иҗтимагыйлык сыйфатына да ия булалар.

Лингвистик аспектта, ягъни сөйләм телен мәгълүмат тапшыру чарасы буларак өйрәнү, фонология фәнендә башкарыла. Әмма фонетиканы сөйләмгә генә кайтарып калдыру шулай ук дөрес булмас иде. Сөйләм вакытында кешеләр бер-берсе белән мәгълүмат алышалар һәм әлеге мәгълүмат билгеле бер мәгънәләргә ия булган аваз тезмәләре – сүзләр – ярдәмендә тапшырыла. Ягъни хәбәрләшүне мәгънә аеруда мөһим роль уйнаган авазлар һәм суперсегмент берәмлекләр тәэмин итә.

Кыскасы, бүгенге фонетикада «аваз»ны мәгънә аеру процессына бәйләп, ягъни «фонема» хөкемендә лингвистик аспекттан чыгып, өйрәнү дә кабул ителгән. Әмма бу очракта, «аваз» һәм «фонема»ның функцияләре бер үк икән, дип аңларга ярамый. Югарыда әйтелгәнчә, сөйләм ярдәмендә кешеләр фикер алмашалар. Бу процесста тыңлаучы һәрбер әйтелгән сүзнең мәгънәсен аларның авазлар тышчасын тәшкил иткән һава дулкыннары аша гына танымый. Дөресрәге, ул моны эшли алмый. Мисал өчен, сөйләмдә *кул* сүзе әйтелгән дип фараз кылыйк. Әгәр тыңлаучы сүзләрнең мәгънәсен авазларны берәм-берәм аерымлап таный торган булса, ул түбәндәгечә эш итәргә тиеш була:

– t мизгелендә [к] тартыгын үз хәтерендә сакланучы авазлар белән чагыштырып аның [к] булуын танырга,

– t+1 мизгелендә ул [у] авазын ишетергә, аны хәтерендәге башка авазлар белән чагыштырып, [у] сузыгы икәнен танырга,

– t+2 мизгелендә шул ук ысул белән [л] авазын танырга, һәм, ниһаять,

– t+3 мизгелендә дүртенче берәмлекнең пауза булуын танып, *кул* сүзенең *кол, кыл, кал* түгеллеген ачыкларга тиеш.

Тасвирланган процесс сөйләмне ишетеп тануның бердәнбер чарасы сыман. Әмма чынбарлыкта ул үтәлми. Сөйләм танучы (сөйләмне язма формага күчерүче) системалар төзү буенча уздырылган экспериментлар тел иясенең сөйләмдә яңгыраган авазларны бер-бер артлы ишетеп танып бара алмавын күрсәттеләр. Аның сәбәпләре берничә. Беренчедән, сөйләмдә сүзләр һәм аларны тәшкил иткән авазлар төрлечә яңгырыйлар, еш кына алар әйтелми дә калалар. Мәсәлән, *Ботка ашап утыра* җөмләсе *боткашып утыра,* ә *тары алмады* сүзтезмәсе *таралмады* формасында да яңгырарга мөмкин.

Икенчедән, тыңлаучыга сөйләм авазларын берәм-берәм танып бару өчен сөйләм тизлеге секундына 15–20 аваздан артмаска тиеш була. Чынбарлыкта исә ашыгып сөйләүләрдә ул тизлек секундына 30–40 авазга да житәргә мөмкин [Златоустова, Потапова, Потапов, Трунин-Донской, 1997, б. 126].

Кыскасы, хәбәрләшү процессында сөйләм артикуляцияләнү этабында да, ишетелү этабында да авазларга таркалмый. Озак еллар сөйләм телен автоматик рәвештә тану (распознавание речи), язма телне сөйләмгә күчерү (синтез речи) мәсьәләләрен чишү өлкәсендә хезмәт иткән танылган галим Дж. Фланаган сөйләмне авазлар тышчасы буларак авазларга таркатуның мөмкин булмавын тасвирлап, сөйләмдә лингвистик берәмлекләрне тану бу телгә хас контекстлар төзелешен, грамматик һәм семантик закончалыкларны белүгә нигезләнгән. Тавыш дулкыннары сурәтендә авазлар чигенең табылмавына ышану өчен күп булмаган сандагы спектрограммаларны күзәтеп чыгу да житә, дип белдерә [Фланаган, 1968, б. 211].

Димәк, хәбәрләшү өчен зарури булган сөйләмне тану шөгыле акустик яки физиологик чараларга түгел, ә бәлки сүзләрне морфемаларга бүлүдә файдаланылган ысул – мәгънәләргә таянып башкарылырга тиеш була. *Юлчы, эшче, хезмәтче, балыкчы* кебек сүзләр икегә – нигез сүзләргә (юл, эш, хезмәт, балык) һәм «эш башкаручы» мәгънәсен белдергән (-чы/-че) суффиксларына бүленәләр. Аларны бүлүче фактор тышкы охшашлык түгел, ә мәгънәләр аермалыгы: -чы/-че кушымчалары бары тик нигез морфеманы «эш башкаручы» итеп таныткан очракта гына суффикслар буларак аерымланалар. *Мәче, кайчы* сүзләрендә алар бу функцияне үтәмиләр һәм сөйләмдә тыңлаучы тарафыннан аерымланмаска да мөмкиннәр [Ибрагимов, Сайхунов, 2015]

Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы бөек галим Иван Александрович Бодуэн де Куртенэ фонетика фәнен, бер яктан, тел, авазлар системасын физик-физиологик аспектта; икенче яктан, лингвистик аспектта өйрәнүче гыйлем дип саный. Икенче планда, ягъни авазлар системасының яратылуын, тарихи үзгәрешен, мәгълүмат алмашуны өйрәнүгә караган фонетика

тармагын, ул психофонетика дип исемли [Бодуэн де Куртенэ 1963]

Психофонетика тәгълиматында фонема – ул телнең морфологиясе, сүз ясагыч формалары төзелү процессында барлыкка килгән телнең мәгънәле берәмлекләрен, морфемаларны, аеруда файдаланылучы аваз берәмлеге. Бодуэн де Куртенэ тәгълиматы аспектында татар сөйләм теле системасы, беренчедән, артикуляция һәм ишетү механизмнарының хезмәтен җиңеләйтүне, икенчедән, аморф хәлдә яшәгән тамыр сүзләрне гармонияле (сингармонизмга буйсынган) сүзформаларга күчерүне, өченчедән, «Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел», «Сүзең көмеш булса, тыңлап утыруың алтын», «Әйткән сүз – аткан ук», «Мулла барда, телеңне тый, оста барда кулыңны тый» кебек гыйбарәләрне күздә тотып төзелгән система тәшкил итә.

Әйтергә кирәк, татар телен өйрәнү тарихы гасырдан артык дәвам итсә дә, аның фонетик һәм фонологик төзелеше җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелгән дип әйтеп булмый. Моны берникадәр күләмдә татар теле фонетикасында күзәтелгән фикер төрлелеге дә раслый. Түбәндәге таблицада китерелгән мәгълүматлар шуның бер дәлиле булып тора.

*Таблица 1*

Галимнәр хезмәтендә фонемалар санының төрлелеге

| Авторлар | Год | Фонемалар | |
|---|---|---|---|
| | | Сузыклар | Тартыклар |
| Радлов В.В. | 1883 | 11 | 23 |
| Каюм Насыйри | 1895 | 10 | 23 |
| Гыйбад Алпаров | 1927 | 5 (10 аваз) | 23 |
| Богородицкий В.А. | 1953 | 10 | 25 |
| Шакирова О.Ф. | 1954 | 12 | 28 |
| Сәлимов Х.Х. | 1993 | 12 | 28 |

В.В. Радлов Татар телен төрки телләргә хас диалектлар нигезендә өйрәнә. Дилектларның берсендә ул ике төрле [а] һәм [ә] авазларын таба [Radloff, 1883]. Бер төрле [а] һәм [ә] авазларын, В.В. Радлов күзаллавынча, сүзләрнең тамырында һәм кушымчаларында кулланырга мөмкин булса, икенче төрле [а] һәм [ә] авазлары бары тик сүзләрнең тамырында гына күзәтеләләр. Безнең карашка, икенче очракта сүз иренләшкән [а] һәм [ә] авазлары хакында бара.

Таблицаның икенче, өченче һәм дүртенче юлларында күрсәтелгән 10 сузыкның берсе [ый] авазы. Галимнәр татар телендә [а], [ә], [о], [ө], [у], [ү], [ы], [е], [и] сузыклары белән бергә [ы̄ (ый)] сузыгы булуын тәгъбир

итәләр. Аның сәбәбе гарәп графикасы нигезендәге иске татар язуында [ый] авазын белдергән «йай» (ى) хәрефенә бәйләп аңлатыла (*килде, калды* кебек сүзләр *килди, калдый* формасында укылганнар).

Татар сөйләм телен җәмгыять тарафыннан эшкәртелгән авазлар системасы буларак өйрәнү үрнәге Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучыларның берсе – В.А. Богородицкий хезмәтләрендә ачык чагылыш таба. В.А. Богородицкий 1881–1884 елларда Казанда эшләп килгән «Татар укытучылар мәктәбе»ндә рус теле укыта. Бер үк вакытта татар укучыларының рус телендә сөйләше белән бәйле күзәтүләр алып бара, аларның татар телендәге сөйләшендә рус алынмаларының әйтелешен өйрәнә.

Диалектология термины белән әйткәндә, В.А. Богородицкий татар теле авазлар системасын ачыклауны «Кыр лингвистикасы» («Полевая лингвистика)» алымнары ярдәмендә башкара. 1930 нчы елларда җыелган материалларын фәнни эшкәртеп, сөйләм тел авазлар системасын гәүдәләндергән хезмәтләр бастырып чыгара [Богородицкий, 1933; 1953]. Татар теленең В.А. Богородицкий хезмәтләрендә гәүдәләндерелгән авазлар системасы җәмгыять тарафыннан эшкәртелгән. Галим аны хаклы рәвештә халык теле (народный говор) дип атый.

В.А. Богородицкий тәгълиматында татар сөйләм теленең сузык авазлар (фонемалар) составы түбәндәге 10 сузыктан – [а], [о], [у], [ы], [ә], [ө], [ү], [е], [и], [і (ый)] сузыкларыннан тора. Чынлыкта ул 9 сузык таба. [і (ый)] сузыгын галим гарәп хәрефләре белән язылган *чәчте, урды* кебек сүзләрнең *чәчти, урдый* формасында язылышы һәм *чәчти, урдый* дип укылышы тәэсирендә фонемалар рәтенә кертә. Чынлыкта В.А. Богородицкий сүз азагында килгән [ы] авазын шулай ук сүз азагында килүче [и] авазы белән оппозиция мөнәсәбәте төзүче дифтонг итеп карый.

Таблицаның бишенче һәм алтынчы юлларында күрсәтелгән галимнәр тәгълиматында сузык фонемаларның саны өчкә арта. Бу, билгеле, очраклы хәл түгел. XX гасырның 50–60 нчы елларында фонетика белемендә авазларның фонема булу-булмавын квазиомонимнар ярдәмендә ачыклау гадәткә керә. Бу метод буенча, әгәр пар сүзләр бары тик бер аваз белән аерылалар икән, бу авазлар фонемалар булып саналалар. Мәсәлән, *кол – кыл* парында, [о] һәм [ы] авазлары, *сал – сул* парында [а] һәм [у] авазлары бер үк позициядә һәм бер үк контекстта киләләр. Димәк бу очракларда [о], [ы], [а], [у] авазлары мәгънә аеру вазифасын үтиләр һәм фонемалар булып саналалар.

Шушы алым ярдәмендә 1950 елларда татар телендә *тōл* (взрывчатка) – *тол* (вдова), *сэр* [сēр] (уважительное обращение) – *сĕр* (секрет) парларын каршы куеп киң әйтелешле [ō] һәм [ē/э] фонемалары табыла [Шакирова, 1954].

1980 елларда шундый ук ысул белән, ягъни *сы̄р* (ашамлык) – *сыр* (складка) сүзләрен, квазиомонимнар буларак каршы куеп, телнең сузык авазлар

составына киң әйтелешле [ы̄] фонемасы кертелә [Сәлимов 1989].

Беренче карашка галимнәр хаклы да сыман. Фонемаларның төп вазифасы – сүзләрнең мәгънәсен аеру. Табылган фонемалар бу вазифаны башкаралар. Әмма җентекләбрәк караганда аларны фикерендә аерым каршылыклар күзәтелә.

Беренчедән, күзәтелгән квазиомонимнар сузыклар белән генә түгел, тартыкларның сыйфаты белән дә аерылалар. Мәгълүм булганча, иҗек – иң кечкенә сөйләм берәмлеге – бербөтен тәшкил итә. *Тōл* сүзендәге [о] авазының киң әйтелеше [т] һәм [л] авазларына да йогынты ясамый калмый. Л.Р. Зиндер фикеренчә, телдә квазиомоним парларның табылуы аларның бары тик бер аваз белән аерымлануына ышанычлы дәлил була ала шул очракта гына, әгәр ул сүзләр рус теленең *а* һәм *и* теркәгечләре кебек бер фонема тәшкил итсәләр [Зиндер, 2007, б. 86].

Икенчедән, квазиомонимнар методына таянып сүзнең мәгънәсен ачыклау аның һәр авазын эзлекле рәвештә танып баруны күздә тота. Югарыда *кул* сүзе мисалында аның мөмкин түгеллеге инде тәгъбир ителде.

Әмма квазиомонимнар методы ярдәмендә фонемалар табуның төп җитешсезлеге болар түгел, ә бәлки бу методны механик рәвештә файдалануда.

Әйтергә кирәк, квазиомонимнар ярдәмендә телләрнең фонемалар составын билгеләү шактый киң таралган, билгеле бер күләмдә ул бүген дә файдаланыла. Метод гади һәм конструктив. Ул авазның мәгънәләр аеру (аера алмау) мөмкинлеген дә тиз ачыклый. Әмма авазның фонема хасил итү-итмәвен исбатлау өчен аның мәгънә аеру сыйфатына ия булуы гына җитми. Дөрес әйтелмәгән яки кайсыдыр чит телдән кергән сүзләр дә очраклы рәвештә ниндидер мәгънә билдерергә һәм квазиомоним төзергә мөмкин.

Тел төзелеше, кайсы гына берәмлекләр югарылыгында тикшерелмәсен, үзенчәлекле система тәшкил итә. Сүзләр биеклегендә төзелгән тел системасы сүзлек һәм ул сүзләрнең янәшә килү (килә алмавын) тәгъбир иткән кагыйдәләрдән торса, авазлар (фонемалар) югарылыгында гасырлар дәвамында төзелгән тел системасы авазлар һәм аларның бер-берсе белән янәшә килү мөмкинлекләрен чагылдырган закончалыклардан тора.

Квазиомонимнар составындагы капма-каршылык (контрастлык) барлыкка китерүче авазларның тел системасы өчен ят булмавы – телнең башка авазлары белән парадигматик һәм синтагматик мөнәсәбәтләргә керү мөмкинлеге ачыкланырга тиеш. Гомуми тел белемендә бу мәсьәлә, гадәттә, дистрибуция методы ярдәмендә чишелә. Дистрибуция (*distribute* – бүлү, тарату).

Тел белемендә теге яки бу берәмлекнең (аның сыйфатының) дистрибуциясе – ул шушы берәмлекне эченә алган контекстлар күплегеннән тора [Лайонз Джон, 2004]. Мәсәлән, [а] сузыгының дистрибуциясе аның алдыннан һәм артыннан килүче авазлардан тора, ягъни ул $C_1$ –

[а] – $C_2$берәмлекләренең суммасын тәшкил итә. Биредә $C_1$ – [а] авазы алдыннан килүче, $C_2$ – [а] авазы артыннан килүче тартыкны (C-consonanta) белдерә.

Дистрибуция анализы аваз (фонема, сүз) эргәсендәге берәмлекләрне санап чыгу белән генә чикләнми. Күп очракта галимнәрне тел берәмлекләренең бергә килү мөмкинлегеннән тыш аларның бергә килү ешлыгы да кызыксындыра. Шуны күздә тотып кыскача дистрибуция тәгълиматына тукталып үтәбез.

Тел – билгеле бер система тәшкил итә. Һәрбер тел берәмлеге, аеруча авазлар, сүзләр чикләнгән күләмдәге шундый ук берәмлекләр эргәсендә (контекстында) киләләр. Алда сөйләм берәмлекләренә хас булган контекстлар нигезендә кайбер авазларда күзәтелгән сыйфатларның фонетик яки фонематик үзенчәлек булуын исбатлау күздә тотыла. Башта кыскача дистрибуция төрләрен (модельләрен) ачыклап үтәбез.

1. Әгәр кайсыдыр бер авазның контекстлар күплеге (дистрибуциясе) икенче бер авазның контекстлар күплегенә (дистрибуциясенә) тигез булса, алар эквивалент дистрибуцияле берәмлекләр дип аталалар. Икенче төрле итеп әйткәндә алар бер үк мәгънәгә ия булалар, ягъни синонимнар барлыкка китерәләр.

Мисал өчен, [в] һәм [w] авазлары бүгенге татарлар сөйләмендә бертигез диярлек дәрәҗәдә файдаланыла. Берәүләр бу авазлар кергән сүзләрне [w] белән, икенчеләр (татарча сөйләшүгә язма тел нигезендә өйрәнүчеләр) [в] белән әйтәләр. Мондый очракларның лексик берәмлекләр яссылыгында да күзәтелүе мөмкин. *Әмма* һәм *ләкин* сүзләре, мәсәлән, шулай ук язма телдә бер үк контекстларда күзәтеләләр, ягъни эквивалент дистрибуцияле берәмлекләр тәшкил итәләр.

2. Әгәр ике тел берәмлеге, әйтик А һәм Б берәмлекләренең уртак контекстлары булмаса, бу очракта алар өстәмә дистрибуцияле берәмлекләр буларак өйрәнеләләр. Мисал итеп [а] һәм [ә] авазларының контекстлар күплеген күрсәтергә мөмкин. Аларның икесе дә барлык тартыклар контекстында күзәтелергә мөмкин. Әмма [а] контекстлар күплеге калын тартыклар төркеменнән, [ә] авазының контекст күплеге нечкә тартыклар төркеменнән тора. Ул төркемнәр үзара кисешмиләр, ягъни [а] һәм [ә] авазлары өстәмә дистрибуцияле берәмлекләр хасил итәләр.

3. Әгәр А берәмлегенең контекстлар күплеге Б берәмлегенә хас контекстлар күплегенең бер өлешен тәшкил итсә, бу очракта А һәм Б берәмлекләре керешкән дистрибуцияле берәмлекләр дип аталалар.

4. Әгәр А берәмлегенә хас контекстлар күплегенең бер өлеше Б берәмлегенең контекстлар күплегендә табылса, А һәм Б берәмлекләре өлешчә тәңгәл дистрибуцияле берәмлекләр тәшкил итәләр.

Тел белемендә эквивалент дистрибуцияле берәмлекләр күп очракларда иректе алмашынуга лаек берәмлекләр дип аталалар. Татарлар сөйләшендә *вагон* сүзенең *wагун*, *даwыл* сүзненең

*давыл* формаларында әйтелүе мәгънә аңлауда кыенлык тудырмый. Димәк [w] һәм [в] авазлары татар телендә ирекле алмашыну сыйфатына лаек берәмлекләрн тәшкил итәләр.

Дистрибуция тәгълиматы нигезендә киң әйтелешле [ы̄], [о̄], [е̄/э] сузыкларының телнең фонетик системасына хас булу-булмавын ачыклап үтик. Югарыда телгә алынганча, телчеләр *то̄л – тол*, *сэр* (*се̄р*) *– сёр* һәм *сы̄р – сыр* сүзләрен каршы куеп сузыклар составында киң әйтелешле [о̄] һәм [е̄(э)], [ы̄] фонемаларын табалар. Хаклымы соң бу? Күрсәтелгән фонемалар татар теленең авазлар системасына үзме?

Башта татар теле өчен үз булган [о] авазына күз салыйк. Беренчедән, *тол* сүзе татар телендә *то̄л* белән генә түгел, ә *тал, тул* сүзләре белән капма-каршылык (контрастлык) мөнәсәбәтләре төзи һәм аерымлана. Икенчедән, ул [р], [з], [й] авазларының алдыннан һәм [к], [с], [б], [й] авазларының артыннан килергә, комбинаторик мөнәсәбәтләрдә күзәтелергә мөмкин. Өченчедән, тар әйтелешле [о] авазы *тол, тоз, тор, той* сүзләрендә күзәтелгән контрастлык мөнәсәбәте нигезендә [л], [з], [р], [й] авазларын аеруда катнаша. Тар әйтелешле [о] авазының татар тел системасы өчен үз булуын яклап китерелгән дәлилләрне, [ы] һәм [е] авазларына карата кабатлап тормыйбыз.

Югарыда бәян ителгән схемада киң әйтелешле [о̄] авазының татар теленең фонетик системасында файдаланылу мөмкинлегенә күз салыйк. Киң әйтелешле [о̄] авазы тар әйтелешле [о] бәрабәрендә контрастлык һәм комбинаторик мөнәсәбәтләр төзергә сәләтле түгел. Аның башка авазлар белән комбинатор бәйләнешкә керү мөмкинлекләре дә, *тол, тоз, тор, той* фомаларында [л], [з], [р], [й] тартыкларын аеру мөмкинлекләре дә нык чикләнгән, юк хәлендә. Дистрибуцияләр тәгълиматында бу очрак өстәмә дистрибуцияле берәмлекләр мөнәсәбәтен гәүдәләндерә. Киң әйтелешле [о̄] авазының контекстлар күплеге аның эргәсендә килгән [т] һәм [л] авазлары белән чикләнгән. Бу очракта киң әйтелешле [о̄] авазы бары тик тар әйтелешле [о] авазының кайсыдыр аллофонын тәшкил итә.

Дистрибуция кысаларында [ы̄] һәм [е̄] авазларының контекстлар күплеген өйрәнү дә шундый ук нәтиҗәгә китерәчәк. Һәм бу гаҗәп тә түгел. Татар теленең авазлар системасына киң әйтелешле (авызны киң ачып әйтелә торган) сузыклар хас түгел. Аерым бер сүзгә таянып (ул ничек кенә еш кулланмасын) тел системасын үзгәртеп булмый. Бу хакта В.А. Богородицкий югарыда телгә алынган китабында да, татар теленә киң әйтелешле сузыклар хас түгел, дип әйтеп калдырган.

Татар теленең сузыклар системасы тел тамырының авыз (бугаз) куышлыгына күчү дәрәҗәсенә, тел аркасының каты аңкауга якын (ерак) тартылу дәрәҗәсенә һәм иреннәрнең артикуляциядә катнашу (катнашмавына) корылган. Авызның киң (тар) ачылуы татар теленең

авазларын аеруда роль уйнамый. Татарлар сөйләмендә авызны киң итеп ачу тавышны көчәйтү, ягъни просодик планда гына файдаланырга мөмкин.

Татар теленең сузыклар системасын тирәнтен өйрәнгән В.А. Богородицкий болай дип яза: «Так как звуковая система каждого языка представляет не простое собрание звуков, но гармонически связанное целое, то вполне естественно, что те или иные свойства гласных могут быть родственны со свойствами звуков согласных...» [Богородицкий, 1953, б. 39].

Бүгенге көндә телдә бары тик бер аваз белән аерымланучы мәгънәләрнең (квазиомонимнарның) очрау ихтималлыгы арта бара. Татар телендә дә алар еш очрыйлар. Кыскасы, бу метод белән эш иткәндә, *сан* (число) – *сан* (дәрәҗә), *тир* (пот) – *тир* (стрельбище), *тур* (место) – *тур* (дикая коза), *тол* (вдова) – *тол* (взрывчатка) һ.б. сүзләрне берберсенә каршы куеп, татар телендә ике [а], [и], [у] фонемалары да табылырга мөмкин.

Югарыда китерелгән формада квазиомонимнар методын дистрибуцияләр методы белән тулыландырып, икенче төрле итеп әйткәндә, авазларның парадигматик һәм синтагматик системалар төзүен истә тотып телнең фонемалар составын билгеләгәндә, татар теленең сузыклар системасы түбәндәге фонемаларга нигезләнә: [а], [ә], [ы], [е/э], [у], [ү], [о], [ө], [и]. Күрсәтелгән сузыклар, телнең тартык авазлары белән берлектә, кешелек мәдәниятен татар телендә тасвирлау өчен зарури һәм җитәрлек система тәшкил итәләр. Моңа интернетта китерелгән «Язма татар теле корпусы» [Письменный корпус..., 2012] дәлил булып тора.

Авазлар сузык һәм тартыкларга бүленәләр. Телләрдә, кагыйдә буларак, тартыклар сузыкларга караганда күбрәк була. Тартыклар санының сузыклар санына чагыштырмасы консонантлар константасы (К) дип йөртелә. Консонантлар константасы (К) алфавит нигезендә һәм текстлар нигезендә табылырга мөмкин. Мәсәлән, татар теленең алфавиты нигезендә үлчәнелгән константлар константасы Ка=25/9= 2,7 гә тигез була. Константлар константасын авазларның текстларда күзәтелүеннән чыгып үлчәгәндә, ул = 1,37 тигез була. Бу константаларның икенчесе (Кт) зуррак әһәмияткә ия. Әгәр текстта тартыклар Кт чагыштырмасы 1,5 тән азрак булса, андый сөйләм системасы тартыклар белән туелдырылмаган, ә инде 1,5 тән зуррак булса, тартыклар белән туелдырылган тел дип исәпләнә.

Күренә ки, татар теле тартыклар белән туелдырылмаган, сузыклар белән тартыклар чиратлашып киләләр. Иҗек эчендә ике тартыкның бергә килү очраклары бик сирәк, ә өч тартыкның (контракт, страх) бергә килү очраклары бөтенләй күзәтелми.

Икенче таблицада сузыкларның телдә нинди ешлык белән сүз башында, сүз азагында кулланылу ихтималлыклары күрсәтелгән. Татар теле күп гасырлар дәвамында Урал-Алтай, финугыр телләре йогынтысында

формалашкан. Бу телләрнең уртак ядкәрләреннән берсе Орхон-Енисей язмалары V–VI гасырларга карый. Бүгенге татар телен шул язмалар белән чагыштырганда ул зур үзгәрешләргә юлыккан. Хәзерге вакытка кадәр сакланып килгән Урал-Алтай һәм төрки телләр арасында татар теле, галимнәр әйтүенә караганда [Җәләй, 2000], бик зур үзгәрешләр кичергән.

*Таблица 2*

Сузык авазларның сөйләм телендә, сүз башында һәм сүз азагында кулланылу ихтималлыгы

| Фонема | Очрау ешлыгы | Сүз башы | Сүз азагы |
|---|---|---|---|
| а | 0,113 | 0,107 | 0,179 |
| ә | 0,072 | 0,053 | 0,233 |
| е(э) | 0,068 | 0,039 | 0,319 |
| ы | 0,066 | 0,006 | 0,197 |
| и | 0,042 | 0,198 | 0,102 |
| у | 0,025 | 0,176 | 0,071 |
| ү | 0,011 | 0,208 | 0,058 |
| ө | 0,011 | 0,178 | |
| о | 0,010 | 0,242 | |

Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы И.А. Бодуэн де Куртенэ тәгълиматында авазлар системасының төзелешен, составын, үзгәрешен тәэмин иткән көчләрнең берсе – ул артикуляцияләү һәм ишетүне җиңеләйтүгә омтылыш. И.А. Бодуэн де Куртенэ Туран телләренә сүз басымы хас булмаган дип таба [Бодуэн де Куртенэ, 1963, б. 34]. Сүз басымы булмаган телләрнең үзгәрешендә әйтелешне җиңеләйтү принцибының тәэсире көчлерәк күзәтелергә тиеш. Бу чынбарлыкта да шулаймы?

Сузыкларның әйтелешен җиңеләйтү чараларының берсе – түбән күтәрелештәге авазлар артикуляциясен урта күтәрелештәге авазлар артикуляциясенә якынайту. Икенчесе – авазларның әйтелеш вакытын кыскарту.

Бу чараларның йогынтысы татар теленең сузыклар системасында шактый ачык сизелә. Түбән күтәрелештәге [а] һәм [ә] фонемаларының артикуляциясе урта күтәрелештәге [ы], [е/э] фонемаларының әйтелешенә бик якын, һәрхәлдә татар теленең сузыклар системасында рус телендә табылган ачык (киң әйтелешле) [а] һәм [о] фонемалары хас түгел.

Икенче чара (сузыклар әйтелешенең вакыт ягыннан кыскаруы) сөйләмдә шулай ук киң чагылыш тапкан. Кыска сузыклар [о], [ө], [ы], [е/э], беренче чиратта [ы], [е/э] фонемалары сөйләмне бермә-бер тизләтәләр дә, җиңеләйтәләр дә булса кирәк. Кыска сузыкларның кыскаруы, югалып калу күренешләре иң күп очракта ТС калыбындагы иҗекләрдә күзәтелә. Ә бу калыптагы иҗекләрнең кулланылу ихтималлыгы (р) татар телендә 0,46 (р = 0,46). (Күзне бәйләп, ягъни күрмичә татарча текстларны төрткәләп чыксак, 100 тамганың якынча 46 сы ТС калыбына күрсәткән булыр иде.)

Икенче таблицаның өченче һәм дүртенче баганасындагы мәгълүматларга караганда татар телендә сүзләр 24% күләмендә сузыкларга башланалар һәм 41% күләмендә сузыкларга тәмамланалар. Ни сәбәпледер [ы], [е/э], [ә] сузыклары сүз башында артикуляцияләнүне җайлы тап-

мыйлар. Аларның сүз башында һәм сүз ахырында куллану ешлыклары арасындагы аермалык 74% җитә. Таблицадагы саннардан күренгәнчә, татар телендә иренләшкән урта күтәрелештәге [о] һәм [ө] авазлары сүз азагында кулланылмыйлар. Шул ук вакытта иренләшкән югары күтәрелештәге [у] һәм [ү] сузыклары сизелерлек дәрәҗәдә сүз ахырында да файдаланылалар. Бу күренеш энергия чыгымын киметү законына сыеп бетми кебек. Әмма бу беренче карашка гына.

Татар сөйләмендә сүз азагында (сөйләм егәрлеге кимегән позициядә) [о], [ө] сузыклары белән бергә тигез [у], [ү] авазларын артикуляцияләүдән «котылырга тырышу» да чагылыш тапкан. *Утырау, үгетләү* кебек сүзләрдә сүз башында һәм сүз азагында яңгыраган [у], [ү] авазлары бер үк формада әйтелмиләр һәм әйтелә дә алмыйлар. Татар теленең авазлар системасына сузыкларның рәттән килүе хас түгел. Шулай ук *укыту, үстерү* сүзләрендә сүз азагында килгән [у] һәм [ү] авазларының артикуляциясендә «иякне аска төшерү», «иреннәрне бөреп алга сузу» күзәтелми. Сөйләүче [у] авазын [ыw] га (*укытыw*), [ү] авазын [еw] гә (үстереw) күчерә.

Бодуэн де Куртенэ тәгълиматы буенча урта күтәрелештәге сузыкларны артикуляцияләү аскы һәм өске күтәрелештәге сузыкларны артикуляцияләүгә караганда җайлырак. Икенче таблицада чагылыш тапкан [е] һәм [ы] сузыкларының сүз азагында 8 һәм 33 мәртәбә күбрәк кулланылуы да аларның артикуляцияләү өчен җайлырак булуына нигезләнгән булырга мөмкин [Бодуэн де Куртенэ, 1963, с. 83].

Өченче таблицада сузыкларның ясалу урыннарына мөнәсәбәттә аерымлануы күрсәтелгән. Таблицада китерелгән мәгълүматлар буенча, [ы] һәм [е] фонемалары урта күтәрелешле фонемалар тәшкил итәләр. Сүз башында алар югары әйтелештәге [и] авазы белән бер чамада кулланылсалар, сүз ахырында күзгә ташланырлык дәрәҗәдә аннан күбрәк файдаланылалар. Шулай ук [ө] авазының [и] гә түгел, ә [е] гә күчүендә дә хикмәт бар.

*Таблица 3*

Ясалу урыннарына мөнәсәбәттә сузык авазларның аерымлануы

| Фонема / Ясалышы | а | ә | у | ү | и | о | ө | ы | е |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Алгы рәт | | + | | + | + | | + | | + |
| Арткы рәт | + | | + | | | + | | + | |
| Югары күтәрелеш | | | + | + | + | | | | |
| Түбән күтәрелеш | + | + | | | | | | | |
| Урта күтәрелеш | | | | | | + | + | + | + |
| Иренләшкән | | | + | + | | + | + | | |
| Иренләшмәгән | + | + | | | + | | | + | + |

Арткы рәт сузыклар ([ы] дан башкалар), ягъни [а], [у], [о] сузыклары сүз башында куллануны кулай күрәләр.

Сүз азагында (үпкәләрдә тупланган һава азая барган чакта) [о] һәм ]ө] авазларының [ы], [е] авазларына күчеше, шул ук [ы], [е] авазлары кулланышының сүз азагында бермә-бер үсеп китүе Бодуэн де Куртенэ тәгълиматының – авазлар эволюциясенең энергия чыгымын киметүгә корылган булуын – тагын бер мәртәбә дәлиллиләр.

Икенче таблицада китерелгән зурлыклар нигезендә табылган беренче нәтиҗә – ул алгы рәт сузыкларның телдә 20,4%, арткы рәт сузыкларның 21,4% тәшкил итүе. Алгы рәт сузыклар сан ягыннан күбрәк булсалар да, ни сәбәпледер телдә азрак файдаланылалар.

Таблицадагы саннарда чагылыш тапкан икенче күренеш – татар теленең сүзләр төзелешендә алгы рәт сузыкларның да, арткы рәт сузыкларның да сүз башында ике мәртәбә диярлек азрак кулланылуы. Саннар белән әйткәндә, алгы рәт сузыклар сүз башында 11,7% күләмендә, сүз азагында 20,3% күләмендә, арткы рәт сузыклар исә сүз башында 12,4% күләмендә, сүз ахырында 20,6% күләмендә күзәтеләләр. Ахры, татар телендә сузыкларның сүз ахырында якынча ике тапкыр ешрак кулланылуы физиологик сәбәпләргә генә нигезләнмәгән. Фәнни әдәбиятта сузыкларга бетүче сүзләрнең күп булуын телнең музыкальлеген чагылдыручы күренеш буларак аңлатыла, әмма ул статистик дәлилләр белән ныгытылмый.

Татар теле иясенә иң җайлысы – сүз азагында – үпкәләргә җыелган һава бетеп барган вакытта – [ы] һәм [е] авазларын артикуляцияләү. Җиңеллек буенча икенче урында түбән күтәрелешле [ә] авазы. Иң җайсызы – иреннәрне бөрештереп [о] һәм [ө] авазларын әйтү. Кыенлык буенча икенче урында [у] һәм [ү] авазлары. Алар шулай ук иренләшкән авазлар, әмма, [о] һәм [ө] авазларыннан аермалы буларак алар иреннәрнең бөрелгән хәлдә тышка тартылышын таләп итмиләр.

«Безнең телебез – ул безнең тарихыбыз да». Бу сүзләр 1785 – 1863 елларда яшәгән күренекле немец галиме Якоб Гримм исеменә бәйләнештә тарихка кереп калганнар. Моңа чаклы халыклар үзләренең тарихлары белән язма текстлар аша танышып килделәр. Бүгенге техника һәм технология чаралары телчеләргә сөйләмә һәм язма телләрне электрон форматта тарихта калдыру мөмкинлекләре тудырды. Әгәр тел белемендә язма текстларны телнең һәйкәле итеп карау гадәткә кергән булса, электрон формага күчерелгән текстлар кимендә гасырларның фоторәсемен тәшкил итергә мөмкиннәр. Телчеләрнең бурычы – тел системасын саклау. Тел системасы исән булганда, киләчәк буыннар үзләренең тарихлары белән таныша алырлар.

**Әдәбият**

*Богородицкий В.А.* Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию. Казань: Татгосиздат, 1933. 157 с.

*Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. Казань: Татгосиздат, 1953. 220 с.

*Бодуэн де Куртенэ И.А.* Язык и языки. Избранные труды по общему языкознанию / И.А.Бодуэн де Куртенэ. М.: Наука, 1963. Т. 2. 388 с.

*Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе. (Очерклар). Казан: ФИКЕР, 2000. 287 б.

*Зиндер Л.Р.* Общая фонетика и избранные статьи: учеб. пособие для студ. филол. фак. высш. учеб. заведений. 2-е изд., испр. и доп. СПб.: Филологический факультет СПбГУ; М.: Академия, 2007. 576 с.

*Златоустова Л.В., Потапова Р.К., Потапов В.В., Трунин-Донской В.Н.* Общая и прикладная фонетика. М.: МГУ, 1997. 414 с.

*Ибрагимов Т.И., Сайхунов М.Р.* Фонология татарского языка в плане теории фонемы И.А. Бодуэна де Куртенэ // И.А. Бодуэн де Куртенэ и мировая лингвистика (V Бодуэновские чтения) Материалы Международной конференции. Казань: Изд-во Казан. федер. ун-та, 2015. Т. 1. С. 130.

*Лайонз Джон.* Язык и лингвистика. Вводный курс. М.: Эдиториал УРСС, 2004. 320 с.

Письменный корпус татарского языка [Электронный ресурс] / М.Р. Сайхунов, Т.И. Ибрагимов. Казань, 2012. Режим доступа: http://corpus.tatfolk.ru

*Сәлимов Х.Х.* Татар телекнең сузык авазлары. Куйбышев: Редакционно-издательский отдел Куйбышевского гос. пед. института, 1989. 80 с.

*Фланаган Джеймс Л.* Анализ, синтез и восприятие речи. М.: Связь, 1968. 392 с.

*Шакирова О.Ф.* Хәзерге татар теле фонетикасына кереш. Казань: Таткнгоиздат, 1954. – 101 с.

Radloff V. Phonetik der nördlichen Türkspachen. Leipzig, 1883.

***Ибраhимов Тәүзих Ибраhим улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты, инженер*
*E-mail _Tavzikh.Ibragimov@kpfu.ru*

***Сәйхунов Мансур Равхат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Фәннәр академиясе Перспектив эзләнүләр институтының фәнни-тикшеренү эшләрен техник оештыру ягыннан тәэмин итү бүлеге мөдире*
*E-mail _6688000@gmail.com*

УДК 811.512.145´33

***Б.Э. Хәкимов***

# ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ КОРПУС ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН КУЛЛАНУГА КАРАТА

В последние годы в лингвистике для решения многих научных проблем активно используются корпусы электронных текстов, которые разрабатываются при помощи компьютерных технологий. В современном татарском языкознании проведение исследований в области корпусных технологий и разработка специальных программ являются одним из актуальных и значимых направлений. Статья знакомит читателя с результатами, достигнутыми в области создания корпуса электронных текстов татарского языка.

**Ключевые слова:** татарский язык, корпус текстов, компьютерная лингвистика, лингвистическая разметка, морфологический анализатор.

Соңгы елларда лингвистиканың күп кенә мәсьәләләрен тикшерүдә компьютер технологияләре ярдәмендә төзелгән *электрон текст корпуслары* кулланыла башлады. Электрон текстлар корпусы теге яки бу телдәге текстлар җыелмасыннан гыйбарәт булып, махсус рәвештә бердәм стандартка китерелә, тамгалана һәм билгеле бер структурага салына. Телнең төрле функциональ, территориаль, хронологик, иҗтимагый һәм башка барлык вариантларын да чагылдырган мондый корпуслар лингвистика өлкәсендәге нәзари тикшеренүләр өчен дә, гамәли эшчәнлек өчен дә кыйммәтле чыганак, тәфсилле информацион-эзләү системалары ролен үти [Зубов, 2004]. Шул сәбәпле, корпус технологияләре өлкәсендәге тикшеренүләр һәм махсус программалар төзү эшчәнлеге татар тел белеме өчен гаять актуаль.

Корпус дип аталган махсус электрон ресурслар дөнья тел белемендә 1960 елларда пәйда була башлый, әмма исәпләү техникасының ул чордагы үсеш дәрәҗәсе әлеге ресурсларның киң таралышына комачаулый. 1990 еллардан башлап корпус лингвистикасы тарихында яңа чор башлана, корпус тикшеренүләренең активлашуына Интернет челтәренең барлыкка килүе дә сәбәп була. Рус телендә мондый төрдән «Национальный корпус русского языка» («Рус гомумтел корпусы») ресурсын мисал итеп китерергә була (www.ruscorpora.ru). Төрки телләрдә дә корпуслар актив төзелеп килә [Suleymanov, Nevzorova, Gatiatullin, Gilmullin, Khakimov, 2013]. Татар теле өчен соңгы елларда «Туган тел» исемле татар гомумтел корпусы (http://tugantel.tatar/) һәм «Татар теленең язма корпусы» («Письменный корпус татарского языка», http://corpus.tatfolk.ru) төзелде. Аерым алганда, «Туган тел» корпусы киләчәктә татар әдәби теленең барлык функциональ стильләрен дә үз эченә алган (сөйләм теле үрнәкләрен,

диалектологик материалларны һәм телебезнең башка яшәеш формаларын да керткән хәлдә) киң колачлы ресурс булыр дигән максат куела [Гильмуллин, Невзорова, Хакимов, 2011]. Хәзерге вакытта «Туган тел» корпусының күләме якынча 80 млн сүз тәшкил итә.

Татар теле өчен зур электрон корпус төзү – бик күп көч, вакыт һәм махсус тикшеренүләр сорый торган глобаль мәсьәлә [Сулейманов, Хакимов, Гильмуллин, 2011]. Бер яктан, корпус өчен күпсанлы лингвистик мәгълүматларны эшкәртү, текстлар коллекциясен бөртекләп җыю кирәк булса, икенче яктан, ул махсус компьютер программасы төзүне таләп итә. Текстларны сайлап алу методикасын булдыру, аларның электрон версияләрен шрифтлар, кодировкалар һәм форматлау ягыннан стандартлаштыру белән беррәттән, текстлар коллекциясен әзерләгәндә *махсус тамгалау системасы* зур әһәмияткә ия. Корпусларда лингвистик тамгалау (лингвистическая разметка) башкару вакытында шартлы тамгалар ярдәмендә тексттагы һәрбер сүзгә аның морфологик, семантик һәм башка үзлекләре турындагы мәгълүмат беркетелә. Бу мәгълүматка таянып, корпусның махсус эзләү системасы кулланучыга кирәкле мисалларны автомат рәвештә таба ала [Хакимов, Гильмуллин, 2010].

Билгеле ки, корпусны тәшкил иткән текстларны тамгалау бик катлаулы һәм дәвамлы процесс. Гадәттә бу процесс өлешчә яки тулысынча автоматлаштырыла, шуның өчен махсус программалар (анализаторлар) кулланыла. Татар компьютер лингвистикасы өлкәсендә күп еллар дәвам иткән тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак, бүгенге көндә берничә махсус лингвопроцессор программасы һәм татар теле грамматик системасының модельләре бар [Сулейманов, Гильмуллин, Гильмуллин, 1997]. Без татар морфологиясенең ике дәрәҗәле моделен куллана торган морфологик анализатор ярдәмендә татар теленең электрон корпусында лингвистик тамгалау процессын автоматлаштыру мөмкинлекләрен тикшерүне максат итеп куйдык һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Татар морфологиясенең ике дәрәҗәле моделенә нигезләнүче морфологик анализаторның хәзерге версиясе татарча текстларны корпус өчен тамгалау процессын шактый күләмдә автоматлаштырырга мөмкинлек бирә. Бу бигрәк тә татар теленең үз сүзләренә кагыла. Автоматлаштыруның нәтиҗәлелеген өстәмә кагыйдәләр булдыру һәм контекст анализы чараларын төзү аша арттырырга мөмкин.

2. Татар телендә сүз формасының морфологик үзлекләре аффикслар составын автомат рәвештә анализлау барышында җиңел ачыклана. Сүз төркемнәренең семантик төркемчәләре исә гадәттә саф формаль күрсәткечләргә ия булмый һәм аларны танып алу аерым бер проблеманы тәшкил итә.

3. Морфологик анализаторның эшен яхшырту максатыннан алынма сүзләрнең һәм татар теленең төп кагыйдәләргә

буйсынмый торган үз сүзләренең аерым типлары өчен махсус фонологик һәм морфотактик кагыйдәләр төзү мөмкинлеген тикшерү таләп ителә.

4. Шулай ук күпмәгънәле һәм омоним аффиксларның конкрет функцияләрен автомат рәвештә аеру мөмкинлекләрен тикшерү дә зарури. Икенче яктан, агглютинатив тел булган татар телендә аффикслар даими һәм тотрыклы булганга күрә, аларның төп вариантларын билгеләү зур авырлык тудырмый, ә функцияләрен аеру өчен контекст анализы ярдәмгә килә ала [Галиева, Хакимов, Гатиатуллин, 2013].

5. Корпус өчен кулланыла торган программаларда лингвопроцессорларны «өйрәтү» һәм телнең компьютер модельләрен камилләштерү өчен дә мөмкинлекләр салынган булырга тиеш. Мәсәлән, төрле аффиксларның һәм парадигмаларның ешлык күрсәткечләрен анализлау, билгеле бер сүз төркеменә нисбәт ителә торган аффиксларның башка сүз төркемнәренә дә ялгану очракларын теркәү һәм тикшерү файдалы булырга мөмкин.

Хәзерге вакытта «Туган тел» корпусында югарыда телгә алынган морфологик анализатор уңышлы кулланыла һәм корпус төзү эшен өлешчә автоматлаштыруны тәэмин итә [Сулейманов, Невзорова, Галиева, Гатиатуллин, Гильмуллин, Хакимов, 2014].

Йомгаклап әйткәндә, татар тел белемендә корпус технологияләрен куллану өчен кирәкле җирлек һәм ресурслар базасы формалашкан дип санарга була. Әлеге мөмкинлекләр, бер яктан, татар компьютер лингвистикасының хәзерге үсеш дәрәҗәсе белән, икенче яктан, татар теле морфологик системасының эчке һәм тышкы үзенчәлекләре белән билгеләнә.

**Әдәбият**

*Галиева А.М., Хакимов Б.Э., Гатиатуллин А.Р.* Метаязык описания структуры татарской словоформы для корпусной грамматической аннотации // Ученые записки Казанского университета. Серия Гуманитарные науки. 2013. Т. 155, Кн. 5. С. 287–296.

*Гильмуллин Р.А., Невзорова О.А., Хакимов Б.Э.* Корпус татарских текстов: проблема репрезентативности // Труды международной конференции «Корпусная лингвистика – 2011». 27–29 июня 2011 г., Санкт-Петербург. СПб.: С.-Петербургский гос. университет, Филологический факультет, 2011. С. 125–130.

*Зубов А.В., Зубова И.И.* Информационные технологии в лингвистике: учеб. пособие для студ. лингв. фак-ов высш. учеб. заведений. М.: Академия, 2004. 208 с.

*Сулейманов Д.Ш., Гильмуллин А.А., Гильмуллин Р.А.* Двухуровневое описание морфологии татарского языка // Тезисы Международной научной конференции «Языковая семантика и образ мира». 7–10 октября 1997. Кн. 2. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1997. С. 65–67.

*Сулейманов Д.Ш., Невзорова О.А., Галиева А.М., Гатиатуллин А.Р., Гильмуллин Р.А., Хакимов Б.Э.* Размеченный корпус татарского языка «Туган тел»: аспекты реализации // Труды Казанской школы по компьютерной и когнитивной лингвистике TEL – 2014. Казань: Фэн, 2014. С. 88–93.

*Сулейманов Д.Ш., Хакимов Б.Э., Гильмуллин Р.А.* Корпус татарского языка: концептуальные и лингвистические аспекты // Вестник ТГГПУ. 2011. № 4 (26). С. 211–216.

*Хакимов Б.Э., Гильмуллин Р.А.* Морфологическая разметка в корпусе татарского языка // Компьютерная лингвистика: научное направление и учебная дисциплина. Сборник научных статей. Вып. 1. Гомель: ГГУ им. Ф. Скорины, 2010. С. 34–38.

*Хәкимов Б.Э.* Татар тел белемендә корпус технологияләрен куллану мөмкинлекләре // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы: Материалы II Междунар. науч.-практ. конф. Казань, 2009. С. 331–333.

*Dzhavdet Suleymanov, Olga Nevzorova, Ayrat Gatiatullin, Rinat Gilmullin, Bulat Khakimov.* National corpus of the Tatar language «Tugan Tel»: Grammatical Annotation and Implementation // Procedia-Social and Behavioral Sciences (2013). P. 68–74.

***Хәкимов Булат Эрнст улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты*
*Филология һәм сәнгать институтының математик лингвистика*
*һәм филологиядә мәгълүмати системалар кафедрасы доценты*
*E-mail: dvdt.slt@gmail.com*

УДК 821.512.145-2

*А.Г. Әхмәдуллин*

# ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ПЬЕСАЛАР
## *(Эсфир Яһудин драматургиясе хакында)*

Статья посвящена драматургии Эсфира Ягудина. Тематическое и жанровое разнообразие, система образов его произведений рассмотрены с точки зрения новизны, которую он привнес своим творчеством в татарскую драматургию.

**Ключевые слова:** Э. Ягудин, драматургия, новая татарская пьеса.

Соңгы елларда сәхнә әдәбиятына дистәләрчә яңа иҗатчылар килде, һәм алар безнең театрларыбызны милли репертуар белән тәэмин итүгә җитди өлеш кертәләр. Татарстан китап нәшрияте бу авторларның иҗатын укучыга үз вакытында җиткерүдә бик актив һәм бәрәкәтле эш алып бара. Чөнки безнең халык пьесаларны театрда карарга гына түгел, укырга да элек-электән үк бик хирыс булды. Шуны истә тотып, нәшрият бер-бер артлы өлкән буын драматургларының гына түгел, инде урта буын саналган һәм яшьрәк авторларның да пьесалар җыентыкларын даими бастырып килә. Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов, И. Юзиевләр буыныннан соң әдәбият мәйданына килгән Ф. Яруллин, Ю. Сафиуллин, Д. Салихов, Ф. Бәйрәмова, А. Хәлим кебек драматургларның пьесалары җыентыклар булып дөнья күрде. Күркәм эш! Аларга алмашка килгән яңа буын драматургларның соңгы елларда гына да дистәләрчә җыентыклары басылды: Мансур Гыйләҗевнең «Бичура» һәм рус телендә «Словарь любви», Ркаил Зәйдулланың «Саташкан сандугач», Аманулланың «Моңлы ядкәр», Хәбир Ибраһимның «Газиз ярым», Рәдиф Сәгъдинең «Гүзәл Аппаксылу», Ләбиб Леронның «Бәхеткә биш минут кала», Гафур Каюмовның «Упкын өстендә уен» һәм «Ул...» дип аталган пьесалар җыентыклары... Рәфкать Кәраминең «Яратуың чынмы?» исемле китабында да төп урынны пьесалар алып тора. Мәдинә Маликованың «Алтын ятьмә», «Югалган якутлар» исемнәре белән басылган җыентыкларына да шактый пьесалар кертелгән. Драматургия тарихы буенча зур хезмәт язу эше белән мәшгуль булуым сәбәпле, гәрчә теләгем бик булса да, алар турында махсус сүз әйтә алмадым. Татарстан китап нәшрияте Эсфир Яһудинның 2004 елда «Мәхәббәткә мәдхия», 2014 елда «Пьесалар» исемендәге җыентыкларын бастырып чыгарды. Сүзем шул китапларда урын алган пьесалар турында.

Э. Яһудин – ике дистәгә якын драма әсәрләре авторы. «Мәхәббәткә мәдхия» исемле җыентыкта аның 3 драмасы,

4 комедиясе дөнья күрде. «Пьесалар» җыентыгында авторның ике драмасы, ике комедиясе, өч экият-пьесасы (икесе шигырь белән язылган) урын алган. «Яңа татар пьесасы» альманахлар сериясендә 5 пьесасы басылган, берничәсе төрле сәхнәләрдә уйналган һәм уйнала килә.

Э. Яһудин пьесалары жанрлар ягыннан да, тематик яктан да төрле. «Пьеса» дип гомуми исем белән генә аталса да, драма төренә якын булганнары да, саф драмалар да, комедияләр һәм музыкаль комедияләр дә, «музыкаль тамаша» дип билгеләнгәне дә, экият-пьесалар да бар.

Драмалар һәм комедияләр, асылда, бүгенге көннәрдәге вакыйгаларны чагылдыра, замандашларыбыз образларын сурәтли. Ир белән хатын арасындагы катлаулы, яшьләр арасындагы самими мөнәсәбәтләр, күршеләрнең үзара аралашуындагы күптөрле рәвешләре тормышта очрый торган һәм гаиләдәге гадәти ситуацияләр ярдәмендә ачыла («Вагон», «Идел буе сәхифәсе», «Киң урамнар тар иде», «Әгәр дә көн туса», «Тутый кош», «Мәхәббәткә мәдхия», «Җиһанның серле затлары»...). Алардагы конфликт кешеләрнең бер-берсенә капма-каршы позициядә торулары төсендә булудан да бигрәк һәртөрле аңлашылмаучылыклардан килеп чыккан хәлләр рәвешендә оеша. Болар укучы-тамашачы өчен аңлаешлы һәм мавыктыргыч. Мәсәлән, «Вагон» драмасында юлда баручылар – төрле характердагы кешеләр, һәм бу төрлелеккә драматург уңышлы ирешкән. Юк, моңа ул алар арасында каршылыклар тудырып, характерларны үзара бәрелештереп ирешми. Ә тормышчан хәлләрне сурәтләп, шуларны табигый тасвирлап, характерлар тудыра. Монда Себергә вахтага баручы егетләр дә, хатыны үлгән, малае Әфганстанда һәлак булган, Чечня вакыйгаларында инде оныгын да югалткан герой-фронтовик Сирмат та, Мәскәүгә барам дип, ялгышып Новосибирскийга баручы поездга утырган Хәбир карт та, сөйгәне аны көтеп тормыйча кияүгә чыкканга дөньяның ямен югалткан, шуның өчен беренче булып аңа елмайган кызга өйләнергә карар кылган Бәхти дә, үзара аңлашып бетә алмаган проводница Маша белән полиция старшинасы Миша да, туй сәяхәтенә чыккан яшь парлар Алия белән Назир да, сатучы кыз Галия дә бар. Һәрберсенең үз холык-фигыле, тормышта үз максаты. Хәбир картның үз поездын буташтыруы поезд туктаган арада станциягә эчемлек алырга дип чыккан Бәхтинең утырырга соңга калуы, иптәшләренең күреп-танып алыр дип, аның акчалары-документлары салынган биштәрне кузгалып киткән поезддан перронга чыгарып ташлаулары, аны очраклы рәвештә табып алган Хәбир картның алып керүе кебек вакыйгалар ситуацияләрне җанландырып тора. Фронтовик дусты чичен Зилемханнан Чечнядагы оныгының исән булуы турындагы хәбәрен ишеткәч, Сирматның шатлыгыннан нишләргә белмичә өзгәләнүе, яшәргә өмете яңадан кабынуы пьесага эчке кичерешләр, мелодраматик рух һәм җанлылык

өсти. Әсәрне уку өчен дә, сәхнәдән карау өчен дә мавыктыргыч итә.

Әйе, әсәрдәге конфликтны характерлар бәрелеше рәвешендә түгел, төрле очраклыклар, аңлашылмаучылыклар төсендә барлыкка китерү, оештыру Эсфир Яһудинның күпчелек драмаларына һәм комедияләренә хас бер үзенчәлек булып тора. «Идел буе сәхифәсе» дип аталган драмада вакыйгалар чыгарылыш сыйныфындагы ике укучыга (берсе – мәктәп директоры оныгы, икенчесе – бер «бик кирәкле» җитәкченең улы) алтын медаль алсыннар өчен бер фәннән билгеләрен төзәтү вакыйгалары тирәсендә оеша. «Киң урамнар тар иде» драмасында аңлашылмаучылык аркасында бер-берсен яратучы яшьләр аерылыша язып калалар. Пьесада бер персонажны да баш герой дип әйтеп булмый. Вакыйгаларда бар да бертигез.

Яки, мисалга менә тагын ике ситуация. Авыл кызы Зәкинәне этисе, кияүгә дә чыкмыйча балага узганын белгәч, өеннән куып чыгара. Кыз кая барып бәрелергә белмичә йөри. Икенче ситуация: сөйгән кызы Наҗиянең аңа кияүгә чыгарга, бары тик ул дачалы, машиналы һәм фатирлы булгач кына риза булачагын шарт итеп куйгач, шәһәр паркында эшләүче Бартасның язмышы. Ләкин һәр ике ситуация дә әсәрләрдә төп рольне уйнамый. Алар пьесадагы вакыйгаларны бер үзәккә тупламыйлар, бары тик персонажларның характер үзенчәлекләрен ачуга хезмәт итәләр.

Әсәрдә анык бер конфликтның да, үзәктә торган бер геройның да булмавы «Әгәр дә көн туса» драмасына да, «Тутый кош» исемле музыкаль комедиягә дә, «Тәтәй кызлар утары», «Мәхәббәткә мәдхия», «Китмәскә килгән кошым», «Эт чаба дип...» комедияләренә дә хас. Ләкин һәртөрле очраклыклар, аңлашылмаучылыклар, алда әйтелгәнчә, вакыйгалар барышын тотып тора, әсәрләрне уку һәм сәхнәдән карау өчен мавыктыргыч һәм кызыклы итәләр. Бу, кабатлап әйтәбез, драматург Эсфир Яһудин иҗатының бер үзенчәлеге.

Дөрес, автор үз иҗатында бу юл белән генә бармый. Аның тарихи һәм әкият-пьесаларында хәлләр бер вакыйга тирәсенә оештырыла, конфликт анык һәм ачык. Бу яктан бигрәк тә «Кол» исемле драма аерылып тора. Әсәр – моңарчы бездә сәхнә күргән тарихи пьесалар арасында кызыклы булуы ягыннан бик уңышлылардан берсе. Кызганыч, театрларыбыз аңа мөрәҗәгать итмиләр. Югыйсә, тамашачыларның игътибарын җәлеп итүче менә дигән спектакль булыр иде. Драматургның интрига кору осталыгын күрсәтү өчен әсәрнең кыскача гына эчтәлеге белән таныштыру урынлы булыр дип уйлыйм.

...Вакыйга унынчы гасыр башында бара. Ил башлыгы Алихан, кызын кияүгә бирүен сорап, күрше илнең ханына яучы җибәрә. Ләкин тискәре җавап ала: чөнки кыз инде башка бер илнең ханы Аршакка ярәшелгән, туй көне дә билгеләнгән икән. Моңа үртәлгән Алихан яу чаба, нәкъ туй барган көнне Аршак иленә бәреп керә, аның гаскәрен

җиңә, Аршакны да, аның гаскәр башлыгы Зайналны да әсир итә. Бәрелеш вакытында яраланган ханын коткару өчен Зайнал аның киемнәрен кия, үзенекеләрен аңа киертә. Аршакны аңарчы күрмәгән-белмәгән Алихан Зайнални хан дип кабул итә, үзенә кол итеп ала, чөнки хан кадәр ханны кол итеп тотуны үзенә дәрәҗә саный. Ә инде ханбикә Гөлмирәне, үзенә булмаганына үч итеп, хан дип уйлаган Зайналга (дөресендә Аршакка) хатынлыкка бирә, аларны, балалары булгач иреккә җибәрергә ышандыра. Шуның белән, ягъни гади гаскәригә кияүгә биреп, ханбикәне кимсетәм дип уйлый. Чөнки аның электән килгән гадәтләргә нык ышануы буенча, бары тик югары катлау вәкилләре генә үзара туганлаша ала. Ә Зайналга үзенең кәнизәге Зарифаны кияүгә бирә, монда да гади кәнизәкне хатын итеп алган ханның дәрәҗәсен төшерәм дип исәпли. Аршакның улы, ә Алиханның кызы туа. Дөресендә, ул кызның әти-әнисе – Зайнал белән Зарифа. Чөнки бала тапканда Алиханның хатыны да, баласы да үләләр. Бу вакытта ерак җәйләүдә булган Алихан белмәсен, кара кайгыга батмасын дип, үзләренең кызларын алар ханныкы дип әйтәләр. Бала Зарифа тәрбиясендә үсә, атасын Алихан дип белә, хан аны бик ярата. 18 ел вакыт үтә. Аршакның малае Мирза Алихан ханның кызы Адинәнең бик чибәр икәнен ишетеп, аны күрергә тели. Шуның өчен сәүдәгәр Зафирның хезмәтчесе кыяфәтендә Алихан иленә килә. Яшьләр күңелләре белән бер-берсенә тартылалар. Адинә әтисеннән Мирзаны үзенә кол итеп сорап ала. Җаен китереп, Мирза кызны, аның теләге белән, урлап кача. Үз иленә кайткач, Алиханны инде кияве сыйфатында кунакка чакырып, илче җибәрә. Моңа ачуы кабарган Алихан Аршак иленә яу чапмакчы була. Шунда бөтен серләр ачыла. Зайналның хан түгеллеге дә, Адинәнең чын әти-әнисе Зайнал белән Зарифа булуы да, япаялгыз калдым дип өзгәләнгән Алиханның бер көтүче кыздан туган малае барлыгы да мәгълүм була. Дәвамчысы барлыгын белеп чиксез шатланган хан барчасын да гафу итә, тизрәк улын, көтүче кызы булса да, ханбикә итеп куячак хатынын да күрергә ашкына. Шуның белән ул, Зарифа әйткәнчә, «биләр нәселен генә санга сугып, башкаларны үзеннән түбән итеп күрә торган тәкәбберлек колыннан азат» була. Менә шунда пьесаның исеменә чыгарылган «кол» сүзенең төп мәгънәсе ачыла да: ул – Аршак-Зайналның да, Мирзаның да кол булуында гына түгел, ә сыйныфлар арасындагы аермага табынуның дөрес булмавы, шуны танымаган-аңламаган кешенең коллык түбәнлегендә торуы.

Авторның әкият-пьесалары да үзенчәлекле. Алар тарихи вакыйгаларга корылган. Ханнар, сарайлар тормышы... Аларны хәтта тарихи драмалар дип тә әйтергә була. Инде алда әйтелгәнчә, аларның икесе шигырь белән язылган. Монда драматургның шигырь белән язуда уңышлары да күренә. Пьесаларның нигезендә чыннан да әкияти хәлләргә охшаган очраклыклар ята.

Менә, мәсәлән, «Соңгы чәчәк» пьесасында илбашы Кайсар хан өйләнергә карар кыла. Ләкин аның бер шарты бар: аның хатыны булачак кыз ул үти алмаслык бер эш уйлап табарга тиеш. Моны аның янына китергән кызларның берсе дә эшли алмый. Әкиятләрдә генә була торган хәл туа: елга буенда әнисе белән генә яшәп ятучы кыз Маһруй хан алдына: «ул элек яулап алган илнең башы, менә ун ел инде тоткынлыкта ятучы әтисе Фәридне үзе урынына хан итеп куйсын, ә әнисе белән яшәгән җирдә үзе бер ел гомер сөрсен», – дигән шарт куя. Башта кеше ышанмаслык бу таләпкә ачуланып та, көлеп тә караган, ләкин гадәттә биргән вәгъдәсендә тора торган, кызның акылына һәм чибәрлегенә сокланган Кайсар хан, үзе куйган шартны исендә тотып, бу сынауга ризалыгын бирә, һәм шулай эшли дә. Бер ел вакыт үтә. Табигать кочагында, яраткан хатыны янында хөкүмәт эшләреннән азат булып яшәүнең тәмен татыган хан да, аның урынында ил белән җитәкчелек итүдә урнашкан тәртипләргә тугрылыклы Фәрид дә озакламый илгә басып кергән дошманнарга каршы яуга китәләр, шунда башларын салалар. Ләкин илдәге хөкем сөргән шәхси азатлык, тормышта тигезлек, рәхимлелек, миһербанлык саклап калына. Алда биргән вәгъдәсенә туры калып, өйләнгән көнендә барлык тоткыннарны азат итәргә сүз биргән Кайсар ханның илендә инде бернинди җинаять кылынмый, төрмәләрнең кирәге калмый. Аңарчы тоткыннарны карап торучы булып эшләгәнНазифның шул вазифасын сагынып төшенкелеккә бирелүе, яшәүдән тәм тапмавы иске тәртипләрнең колы булган кешенең үзенчәлекле характеры рәвешендә истә кала. Кызыклы әкият, гуманлылыкны үзенчәлекле төстә яклый торган әкият-пьеса.

Эсфир Яһудинның үзенчәлекле драматургиясен югары бәяләү белән бергә, авторга кайбер искәрмә рәвешендәге сүзләрем, киңәшләрем дә бар. Иң беренче, пьесаларына исем куюда автор еш кына кыенлык кичерә. Мәсәлән, «Киң урамнар тар иде» драмасының исеме әсәрнең эчтәлегенә ятышмый, андагы вакыйгаларга туры килми, очраклы рәвештә генә куелганлык тәэсирен калдыра. Автор аны Бабай дип кенә исемләгән персонажның бер куплетлык җырыннан гына алып куйган.

«Әгәр дә көн туса» дип аталган драманың да исеме җисеменә туры килми. Әсәрнең исеме әйтелү белән үк аның эчтәлеге искә төшәрлек булырга тиеш. Бу пьесалар турында да, «Җиһанның серле затлары» дип аталган, «Эт чаба дип...» исемләнгән комедияләр хакында да моны әйтеп булмый.

Пьесаларның жанрын билгеләүдә дә уйлап җиткермәү сизелә. Мәсәлән, «Тәтәй кызлар утары» автор үзе атаганча «моңсу комедия» булудан бигрәк – «мелодрама». «Мәхәббәткә мәдхия» дип аталган моңсу комедия турында да шуны ук әйтеп була. Ул – әйбәт кенә мелодрама, ләкин комедия түгел.

Э. Яһудинның шигъри әсәрләр язуда, инде әйтелгәнчә, мөм-

кинлекләре бар. Еш кына пьесаларда («Идел буе сәхифәсе», «Эт чаба дип...», «Тутый кош») персонажлар сөйләмдә җырга, шигырьгә күчәләр. Бигрәк тә «Мәхәббәтнамә» пьесасында, аерата аның беренче яртысында шигъри юллар әйбәт эшләнгән. Ә менә пьесаның икенче яртысында, шулай ук «Олуг хан фәрманы» экият-пьесасында шигъри юлларда кимчелекләр бар, аларны язганда авторның ашыгычлык күрсәткәне сизелә.

Шулай да, тулаем алып бәяләгәндә, Эсфир Яһудин драматургиясе кызыклы әсәрләрдән тора. Тематик яктан да, жанрлар җәһәтеннән дә, образлар системасы белән дә ул бүгенге сәхнә әдәбиятыбызга яңалыклар алып килде.

***Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 821.512.145-2

***Г.И. Каюмова***

# КУРЧАКЛАР УЕНЫНДА – КЕШЕЛӘР ЯЗМЫШЫ...

## *(«Курчак туе» һәм «Кәләпүшче кыз» әсәрләренә чагыштырма анализ)*

В статье дается полный сравнительный анализ драматического произведения «Кукольная свадьба», написанного М. Гилязовым в соавторстве с Р. Хамидом и повести Г. Исхаки «Тюбетейщица».

**Ключевые слова:** драма, повесть, судьба человека, проблема женского счастья, кукольная свадьба, «живая кукла».

Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902–1904) әсәрендә татар байларының зур суммаларга курчак туйлары уздырып күңел ачулары турында әйтелгән юллар бар: «Акыртынлап кунаклар тарала башлады. Кунаклар арасыннан: «Байлык ни эшләтә!! Курчак туена никадәр расхут!! Ике яктан кырык мең, кеше үз кызын биргәндә дә алай расхут тота алмый, и, байлык яхшы нәрсә соң!» – дигән сүзләр ишетелә иде. Әман, йа Раббем кырык мең тәңкә! Курчак туена кырык мең тәңкә?! Кем әйтеп, кем ышаныр бу сүзгә? Ләкин ышансаң – ышанмасаң да, бу курчак туе иде! Һәм чыккан расхут та, кырык мең иде. Сез: «Бу эшләр ни өчен? Ник курчак туена кырык мең? Бу эштән кемгә файда булды? Әллә гомум милләткә бер-бер файда бармы? Ник болай иткәннәр?» – диярсез? Мин тагы: «Бу туй – курчак туе иде, чыккан расхут кырык мең иде»дән башка җавап белмим. «Кырык мең!! Кырык мең!! Бер файдасыз кырык мең!» – дисезме? Без элгәре үземезгә кәеф килердәй йерләрдән кырык меңнәрне кызганмый идек! (Бу туй үзе зур дәлил)» [Исхакый, 1998, б. 162]. Курчак туен Шаһмөхәммәт бай белән Фәхри кода мул сыйлар әзерләп, зурдан кубып уздыралар. Курчакларның хәтта исемнәре дә бар: «кыз» – Айсылу, «егет» – Бикбау. «Унтугызынчы гасырда бер курчак туе кырык мең булдыгы шикелле, җанлы курчаклар туе да кырык мең берлә калмаенча, сиксән меңгә бик еш йетә иде», – дип яза автор [Исхакый, 1998, б. 163]. Әдип әлеге һәм башка шундыйрак күренешләргә тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Аның фикеренчә, эшләнәсе эшләр сөйләнгән сүзләрдә генә калганга күрә, ул төрле «лаф орулар»га, кычкырышларга «курчак туе» дигән исем бирә һәм мондый күренешләрнең һәммәсен дә «курчак уены» дип атый. «Курчак уеныннан бер мәгънәле эш килеп чыкмадыгы кеби, табигый, безнең дә бу “төпсез” эшемездән дә бернәрсә чыкмас дип уйлыйм» [Исхакый, 1998, б. 154], – ди.

Курчак уены турында Алтын Урда чорында иҗат ителгән

«Хөсрәү вә Ширин» (1342) әсәрендә дә искә алына. Түбәндәге юлларга игътибар итик:

Утырды пәрдә артында Ширин дә,
Тәмам яктырды ай аның нурында,
– Күренерме бу? – дип, Фәрһад
текәлде,
Күләгәсен генә ләкин күрәлде:
Кугырчакны (фигура-марионетка)
уйнаткан чакта шәүлә,
Күренгәндәй, беленде якты гәүдә.
Сурәткә керде җан: Фәрһадка шунда
Ишеттерде Ширин үз тавышын да
[Котб, 2003, б. 190, 191].

Егет курчак уены аша сөеклесенең күңелендә ниләр булуын белергә өметләнә.

Балалар да еш кына курчак уеннары уйный торган булганнар. Алар да, өлкәннәрдән күреп булса кирәк, шундый курчак туйлары уздырганнар. Мондый «курчак уеннарында борынгы заманнардан бирле бик тормышчан сюжетлар уйналган» [Ханзафаров, 1996, с. 32]. Фарсы шагыйре Г. Хәйям робагыйларында ук безне якты дөньяга яралткан Аллаһ кулында барыбызның да күндәм «курчаклар» гына булуыбыз һәм соңгы сулышыбызга кадәр Тәңренең безне тормыш сәхнәсе буйлап бер җепкә тезеп йөртүе хакында әйтелгән юлларны күрергә мөмкин [Хайям, 2002, с. 174].

М. Гыйләҗевнең Р. Хәмид белән автордашлыкта иҗат иткән «Курчак туе» драмасы (2001) Г. Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» (1900) повестена нигезләнә. Моннан тыш, иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләрне яктыртканда, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендәге курчак туе күренеше өлге итеп алына. Әсәрдә шундый курчак туйлары уздырып, күңел ачып яшәүче Сәлим һәм Гайни байлар заманның бөтен тискәре сыйфатларын үзләрендә туплаган типик характерлар югарылыгында сурәтләнә. Шул рәвешчә XX йөз башында иҗат ителгән әсәрләр нигезендә шушы чорны гәүдәләндергән драма әсәре туа. Мәгълүм булганча, «Кәләпүшче кыз» повестенда азгынлык, бозыклык, шәхеснең әхлакый яктан таркала баруы кебек күренешләр гәүдәләнеш таба. Хатын-кызның аяныч язмышы аркылы милләт фаҗигасен биргән «Кәләпүшче кыз» заманында хуплап кабул ителә. Моны шушы уңайдан язылган мәкаләләр дә раслый, мәсәлән, Н. Гасрый әлеге әсәрнең «татар әдәбиятында мөһим бер вакыйга буларак кабул ителүен» [Гасрый, б. 40–41] билгеләп үтә. Й. Акчура Камәр язмышын «милләт тәненә чыккан иң куркыныч, иң агулы чуан»га [Акчура, 1992, б. 26] тиңли. Ф. Мусин фикеренчә, Г. Исхакый бу әсәрендә Камәрнең фаҗигале язмышын яктыртып, «татар кызларын Камәр фаҗигасеннән саклау – милләтнең, аның җан сакчысы булган зыялыларның мөһим бурычы дигән нәтиҗәгә килә» [Мусин, 1998, б. 18]. Галим әдәбиятның да «бу мәсьәлә белән турыдан-туры кызыксынырга һәм аны хәл итүгә үзеннән өлеш кертергә тиешлегенә» [Мусин, 1998, б. 18] басым ясый. Җансыз курчак тормышына дучар ителгән татар хатын-кызларының бәхетсез язмышын Ф. Әмирхан да «Татар кызы» (1909) нәсерендә ачык тасвирлый. Дөньяга ирекле булып туган татар кызының тәкъдирен тора-бара әсәрдә Кара көч була-

рак гәүдәләндерелгән иске татар җәмгыятенең гореф-гадәтләре, ныгып урнашкан тәртипләре хәл итә башлый. Үз исеме, шәхси үзенчәлекләре булмаган, җыелма образ сыйфатында бирелгән Татар кызы Кара көч кулында ирексез бер «җанлы курчак» булып яшәргә мәҗбүр. «Кара көч, татар кызы янына апа, җиңгә, ана, әби... дип төрле исемнәр белән атала торган җанлы курчакларны җибәреп, җансыз курчаклар белән ничек уйнарга кирәклеген өйрәттерде. Җанлы курчакларның чын игътикатларынча (ышануларынча), җансыз курчакларны кунакларга йөртеп, туйлар ясатып, кияүләр кертеп, киленнәр төшертеп, кодагый-кодача, бүләкләр бирештереп... уйнарга кирәк иде» [Әмирхан, 1957, б. 329, 330]. Шул рәвешчә Татар кызы кечкенәдән үк, Кара көч сүзләре белән әйтсәк, «киләчәктәге үз тормышына әзерләнә». Инде кыз бала «җанлы курчаклар» тапкан кияүгә ярәшелеп, дүрт дивар эченә бикләп куелып үзе дә тәмам «җанлы курчак»ка әверелгәч, Кара көч: «Татар кызын терәләй күмделәр бит!» [Әмирхан, 1957, б. 336] – дип тантана итә.

XX йөз башы әсәрләрендә күтәрелгән, безнең көннәрдә дә актуальлеген югалтмаган хатын-кыз язмышы проблемасын М. Гыйләҗев белән Р. Хәмид, бүгенге көн күзлегеннән карап, киңрәк планда яктырталар. Әсәрдә Камәр, аның гаиләсе, үги әтисенең кызы Хәдичәнең фаҗигале язмышы аркылы шул чордагы хатын-кызларның тормышы, гомумән, гади халыкның аяныч хәле гәүдәләндерелә. Пьесада Сәлим – иң көчле кара байларның берсе. Бернәрсә дә аның теләгеннән узып эшләнми. Бай йортындагы бер күренешкә игътибар итик: «...зур кунак бүлмәсенә янәшә берничә ишекле кечерәк алгы бүлмәсе күренә. Иң башлап күзгә ташланганы – парпар курчаклар тезелгән шкаф» [Гыйләҗев, Хәмид, 2001, б. 2]. Пьесада курчаклар – Сәлим бай, аның партнёры Гайни бай образларын ачучы һәм кешеләр язмышын билгеләүче символик образлар. Байлар тарафыннан уздырыла торган курчак туе күренеше аркылы драматурглар кешеләрнең көчлеләр кулында «курчак» кына булуларын күрсәтергә теләләр. Власть кемнең кулында, шул кешеләр белән курчак уены уйный ала. Курчаклар «язмышы» шул чор мохитен тулырак күзалларга ярдәм итә.

Комсыз, кабахәт Сәлим бай кешеләр язмышын курчаклары белән уйнаган кебек кенә хәл итә: астыртын максатларын эшкә җигеп, теге яки бу кешене үзе теләгән башка берәүгә өйләндерә яки кияүгә бирә, аларның теләкләре белән исәпләшми. Курчакларны Сәлим байга бер ай элек кенә Кабан суына батып үлгән вак сәүдәгәр Гәбдерәшитнең аннан тол калган хатыны Кәримә белән унбиш яшьләрдәге житеп килә торган кызы Камәр тегә. Матур курчаклар тегеп, аларны бай кулына тапшырган ана белән кызның үз язмышларын да ул билгеле. Сәлим картның курчак кебек чибәр, саф кызга күзе төшә. Үзен «дөньяның тоткасы» итеп күргән бай образында капиталистик

җәмгыять шартларында хатын-кызларны бәхетсез язмышка дучар иткән төп сәбәпче көчләрнең берсе гәүдәләнә. Пьесада бер кызыклы деталь игътибарны җәлеп итә: кәләпүшчеләр соңгы тапкыр тегеп китергән курчаклар приказчик Вафа белән Камәргә бик охшаган булып чыга. Мондый хәлгә байның ис-акыллары китә. Бу – егет белән кызның язмышлары да Сәлим бай теләгәнчә хәл ителәчәк дигәнгә ишарә кебек.

Йортлары яну сәбәпле, Вафаның гаиләсе банктан ссуда алган була. Шуны вакытында кайтара алмаган өчен, этисенең эше судта икән. «Мәрхәмәтле» Сәлим бай, үзенең бер шартын үтәү бәрабәренә, егетнең бурычын үз өстенә алачагы турында хәбәр итә. Вафа, кызның башын әйләндереп, кешеләр алдында аның яманатын таратырга тиеш була. Бу эшкә күңеле ятмаса да, егет баена күнмичә булдыра алмый. Байлыгы ягыннан аннан аз гына калышучы партнёры урта хәлле сәүдәгәр Гайни бай да аның эчен пошыра: Сәлим бай сүзләре белән әйтсәк, «ике тәкә башы бер казанга сыймый» икән. Ул, Гайни байның үзенә зур бурычы булуыннан файдаланып, аны тол хатын Кәримәгә өйләнергә күнди. Өйләнә калса, бурычын түләү вакытын кичектерүе турында әйтә, каршы килгән очракта банкрот калдырачагы хакында кисәтә. Бурыч мәсьәләсенең кинәт кенә өйләнү мәсьәләсе белән бәйләнеп китүен Гайни бай аңламый да, өнәми дә. Алар диалогына игътибар итик:

*Гайни бай. Менә бу телсез курчакларны гына ул, ризалыкларын сорап тормыйча, өйләндереп була, хи-хи-хи... Тик шунсы зәһәр: үзләре җансыз булсалар да, синең кулда бик каты кылananалар икән!*

*Сәлим бай. Озын сүзнең кыскасы, син риза? Зөһрә карчыкны иртәгә үк... юк, бүген үк Кәримәгә җибәрәбез – «эһ» тә итми аның ризалыгын алып кайтачак ул.*

*Гайни бай. Туктале, Сәлимҗан кордаш... Кызык миңа... Соңгы сүземне әйтмәдем бит мин, хи-хи-хи...*

*Сәлим бай. Соңгы сүзеңне? Ансын син түгел – мин әйтәм! (Кулына кабат кыз курчакны ала). Мин әйткәнчә эшләмәсәң...*

*Гайни бай. (Хуҗаның кулындагы курчакка карап тора). Менә хәзер төшендем шикелле, Сәлим әфәнде... (Хөкем карарын кабул иткәндәй). Яучы карчык тотынсын әйдә... кара эшенә!* [Гыйләҗев, Хәмид, 2001, б. 8].

Күрәбез: Сәлим бай бөтен кешенең язмышы белән рәхимсез кылана. Әлеге диалогта тирән мәгънә ята: Сәлим бай теләсә, тере кешеләрне дә телсез курчакка әйләндерергә мөмкин икән. Бурычка баткан Гайни, үзен Сәлим кулындагы курчакка тиңләп, ул билгеләгән язмышы белән килешергә мәҗбүр була. Гайни байның соңгы сүзендә яучы карчык Зөһрәнең дә нindirәк кеше икәне ачыла. Ул – Сәлим байның куштаны. Кызларны, яшь хатыннарны юлдан яздыруда бу образның роле зур. Ул да – «Кәләпүшче кыз»дагы Зөһрә абыстай кебек үк социаль зарарлы тип. Тыштан караганда әүлия булып күренүче, телгә оста мондый кешеләр

кызларның йөрәк серләрен ала торган булганнар, кызлар һәм яшь хатыннар, аларны үзләрен аңлаучы яхшы күңелле кешеләр дип уйлап, еш ялгышканнар.

Сәлим бай теләгенә ирешә: Вафа белән очраша башлаган кызның, әле гаебе булмаса да, яманатын тиз тараталар. Гайни бай үги кызын йортыннан куып чыгара. Ә Сәлим байга шул гына кирәк тә: урамда калган Камәргә ул «ярдәм кулы»н суза. Зөһрә карчык аркылы кызны бер бүлмәгә урнаштыра. Унбиш яшьлек кыз янына кабахәт ниятен тормышка ашырырга килгән Сәлим бай күз алдына кешелек сыйфатларын тәмам җуйган җирәнгеч, ерткыч бер зат булып килеп баса.

Игътибар үзәгенә алынган әсәрләрдәге Кәримә образлары арасында аерма күзгә ташлана. Повестьтагы Кәримә драмадагы Кәримәгә караганда чагыштырмача иреклерәк кебек. Ул иргә баруда үзе инициатива күрсәтә һәм ире булачак кешегә теләп бара. Ә драма героинясының язмышын Сәлим бай хәл итә. Повестьтагы Кәримә тора-бара иргә чыкканына үкенә дә башлый. Еш кына Габдерәшитен сагына. «Аерылып китәр иде дә, хатын башы берлә йорт-җирсез кая барсын да, ни эшләп торсын?..» [Исхакый, 1998, б. 62]. Тик ирдән китәсе килү сәбәпләре ачык түгел. Драмадагы Кәримә хатын-кызга Сәлим байдан ким карамаган Гайни бай кулы астында изелеп, рәнҗетелеп яши. Гайни бай хатынына хәтта мәрхүм иренең кырыгын уздырырга да ирек бирми: көнли. Драмада ана өчен бала кадере төшенчәсе дә үтемлерәк бирелә кебек. Бу ананың кызының язмышы өчен һәрдаим борчылып торуында чагыла.

Ике әсәрдәге приказчиклар арасында да аерма күзәтелә. Повестьтагы Вафа – әхлакый яктан соңгы чиккә җитеп таркалган, чорның бөтен ямьсезлеген үзендә туплаган типик образ. Кыз бала аның өчен – «тере курчак». Дөньядагы барлык матур хатын-кызны Вафа үзе өчен генә, аңа рәхәтлек китерү өчен генә яратылган дип уйлый. Ул аларны юлдан яздыру максатыннан ягымлы сүзләрен бер дә кызганмый. Драмадагы Вафа – үзе Сәлим бай кулындагы «курчак». Ул, повестьтагы персонаждан аермалы буларак, кешелек сыйфатларына ия. Камәр янына аны мәсхәрә итү теләге белән килгән Сәлим байдан кызны коткарып калучы да Вафа була. Шулай да ул – каршылыклы характер. Сәлим бай кадәр Сәлим байны җилтерәтеп чыгарып ата алган егет кызны, теләгендә булса, фәхешлек юлыннан да алып кала алган булыр иде. Ә ул моңа, киресенчә, күз йома. Шул рәвешчә кызның аңа булган чын хисләрен аяк астына салып таптый.

Ике әсәрдә дә Камәр образларының әхлакый яктан таркалулары, фәхешханәләргә эләгеп, начар чирләр йоктырып газап чигүләре күрсәтелә. Повестьта Камәр кебек намуслы, саф күңелле кызның болай түбән тәгәрәвенең сәбәбе тиешле тәрбия һәм белем җитмәү белән генә аңлатыла. Г. Исхакый, шул чордагы иҗат ысулына тугрылык саклап, тормышта үз кыйбласын югалткан, язмышы карадан-кара

буяулар белән бирелгән бәхетсез Камәрнең капма-каршысы буларак, үги әтисенең яхшы тәрбия алган, белемле кызы Васфибану тормышын бик бәхетле итеп күрсәтә. Драма авторлары исә узган чорга, бүгенге көн күзлегеннән карап, реаль бәя бирәләр. Алар фикеренчә, кешеләр язмышы белән рәхимсез рәвештә курчак уены уйнала торган мәрхәмәтсез бер заманда беркем дә бәхетле була алмый. Пьесада Камәрнең үги әтисенең кызы – сөймәгән кешесенә атасы тарафыннан көчләп кияүгә бирелгән Хәдичә язмышы да, Камәрнеке төсле үк булмаса да, бәхетсезлеге ягыннан анықына бик охшаш. Хәдичәнең үз сүзләре үк шуны раслый: «...дөнья бик катлаулы ул! Менә сине минем әти минем ялваруларга да карамыйча, тотты да бер гаепсезгә көзге салкында урамга куып чыгарды... Минем өчен дә әллә бар, әллә юк ул хәзер! Әти аркасында гына бәхетсез булдым мин... Мәңге бәхиллегем юк аңа! Кая барып сыеныр җирем дә калмады... Яшисе дә килми хәтта! ... Үзем дә курчак булдым шул мин... Ырынбурга китеп барыр идем – әти тапкан ирем талак итми...» [Гыйләҗев, Хәмид, 2001, б. 27]. Әлеге сүзләрдән хатын-кызларның хокуксызлыгы, ирләр кулында «тере курчаклар» гына булулары аңлашыла. Хәдичә – акыллы хатын. Тәҗрибәсез яшь кызга төпле киңәшләр бирүе, Зөһрә кебекләрнең икейөзлелеген аңлап, андыйларны фаш итәргә алынуы хатын-кызларның социаль аңы уяна башлауны күрсәтә. Тик бәхеткә ирешү өчен акыллы, тәрбияле, белемле булу гына җитмәгәнлеген күрәбез. Алар бу дөнья сазы баткаклыгыннан чыгу юлын тапмыйлар. Яшь хатынның үз-үзенә кул салуы, тагы да бер Сәкинә исемлесенең, фәхешханәләрдә газап чигеп, соңыннан ачы йотып үлүе дөньяның кабахәтлекләрен фаш итә, илдә хөкем сөргән деспотизмга протест булып яңгырый.

Ике әсәрдә дә сурәтләнгән Камәрләр – беркатлы, яхшы күңелле кызлар. Тик алар арасында азмы-күпме аерма да бар. Драмадагы Камәр кешеләр язмышын җимерүче, түбән максатларны күздә тоткан Сәлим бай кебекләргә нәфрәтен белдерә ала торган горур, батыр йөрәкле хатын-кыз, кыю характер буларак ачыла. Әсәрдә кызның фәхешханәгә килеп эләгү юллары ачык күрсәтелә. Ялгыз, беркемгә кирәксез, өстәвенә салкын тидереп бик нык авырган хәлсез кызга «ярдәм кулын» фәхешханә тотучы әхлаксыз хатын Наташа суза. «Кызыл йорт» дип исем алган фәхешханәләрнең күңел кайтаргыч күренешләре, анда килеп эләккәннәрнең мораль һәм физик яктан таушала барулары драмада шушы һәм башка образлар аркылы ачык гәүдәләндерелә. Әлеге «йортлар»ның Сәлим, Гайни кебек байларның яратып йөри торган «йортлар» булуы да аңлашыла. Аларның җансыз курчаклар белән генә түгел, «җанлы курчаклар» белән дә комсыз һәм рәхимсез рәвештә «сату-алу уены» уйнаулары фаш ителә. Сәлим бай үзе шушы юлга этәргән кызны фәхешханәдә күргәч имәнеп китә; самими, саф бер

кәләпүшче кызның шундый хәлгә төшүенә ышанырга теләми. Кайчандыр аңа матур курчаклар тегеп биргән Камәр хәзер үзе матур «курчак»ка әверелгән. Кем аның белән уйнарга тели – шул уйный ала. Сәлим байлар теләгән тормыш шушы түгелме соң инде?! Кинәт кенә газиз баласыдай якын булып киткән, кызны бу мәшхәр йортыннан алып китү теләге уянган Сәлим байга Камәрнең әйткән сүзләре дә шуны раслый:

*Сәлим бай:*

*– Камәр! Синең урының түгел бу чучка базы...*

*Камәр:*

*– Мин моннан китсәм, сез байлар нишләрсез?!* [Гыйләҗев, Хәмид, 2001, б. 42]. Хатын-кызларның мондый түбәнчелеккә төшүләренә карата әсәрдә «бу хәлләргә менә сез байлар, ирләр үзегез гаепле» дигән фикер уздырыла кебек. Шул рәвешчә драмада, повестьтан аермалы буларак, шәхесне әхлакый-физик яктан таркатучы фәхешлек күренешләренең, рухи изелгәнлекнең, кешеләр язмышының аянычлы нәтиҗәләренең социаль һәм шәхси сәбәпләре ачык күрсәтелә; яшь, гөнаһсыз, бер ярдәмчесез калган хатын-кызларны юлдан яздыручы Сәлим бай, Наташа кебекләргә нәфрәт хисе белдерелә.

Пьесаның конфликты да социаль һәм шәхси каршылыклардан гыйбарәт. Бер якта – Сәлим, Гайни байлар, ягъни көчлеләр лагеры, икенче якта – Кәримә, Камәр, Хәдичә кебекләр, ягъни байлар теләгенә буйсынырга мәҗбүр булган чарасызлар. Әлеге хатын-кызларның язмышы гаделсезлек хөкем сөргән җәмгыятьтә аларның хокуксызлыгы котылгысыз булуын раслый.

Йогышлы чир эләктереп, хастаханәгә килеп эләккән Камәр караваты янында аунап яткан тегелеп бетмәгән курчак иҗтимагый-символик мәгънәгә ия. Бу – рәхимсез җәмгыять «ватып ыргыткан» Камәр үзе. Ул үзен шушы хәлгә төшерүче байларга, аларның коткысы белән эш итүче Наташа, Зөһрә карчык кебекләргә ләгънәт укый. Мондый эшләрнең бервакытта да кичерелмәячәгенә басым ясый:

*– Мәңге бәхиллегем юк сиңа, Сәлим бай!* [Гыйләҗев, Хәмид, 2001, б. 57]. Ахыр чиктә повестьтагы Камәр кебек үк драмадагы Камәр дә йон юучы бомжлар арасына килеп эләгә, элекке яшәү рәвешен дәвам итеп йөкле була.

Кайчандыр көче, кодрәте бар чагында кешеләр язмышы белән кулындагы курчакларны уйнаткан кебек кыланган Сәлим бай соңыннан үзе дә, «адәм сәләмәсе» булып, бомжлар арасында йөри, кешелек юлыннан язган Камәр янына барып эләгә. Димәк, язмыш дигән усал көч теләсә кемне «курчак»ка әйләндерә ала икән, хәтта Сәлим байны да. Бу уңайдан Камәр сүзләре игътибарга лаек: «...Кыяфәтең кара, Сәлим байның шәүләсе!.. Син бит хәзер... Чүплек башына чыгарып ташланган иске курчак бит син хәзер! Элек син безнең белән курчак уены уйный идең, хәзер синең үзеңне дөнья курчакка әйләндергән!» [Гыйләҗев, Хәмид, 2001, б. 55].

Социаль чыгышлары ягыннан төрле булган ике кешене

янәшә куеп сурәтләүдә тирән мәгънә ята. Шул рәвешле байлык, көч, кодрәт белән шапырынып йөрү, үзеңнән көчсезләрне рәнҗетү яхшыга илтми, чөнки болар берсе дә мәңгелек түгел, тормыш кешене һәрвакыт сынап тора, көннәрдән-беркөнне үзең көлгән, кимсеткән кешеләр хәленә төшәргә, алардан да аянычрак хәлдә калырга мөмкинсең дигән нәтиҗә ясала. Р. Батулланың бер пәрдәлек «Курчаклы уен» пьесасында да шуңа охшаш фикер уздырыла. Әлеге әсәрдә дә курчаклар уены аша җитди иҗтимагый һәм әхлакый проблемалар яктыртыла. Автор җир йөзендәге бөтен кешене дә курчакларга тиңли, кайчандыр һәркемне үзенә буйсындырып, аның язмышы белән уйный алган «курчак уйнатучы»ның көннәрдән-бер көнне үзенең дә гади бер курчакка әверелү мөмкинлеген, ә элекке «курчагы»ның, уйнатучы роленә күчеп, аның үз язмышын хәл итә башлау ихтималын дәлилле күрсәтә [Батулла, 2008, б. 218–227]. Күрәсең, бу – яшәешнең элек-электән килгән бик тә үзенчәлекле бер закончалыгыдыр.

Камәрнең, үзен чит иткән, үгисеткән, түбәнсеткән газиз туган ягы Казанны, андагы кешеләрне калдырып, «җылырак якларга» китәргә җыенганда «кинәт бай» Вафага әйткән сүзләре әһәмияткә ия: «...Казанга беркайчан да борылып кайтмаячакмын мин!.. Казанда гел туңа идем мин... Хәзер аңладым: анда синең кебек кешеләр күп булганга боз кебек салкын! ...Җылырак якларга китәм... Әнә таныш алкашлар миңа бушлай плот ясап бирделәр. Алар мине аңлыйлар... Ә син, Вафа, беркайчан да аңламадың! Син дә, әни дә... Елга буйлап агып китәм. Мондагы бөтен елгалар җылы якка агалар» [Гыйләҗев, Хәмид, 2001, б. 57]. Шул рәвешчә әсәрдә «кеше матди байлыгы белән түгел, ә рухи байлыгы, кешелеклелеге белән көчле һәм матур» дигән фикер уздырыла. Әлеге күренеш шулай ук рәхимсез, ваемсыз җәмгыятькә, иҗтимагый гаделсезлекләргә карата протест төсен ала.

Драмадагы Вафа сүзләреннән курчаклар җитештерү эшенең үсүе, аларның кулланылыш даирәсенең киңәюе аңлашыла: «Яңа цех ачтым мин. Курчаклар җитештерәбез. Шәп үтә торган тауар! Чит илләргә дә чыгарабыз!» [Гыйләҗев, Хәмид, 2001, б. 58]. Бу исә пьесаның иҗтимагый вазгыятен тагын да көчәйтә. Әсәрдә Сәлим һәм Гайни байлар образлары дөм начар итеп кенә дә бирелми. Аларның яхшы яклары да күрсәтелә. Мәсәлән, Гайни бай, бер приказчигының аягы сынгач, үз акчасына аны Мәскәүгә дәваланырга җибәрә. Кияве «мескен мәхдүм»не, кызына өйләндергәнче, Бохарага җибәреп укыта. Сәлим бай исә үзендә эшләүче Вафаны өлкән приказчигы итеп күтәрә. Ә үзе картаймыш көнендә, үз сүзләре белән әйтсәк, аның аркасында гына «сәнәктән көрәк булган эсвежи купислар»дан таланып, урамга чыгарып ташлана. Болар – тормышчанлыкны көчәйтүче күренешләр.

Пьесада тагын бер янәшәлеккә игътибар итик: гомер буе гаилә корып, балалар үстереп,

бәхетле яшәргә хыялланган Сәлим бай да, балалар сөяргә теләгән Наташа да хыялларына ирешә алмыйлар. Бер яктан, бу аларның шәхси фаҗигаләре булып күзаллана; икенче яктан, алар корган гаделсез җәмгыятьнең үзләренә дә бәхет китермәгәне аңлашыла; өченчедән, бозыклык, явызлык, рухи ярлылык хөкем сөргән андый җәмгыятьнең киләчәге юклыгына ишарә дә булып тора. Әдипләр, шәхеснең әхлакый яктан таркалу сәбәпләрен күрсәтеп, аларга тискәре мөнәсәбәтләрен белдереп, рухи матурлык, әхлакый камиллек, саф хисләргә нигезләнгән мәхәббәт, гаилә бөтенлеге, хатын-кыз бәхете, кешеләрне бәхетле тыныч тормышка ирештерүче гадел җәмгыять мәсьәләләрен күтәреп чыгалар. Повестьтагы тәртипсез яшәү рәвеше алып барудан йөкле булган Камәрнең фаҗигале тәмамланган язмышыннан аермалы буларак, драма героинясы исән кала. Тормышның ачысын-төчесен күп күргән яшь ана карынында яңа бер җанның яралуы, ананың үзе һәм баласы хакына ямьсез тормышны ташлап «җылы якларга» китәргә җыенуы матур киләчәккә өмет билгесе кебек аңлашыла. Яктылыкка, бәхеткә өмет уятучы мондый күтәренке рухлы йомгак әсәргә яңа төс бирә.

Драматургларның узган гасыр башында төрле шәһәрләрдә «чәчәк аткан» фәхешлек проблемасын бүген яңадан күтәреп чыгулары бер дә юкка түгел. Бу – безнең көннәрнең дә рухи-әхлакый чире, зур фаҗигасе. Әдипләр кешеләрне уйланырга чакыралар, язмыш дигән олы көч кулында һәркемнең дә «курчак» кына булуын онытмаска киңәш итәләр.

«Курчак туе» драмасы буенча куелган спектакльнең премьерасы 2009 елның 8 ноябрендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында була һәм тамашачы тарафыннан җылы кабул ителә. Спектакльнең режиссёры – Ф. Бикчәнтәев. Режиссёр һәм актёрлар тамашачы игътибарына уйланырлык һәм гыйбрәт алырлык спектакль тәкъдим итәләр. Әлеге спектакльнең даими рәвештә куелуы анда күтәрелгән проблемаларның бүген дә актуальлеген югалтмавы турында сөйли. Сәхнә бизәлеше, пластика, актёрларның сәхнәдә тышкы кыяфәтләре белән дә, хәрәкәтләре белән дә чын курчакларга охшап образга керүләре, һәр детальнең уйланылган булуы сокландыра. Эчтәлек тулысынча ачыла, читкә тайпылыш күзәтелми, драма авторлары җиткерергә теләгән фикер тамашачы аңына төгәл барып ирешә дип әйтү урынлы булыр. Гомерләрен сәхнә эшчәнлегенә багышлап, олы тәҗрибә туплаган ТР һәм РФнең халык артистлары А. Гайнуллина, Ә. Шакиров, ТРның халык, РФнең атказанган артистлары Р. Мотыйгуллина, А. Хафиз, ТРның халык артисты Р. Юкачёва белән беррәттән яшьләр дә – Н. Хәйруллина, Р. Бариев, Р. Вәҗиев, Л. Фәйзуллиналар – һәркайсы үзенә билгеләнгән рольне җиренә җиткереп, образга тирәнтен кереп, тамашачы күңелен кузгатырлык итеп башкаруы белән ихтирам уята.

**Әдәбият**


*Акчура Й.* Гаяз әфәнде // Мирас. 1992. № 6. Б. 26–28.

*Әмирхан Ф.* Татар кызы // Повестьлар, хикәяләр. Казан: Таткнигоиздат, 1957. 1 т. Б. 327–336.

*Батулла Р.М.* Курчаклы уен // Сайланма әсәрләр: 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 3 т. Б. 218–227.

*Гасрый Н.* Шимали төрки әдипләреннән Гаяз Исхакый // Мирас. 1994. № 10. Б. 39–41; № 11–12. Б. 30–37.

*Гыйләҗев М., Хәмид Р.* Курчак туе: Драма. Казан. 2001. 58 б. (Кулъязма).

*Исхакый Г.* Кәләпүшче кыз // Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 1 т. Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). Б. 50–78.

*Исхакый Г.* Ике йөз елдан соң инкыйраз // Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 1 т. Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). Б. 154–270.

*Котб.* Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман). Казан: Мәгариф, 2003. 367 б.

*Мусин Ф.* Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 191 б.

*Хайям О*. Рубаи. М.: ЭКСМО-Пресс, 2002. 352 с.

*Ханзафаров Н.Г.* Истоки, зарождение и формирование комедии // Татарская комедия. Казань: Фэн, 1996. 268 с.



***Каюмова Гөлия Илдус кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты Энциклопедистика үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***Җ.Н. Мотыйгуллин, М.Җ. Мотыйгуллина***

# Г.М ТУКАЙНЫҢ «ЯШЬЛӘР» ҺӘМ М.Ю. ЛЕРМОНТОВНЫҢ «ДУМА» ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЯШЬ БУЫН

Статья посвящена сравнению произведений Г. Тукая «Яшьләр» и М.Ю. Лермонтова «Дума». Русского и татарского поэтов, живших в разные эпохи, объединяет одна общая тема, общая проблема и боль: настоящее и будущее своей страны, судьба родного народа, своего поколения. И в этом русский и татарский поэты во многом схожи – как в плане творчества, так и в контексте их биографии.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, М.Ю. Лермонтов, влияние русской литературы на татарскую, тема «молодого поколения».

Һәр буынның да үз өметләре, хыяллары була. Алар тормышка ашарга да, ашмаска да мөмкин. Һәр буынның да диярлек проблемалары булган, бар һәм булачак. Әмма һәрбер тарихи чорда, һәр буында көрәшүчеләр дә, читтән генә күзәтүчеләр дә булган. Һәркемнең үз тормышы, үз юлы: кемдер үзенең кызыксынуларын, үзенең киләчәген җәмгыять һәм киләчәк буын игътибарыннан өстен куя, ә кемдер, киресенчә, үзен изгелек өчен көрәшкә багышлый.

Үз буын вәкилләренең язмышына битараф карый алмауның ачык мисалы М.Ю. Лермонтов һәм Г. Тукай иҗатында ачык чагыла. Ике шагыйрь дә үз буынының язмышына дулкынланган, борчылган. Бу темага кагылышлы уйларын һәм фикерләрен алар үзләренең «Дума» (1838) һәм «Яшьләр» (1910) шигырьләрендә ачык белдерәләр.

Г. Тукай иҗаты күп кенә тикшеренүчеләрне әдәби элемтәләр контекстында үзенә җәлеп иткән. Мәсәлән, татар шагыйре иҗатын рус әдәбияты белән чагыштыру М. Пехтелев, мәгълүм востоковед-тюрколог В.А. Гордлевский хезмәтләрендә [Пехтелев; Гордлевский] анализланган. Бу хезмәтләрдә галимнәр татар шагыйренең иҗатын комплекслы якын килеп өйрәнәләр – төрки әдәбиятның үсеше күзлегеннән дә чыгып һәм рус әдәбиятының татар әдәбиятына йогынтысы планында да. Г. Тукайга багышланган тикшеренүләрнең зур күпчелегендә, аның «коеп кына куйган шагыйрь» түгеллеге һәм аның үз халкына, әдәбиятына хезмәт итүе язмыш тарафыннан алдан билгеләп куелган булуы ассызыклана. Бу нисбәттән Г. Халитның «Габдулла Тукай и татарское литературное движение начала XX века» китабындагы [Халит, 232 с.] шагыйрь иҗатына күзәтүләр аеруча игътибарга лаек. Автор Тукайның XX гасыр башы татар әдәбиятындагы индивидуалистик агымнарга кушылмаганлыгын ассызыклый һәм рус әдәбияты татарныкына

йогынты ясарга тиеш түгел дип санаучы шагыйрьләргә, язучыларга, сәнгать эшлеклеләренә кискен каршы чыга.

Тукай иҗатындагы кайбер әсәрләр М.Ю. Лермонтов әсәрләре белән аваздашлар. Шундыйларның берсе – Тукайның «Пәйгамбәр» шигыре. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, иң элек һәр ике шагыйрьне дә шагыйрь һәм шигърият темасы, кешенең язмышы борчый: шуңа да, Тукай пәйгамбәрлеге, Лермонтовныкы кебек үк, дөреслекне, хаклыкны яклаучы, чын күңелдән Ходайга ышанучы буларак чыгыш ясавы очраклы түгел.

Бу шагыйрьләрнең иҗатында шагыйрь һәм шигърият темасы туган ил темасы белән тыгыз бәйләнештә. Алар өчен туган ил – аларның яшәү мәгънәсен тәшкил итүче бар нәрсә дә (моңа мисал итеп Лермонтовның «Родина» (1841) һәм Тукайның «Туган җиремә» (1907) шигырьләрен китерергә була). Тикшеренүче В.Р. Әминева билгеләп үткәнчә, Лермонтовта туган ил темасы «в широком эпическом плане <…> в величественнопространственных, развернутых вширь эпических картинах, символизирующих широту национального самосознания», ә Тукайда «через глубокое, эмоционально насыщенное, личное переживание проступают обобщения широкого художественно-психологического плана» [Аминева, с. 8].

Бу ике тема ике шагыйрь иҗатында билгеле бер юнәлеш тудыралар. Аларның фикере буенча, туган ил һәм үз халкыңның язмышы өчен җаваплылык иң элек шушы илнең гражданнарына һәм үз язмышларын туган җиргә хезмәт итүдә күрүче аның «пәйгамбәрләренә» – шагыйрьләргә төшә. Ләкин һәр буынга да үз мөмкинлекләрен тулысынча күрсәтү мөмкин булмый. Заманалар төрле булу сәбәпле, кайвакытта тулы бер буын үзенең хыялларын тормышка ашыра алмый һәм, нәтиҗәдә, иленә дә, үзенең халкына да ярдәм итү мөмкинлеге булмый. Менә шуңа да бу проблемага XIX гасырда рус шагыйре М.Ю. Лермонтов һәм XX гасырда татар шагыйре Г. Тукай мөрәҗәгать итә дә инде.

...Лермонтов Михаил Юрьевич (1814–1841) әнисе үлгәннән соң әбисе белән яши, ә 1830 елда Мәскәү университетының әхлакый-сәяси бүлегенә укырга керә.

Университет философия һәм сәяси кызыксынулар белән яши, анда студентлык түгәрәкләре һәм җәмгыятьләр эшли. Лермонтовның аларда катнашуы хакында төгәл мәгълүматлар юк, әмма шагыйрь үзенә хас булган сәяси каршылык рухын фикердәшләре белән уртаклашкандыр дип чамаларга мөмкин.

1832 елда Лермонтов, Петербург университетында укуын дәвам итәргә өметләнеп, Петербургка күченә, әмма аны укырга алмыйлар һәм шагыйрь туганнарының киңәшен тотып хәрби эшне сайлый. Ул күп яза. Аның барлык әдәби әсәрләре дә ул булган урыннар, аралашкан кешеләр, яшь шагыйрь тормышындагы вакыйгалар тәэсирендә иҗат ителгәннәр. Әмма ул үзенең беренче әсәре «Маскарад» драмасын бастыра башлагач, цензура

белән очраша. Шагыйрь әсәрен өч тапкыр драматик цензурага тапшыра, ике тапкыр үзгәртә, әмма драмага, шагыйрьнең бик нык тырышуына карамастан, басылырга рөхсәт бирелми.

1837 елның 18 февралендә Лермонтов кулга алына, «тыелган шигырьләре» өчен сәяси эш кузгатыла. 1837 елның февраль аенда Лермонтовны Кавказга Нижегород драгун полкына прапорщик итеп күчерү турында приказ чыга. Монда Михаил сөргенгә сөрелгән декабристлар белән таныша. 1838 елда Петербургта ул үзенең «Дума» шигырен яза.

1840 елга кадәр Лермонтов әле драмаларын, тәмамланмаган әсәрләрен исәпкә алмыйча 400 шигырь, 30 га якын поэма яза. Үзе исән вакытта ук шигырьләр җыентыгы һәм «Герой нашего времени» басылып чыга, ә күпчелек әсәрләре вафатыннан соң гына дөнья күрә. 1838–1840 елларда шагыйрь «Кружок шестнадцати»га керә. Ул корпоратив тәртип һәм сәяси оппозицион катнашучыларның гомуми законнары белән берләшкән аристократик яшьләр җәмгыяте була. Ә 1841 елда шагыйрь Юнкерлар мәктәбе буенча дустының пулясына эләгеп, дуэльдә үлә.

Габдулла Тукай (1886–1913) дүрт яшьлек чагында тома ятим кала, асрарга алган гаиләдә тәрбияләнә. Габдулла кечкенәдән авыр крестьян тормышын күреп, үзе дә эшләп үсә. 1895 елда Уральскидагы туганнарына күченеп килә һәм анда шагыйрьнең балачак, яшүсмер еллары уза. Уральскида ул мәдрәсәдә укый, өстәмә рәвештә рус классына да йөри.

Тукай нәкъ менә шәһәрдә яшәгән вакытта илдә революция башлана һәм ул яшь, кызыксынучан шагыйрьнең киләчәк тормышына һәм иҗатына үз эзен сала. Бу чорда Тукай әдәбият өлкәсендә үзенең беренче адымнарын ясый башлый. Ул революция тарафыннан күтәрелгән темаларны үз эченә алган күпсанлы шигырь һәм мәкаләләрен бастырган төрле нәшриятлар белән хезмәттәшлек итә башлый. 1907 елда Тукай мәдрәсәне ташлый, революция сүрелә һәм властьлар Тукай хезмәттәшлек иткән татар басма матбугатын тыялар.

Шушы ук елның көзендә Тукай Казанга килә һәм бик тиз генә әдәби даирәгә керә, яшьләр белән аралаша. Иҗатының тәүге чорларында ук ул үзенең милләтенә мәхәббәтен, халкына хезмәт итәргә теләвен һәм властьларның басымы белән килешергә теләмәвен ачыктан-ачык белдерә:

Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә
Мәгълүмдер ки, курку белән өркү «хәрам»

(«Бер татар шагыйренең сүзләре»)
[Тукай, с. 57]

Тукай әсәрләрен журналларда бастырган. Реакция елларында аның сәламәтлеге бик нык какшый, әмма 1911–1912 елларда ул үзе өчен зур мәгънәгә ия, файдалы очрашуларга бай булган берничә сәяхәткә чыгып керә.

Казанга ул 1912 елның августында кайта. Типографиядә эшли, үзен начар хис итсә дә, язуын дәвам итә. Тукайның соңгы еллардагы эшчәнлеге ана-

литик характерга ия була. Ул үз халкының яшәү дәрәҗәсе, аның җәмгыять белән каршылыкта булуы, гомумән, үзенең гражданлык намусына тигән һәрнәрсә турында да язган. 1913 елда Габдулла Тукай үлә. Ул дөньядан, таланты ташып торган чагында, авырудан китә.

Татар шагыйренең иҗаты хакында уйланганда янә бер фактны искәртеп узарга кирәк – Тукай шигырьләре арасында Лермонтовтан ирекле тәрҗемәләр шактый. Болар «Пәйгамбәр», «Тәэссер», «Вәгазь», «Алдандым» һ.б. «Лермонтов буенча» яки «Лермонтовка ияреп» дигән билгеләр белән басылганнар. Тукайның «Яшьләр» шигыре Лермонтовтан тәрҗемә түгел. Анда бернинди дә билге куелмаган, искәрмә ясалмаган. Шуңа да карамастан, бу шигырьдә Лермонтовның «Дума» шигыре белән гомум уртак мотивларны табарга була.

Ике шагыйрьнең дә тормыш юлы билгеле бер образда аларның иҗатларында да чагылыш таба. Ике шагыйрь дә Россиядәге мөһим сәяси вакыйгалар чорында яшиләр һәм иҗат итәләр. Болар – 1825 елдагы Декабристлар восстаниесе (Лермонтов) һәм 1905 елгы Беренче рус революциясе (Тукай). Бу зур вакыйгалар каты реакция елларына китерде. Саксыз әйтелгән сүз өчен кешене сөргенгә, каторгага җибәрергә яки дар агачы күтәргә мөмкин иде. Шул чордагы җәмгыятьтә каушап калу һәм яхшы үзгәрешләргә өметне югалтудан төшенкелек хакимлек итә. Болар барысы да әдәбиятта чагылыш таба.

Лермонтовның 1838 елда сөргеннән кайткач Санкт-Петербургта язган «Дума» шигыре – ул үпкә белдерү. Сөргендә кичергәннәр һәм декабристлар белән аралашу Лермонтовны әлеге шигырьне язарга рухландырган (яки мәҗбүр иткән?) дип күзалларга мөмкин. Декабристларның идеяләре, дөньяга карашлары, көрәш дәрте һәм килешергә теләмәүләре шагыйрь күңелендә искиткеч хисләр калдыралар. Ул бу шигырьләрендә әйләнә-тирәсен, үз-үзен яңадан бер кат күздән кичерә. XIX гасырның 30 нчы елларында яшьләр тормышы яшәү мәгънәсен югалткан һәм файдасыз кебек күренә.

«Печально я гляжу на наше поколенье!
Его грядущее – иль пусто, иль темно,
Меж тем, под бременем познанья и сомненья,
В бездействии состарится оно».

[Лермонтов, с. 31–33].

Декабристлар восстаниесе бастырылганнан соң, реакция елларында, кешеләрнең бернинди дә гамәл кылмаулары, башлаган эшне дәвам итәргә теләмәү автор өчен аңлашылмый. Лермонтов «Дума»ны читтән бер караш формасында яза. Ләкин «без» («мы») алмашлыгын еш куллана:

«Мечты поэзии, создания искусства
Восторгом сладостным наш ум не шевелят;
Мы жадно бережем в груди остаток чувства –
Зарытый скупостью и бесполезный клад.
И ненавидим мы, и любим мы случайно,

Ничем не жертвуя ни злобе, ни любви,
И царствует в душе какой-то холод тайный,
Когда огонь кипит в крови».

Димәк, шагыйрь үзен бернәрсә дә эшләмәүче җәмгыятьтән аерым куймый. Авторның кайгысы һәм күңелсезлеге үз-үзенә карата да юнәлтелгән. Белинский әлеге әсәрне шигырь-тәүбә дип атаган. Лермонтов тормыштагы үзенең яшәү образын янә бер кат күңеленнән үткәрә:

«К добру и злу постыдно равнодушны,
В начале поприща мы вянем без борьбы;
Перед опасностью позорно малодушны
И перед властию – презренные рабы».

Җәмгыятьтә хөкем сөргән вакыйгаларны шагыйрь гади сүзләр белән сурәтли. Кешеләр Николай I вакытындагы реакция алдында, каршылык күрсәтергә омтылмыйча, башларын ияләр:

«Мы иссушили ум наукою бесплодной,
Тая завистливо от ближних и друзей
Надежды лучшие и голос благородный
Неверием осмеянных страстей».

Лермонтов югары даирәдәгеләр белән аралашкан, үзе дә белем алган һәм аның даирәсендә дә белемле, аң-фикерле кешеләр булган. Аларның күбесе шул заманның гадәттән тыш сәләтле кешеләре саналганнар. Шагыйрь ни өчен кешеләр үзләренең аң-белем, көч-куәтләрен көрәшкә юнәлдермәүләрен, тыныч тормышка өстенлек бирүләрен аңлый алмый.

Шигырь катлаулы. Юллар арасындагы сүлпән элемтә фәкать шигырьнең гомуми стилистикасы һәм кәефе белән генә саклана. Лермонтов һәркем үзенчә аңлый торган бик күп метафоралар куллана:

«И предков скучны нам роскошные забавы,
Их добросовестный, ребяческий разврат;
И к гробу мы спешим без счастья и без славы,
Глядя насмешливо назад»

Миңа калса, шигырьнең иң көчле юллары шушылар. Әлеге дүрт юл Лермонтовның әдәби талантының бөтен көчен күрсәтә. «Балаларның» «әтиләре» юлын дәвам итәргә теләмәүләре, үз тормышыңны «бәхеттән һәм дандәрәҗәдән башка» тиз генә уздырып җибәрү кебек фразалар метафораларга яшерелгән. Ә алда хөкем карары, ыңгырашу кебек яңгыраучы йомгаклау, нәтиҗә:

«Толпой угрюмою и скоро позабытой
Над миром мы пройдем без шума и следа,
Не бросивши векам ни мысли плодовитой,
Ни гением начатого труда.
И прах наш, с строгостью судьи и гражданина,
Потомок оскорбит презрительным стихом,
Насмешкой горькою обманутого сына
Над промотавшимся отцом»

Лермонтов менә үзенә дә, үзенең замандашларына да, ваемсызлыклары, иҗтимагый-сәяси көрәштән баш тартканнары өчен,

шулай кискен төстә бәя биргән. Цензура һәм сөрген белән таныш булгач, ул тормышта хакимлек итүче явызлыкка каршы ваемсыз була алмый. Иҗтимагый тормышка салкын караш – ул кешенең рухи яктан үлеме.

Габдулла Тукай «Яшьләр» шигырен 1910 елда, сәламәтлеге инде шактый какшаган вакытта яза. Лермонтовтан аермалы буларак Тукайда инде кечкенәдән үк дөньяга караш төгәл формалашкан, үз халкының яхшы тормышы өчен көрәшү теләге көчле булган. Үзенең әдәби талантын хакимияттән көлүгә, аңа каршы көрәшүгә багышлагач, ул бу эшләрдән читтә торган яшь, көчле, сәламәт, белемле кешеләрне аңламаган. Әлеге әсәр шушы уй-фикерләр белән язылган да:

«Бара милләт зәгыйфь, абныр-
абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.
Кичә якты вә милли бер күңелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас»

[Тукай, с. 76].

Лермонтов шигыреннән аермалы буларак, монда үзанализ да, мәгънәсенә яңадан кайтып уйлану да юк. Монда кайгы һәм берни дә кылмауны аңлау. Беренче юлны ике төрле мәгънәдә кабул итәргә мөмкин. Беренчесе – революциядән соңгы елларда хакимият басымы астында яшәгән үз халкы өчен кайгырту, аның томышын сурәтләү. Икенчесе – кем бернинди дә гамәл кылмый, аларга адресланган. Бу кычкыру түгел, бу тыныч кына фактны дәлилләү. Шагыйрь үз милләтенең мөмкинлекләренә ышана һәм шуңа да ни өчен үзләренә ирекле киләчәккә зур өметләр баглаган аның замандашлары, яшь кешеләрнең ваемсыз булуларын аңламый:

«Тәти тапса сабый барган юлында,
Йомыш истән чыгар, һич айрылалмас.
Шулай яшьләр дә: юлда күрсә алтын,
Баюдан башка күңлен дә салмас.
Сатучылык итә бездә мөхәррир,
Әдип исме аңар тагылмас»

Мөган, бу юлларны ул «алтын яшьләр»гә адреслыйдыр. Габдулла Тукай кулында кечкенәдән хакимият тә, акча да булмый. Ул белем алу, эшкә урнашу өчен, үзен ишетсеннәр, белсеннәр өчен куллары белән җир тырмаша-тырмаша эшли. Актив гамәлләр кылып үзгәрешләргә ирешергә, халкына барып җитәргә мөмкин булуына ул бернигә дә карамастан ышана. Шул ук вакытта Тукай, кулында власте да, акчасы да була торып, үзенең ватандашларының хәлен җиңеләйтергә тырышмаучыларны да чын күңелдән аңламаган:

«Яралганмы бу яшьләр күңле әллә
Мөрәүвәт маддәсе ягьлыр-ягылмас?
Ышынабыз халык көчсезлегенә,
Бабайлар шөһрәтен сагъныр-
сагынмас?»

Тукай шигырендә кем кулларын салындырган, күңелен төшергән, берни дә эшләп карамыйча, алдан ук эшнең мәгънәсезлегенә ышанганнарга да мөрәҗәгать итә:

«Тотып милләт ливасын, юлга
чыктык:
«Бу куллар мәңге, дип, җиргә
салынмас.

Җыгылдык без икөч чакрым да
китми, –
Җегетләр! Бездә көч юк, – ахры,
булмас!»

Тукай әсәрләрендә үгет-нәсихәт жанры билгеләре чагыла. Ул яшьләрнең иң яхшы сыйфатларын кире каккан булып, үз идеалына яраклаштыра: ирләр турында күзаллау һәм яшьләрнең эчке ирекләре, бигрәк тә иҗат белән шөгыльләнүчеләрнең.

Тукай, «азатлык юлының» авырлыкларын үзендә сынап караган кеше буларак, аның җиңел түгеллеген таный. Мин уйлыйм, ул шигырендә мөрәҗәгать иткәннәрнең күпчелегенә ышанса, аның көче һәм түземлелеге җитәр иде.

Шуңа да игътибарны юнәлтергә кирәк, Тукай шигыре тасвирлауны, эпик башлангычны көчәйтүче бәетләр белән язылган.

Шулай итеп, М.Ю. Лермонтов һәм Г. Тукай шигырләрен бер-берсенә тәңгәл куеп анализлаганнан соң, нәтиҗә ясарга була: бу шигырьләр күп яктан бер-берсеннән аерылалар. Бер үк темага язылсалар да, аларның кабатланмас үз стиле бар. Темага төрле яктан якын киләләр, аны үзләренчә ачалар. Беренчесе – шигырь-тәүбә, икенчесе – шигырь-мөрәҗәгать.

Михаил Лермонтов үзен замандашларыннан аермый, алган белеме, танышлыклары, тәҗрибәсе һәм сүз көче ярдәмендә үзе дә басымга бирешмәслеген аңлый.

Г. Тукай күп шигырьләр язган: үзенең туган җиренә һәм халкына мәхәббәте турында, сатирик, хакимиятне фаш иткән, пропагандалаучы, халыкка мөрәҗәгать итеп өметне өзмәскә, яхшы киләчәккә өметләнергә кирәклегенә чакыручы һ.б. Ул үз шигырьләренең көченә, үзен ишетүләренә, кешеләрнең күңелләренә кагыла алуына һәм фикерләренең аларга барып җитүенә ышанган.

Лермонтов үзенең замандашлары турында кызганып яза, шагыйрьнең лирик героен берни дә шатландырмый. Анда куәт тә, ярату хисе дә, батырлык та, дәрт тә юк. Тукай да үз буыны турында канәгатьсезлек хисе белән яза. Ул аларда хәйләлеккә һәвәслек, ышаныч юклыгын һәм элекке талантларны оныту кебек тискәре сыйфатларны күрә.

Димәк, төрле чорларда яшәгән рус һәм татар шагыйрьләрен гомум бер тема, бер проблема берләштерә: безнең илебезнең бүгенгесе һәм киләчәге, туган халкының, үз буынының язмышы. Рус һәм татар шагыйрьләре бу өлкәдә күп яктан бер-берләренә охшашлар – иҗат планнары буенча да, тормыш юллары буенча да.

**Әдәбият**

*Аминева В.Р.* М.Ю. Лермонтов и Г. Тукай: к вопросу о структурно-содержательных особенностях межлитературных текстовых образований // Филология и культура. 2012. № 2 (28). С. 7–10.

*Гордлевский В.А.* Тукай и русская литература. М.: Восточная литература, 1961. 230 с.

*Лермонтов М.Ю.* Полное собрание сочинений. Т. 1. М.-Л.: Государственное издательство художественной литературы, 1947. 383 с.

*Пехтелев И.* Пушкин. Лермонтов. Тукай. Казань. 189 с.

*Тукай Г.* Избранное. М.: Художественная литература, 1956. 201 с.

*Халит Г.* Габдулла Тукай и татарское литературное движение начала XX века. Казань: Таткнигоиздат, 1956. 232 с.

***Мотыйгуллин Җәлил Нургали улы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы*
*Фән һәм мәгариф министрлыгының фәнни-техник сәясәт бүлеге киңәшчесе*

***Мотыйгуллина Мәликә Җәлил кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты каршындагы*
*Ш. Мәрҗани исем. 2 нче татар гимназиясенең 10 А сыйныфы укучысы*

УДК 398.4

*Л.Х. Дәүләтшина*

# ТАТАР МИФОЛОГИЯСЕН ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

В статье рассматривается история изучения мифологических представлений татар. Автор прослеживает историю становления взглядов на мифологическую систему татар начиная с работ русских этнографов и путешественников XVIII в., продолжая трудами отечественных ученых XX века, написавшими первые труды по татарской мифологии и заканчивая филологическими исследованиями последних лет.

**Ключевые слова:** фольклористика, мифология, история, традиционная культура, текст, персонаж, верования.

Мифология халык иҗатының иң борынгы катламын тәшкил итә. «Миф (сүзнең туры мәгънәсендә) – ул хикәяләү, чынбарлыкны фантастик рәвештә гәүдәләндергән “хикәяләрнең” җыелмасы, әмма бу сүз сәнгате жанры түгел, ә бәлки дөньяны билгеле бер күзаллау. Еш кына ул күзаллау хикәяләү формасын ала; дөньяны мифологик рәвештә күзаллау башка төрле формаларда да булырга мөмкин – хәрәкәт, җыр, бию һ.б.» [Мифы народов мира, с. 211].

Күп гасырлар элек кешенең әйләнә-тирә дөнья, тереклек турындагы фантастик күзаллаулары нигезендә күпсанлы хикәятләр, ышанулар, йола-ритуаллар туган. Кеше әле бу вакытта үзен табигать дөньясыннан аерып карамаган һәм әйләнә-тирәсендәге барлык җанлы һәм җансыз әйберләрне «җанландырган». Ыруглык җәмгыятендә барлыкка килгән социаль мөнәсәбәтләрне кеше табигатькә күчергән, шул рәвешле мифологик карашлар нигезендә табигать һәм кешелек дөньясы арасында гармония барлыкка килгән [Мелетинский].

Фәнни әдәбиятта кабул ителгән классификацияләү принципларына нигезләнеп, татар халкының мифологик мирасын югары мифологиягә һәм түбән мифологиягә бүлеп карау кабул ителгән [Бакиров, 2012; Урманче, 2005]. Төрки-татар мифологиясендә тәңречелек тәгълиматы белән бәйле югары аллалар (Тәңре, Җир-Су, Умай, Алас һ.б.) һәм «культуралы герой»лар хакында телдән һәм язмача рәвештә тапшырыла торган реаль миф текстлары сакланмаган. Бүгенге көндә татар халкының мифологик системасын реконструкцияләү өчен борынгы мифологик ышануларны чагылдырган чыганак ролен «түбән мифология», ягъни Алла статусына ия булмаган ияләр, кара көчләр, рухлар һәм йола гадәтләре, ышанулар, кешенең көндәлек яшәеше белән бәйле мифологик мәгълүмат үти.

Бүгенге көндә бер халыкның мифологиясе мифологик

персонажлар турындагы күзаллауларны гына түгел, ә бәлки алар белән бәйле функцияләрне (куркыту, адаштыру, яклау, басу, зәхмәт җибәрү һ.б.), мифологик образларга бәйсез мотивларны (абага чәчәген эзләү, хәзинә эзләү һ.б.), мифологик лексиканы үз эченә алган катлаулы система буларак билгеләнә [Виноградова, Толстая, с. 16–44]. Өйрәнү объектын тәгаенләштерү материалның чикләрен дә киңәйтеп җибәрә. Мифологик персонажларга бәйле традицион рәвештә өйрәнелә торган жанрлардан (мифологик хикәят, легенда) тыш, эзләнүләр барышында ырым текстларын, йола гадәтләрен (йорт иясен яңа йортка күчерү, йорт иясенә ризык кую, җен алыштырган баланы кайтару, йорттан җен куу һ.б.), көндәлек тормыш белән бәйле гадәтләрне (су аркылы чыкканда җеп ташлау; мунчада әйбер калдырып чыгу, җен төкермәсен өчен ризык өсләренә ябу һ.б.), ышану, тыю, юрау кебек жанрларны исәпкә алу да бик мөһим.

* * *

Татар халкының мифологик күзаллауларын чагылдырган хезмәтләр бик борынгы вакытларда ук языла башлый. Әбрар Кәримуллин күрсәтүенчә [Кәримуллин, б. 5.], XI гасырда ук Мәхмүт Кашгариның «Диване лөгатет төрк» сүзлегендә татарларның борынгы бабалары – болгарларның риваять-легендалары урын алган. Татар мифологиясе үрнәкләре борынгы татар әдәбиятында, аерым алганда Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел фәрадис», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәиф Сараиның «Гөлестан бит төрки» һ.б. әсәрләрдә дә очрый.

«...татар халык иҗаты әсәрләрен язып алу, кәгазьгә теркәп калдыру тарихын X гасырның беренче яртысыннан, Ибне Фадлан китабыннан ук башларга кирәк», – дип яза Ф. Урманче [Урманче, б. 15]. Ибн Фадланның сәяхәте турындагы язма чыганакларда Идел буенда алыплар турындагы легендаларның киң таралуы, ислам диненең бу якларга үтеп керүе белән бәйле фикерләр чагылыш таба. Бу өлкәдәге беренче тәҗрибәләр Әбү Хәмид әл-Гарнати хезмәте (X–XI вв.), «Кодекс Куманикус» (XIV в.), «Казан тарихы» (XVI йөз) кебек язма ядкәрләр белән бәйле [Бакиров, 1993, б. 6].

Бер генә халык та җир йөзендәге башка халыклардан изоляциядә яшәми. Татар халкы да гасырлар дәвамында рус халкы белән төрле тарихи сәбәпләргә бәйле рәвештә бик тыгыз элемтәдә яшәгән. Борынгы заманнардан ук ике халык арасында сәүдә эшләре, мәдәни һәм фәнни багланышлар булуы билгеле. Татар фольклористикасының фәнни нигезләре барлыкка килүе дә рус фольклористикасы фәне белән тыгыз бәйләнгән. «Россиядә татар фольклоры әсәрләрен язып ала башлау XVIII гасырга туры килә. 1725 елда Петербургта Фәннәр Академиясе оештырылып, аның тарафыннан империядә яшәүче халыкларның тарихын, этнографиясен өйрәнү максатында экспедицияләр үткәрелә башлагач, фольклор

әсәрләре Рәсәйдә басыла торган хезмәтләргә дә үтеп керә. Г.Ф. Миллер, П.С. Паллас, И.И. Лепехин, Н. Рычков, М.Д. Чулков хезмәтләрендә, башка халыкларныкы белән беррәттән, татарларның да җырбиюләре, уеннары, халык бәйрәмнәре, легендалары турындагы мәгълүматлар урын таба», –дип яза Ә.Г. Кәримуллин [Кәримуллин, б. 6].

Татар халык иҗатына мөрәҗәгать итү, аны күпмедер дәрәҗәдә өйрәнүнең беренче адымнары рус этнографиясе фәне кысаларында ясала. Россия империясендә экспедицияләр, географик һәм этнографик эзләнүләр башлана. Империядә яшәгән барлык халыклар да, аларның яшәү рәвеше, йола-гадәтләре, иҗатлары этнографларның төп өйрәнү объектына әйләнә, һәм татар халкының бай һәм үзенчәлекле мифологик карашлар системасы да бу процесстан читтә калмый.

XVIII гасырда татар фольклорына караган мәгълүматларны туплаган хезмәтләрнең берсе – 1786 елда чыккан М.Д. Чулковның «Абевега русских суеверий, идолопоклоннических жертвоприношений, свадебных простнародных обрядов, колдовства, шаманства и проч.» хезмәте. Бу очракта М.Д. Чулков тарафыннан кулланылган «русских» сүзе гомумән Россия империясендә яшәгән барлык халыкларны үз эченә ала булса кирәк. Бу фикерне М.К. Азадовский да искәртә: «Абевега действительно представляет собой опыт сводки известного о “суеверных” представлениях и обрядов *различных* народов, обитавших в России» [Азадовский, с. 54]. Бу хезмәттә татарларга кагылышлы түбәндәге мәгълүмат бирелә: туй һәм туйда үткәрелгән йола-гадәтләр (димләү, яучылау, калым түләү һ.б.), татарлар яшәгән җирләр турында легенда һәм риваятьләр, зиратлар (аерым алганда Биләр шәһәре янындагы зиратлар) һәм корбан чалу үзенчәлекләре, мәчетләр турында мәгълүмат, кеше үлгәндә башкарыла торган йола-гадәтләр.

Татар мифологиясе өчен кызыклы мәгълүмат саклаган «Бесовское городище» турындагы легендада М.Д. Чулков Казан янында урнашкан гыйбадәтханә турында мәгълүмат бирә. «Бесовское городище, городок стоявший на берегу Камы, бывший Болгарского еще владения, недалеко от построенного после города Казани. В оном городке был храм некоторого идола, который идол, как уверяют, многие чудеса производил и давал ответы, также исцелял и от болезней; ежели кто проходил мимо его капища, не принеся ему ничего в жертву, то оных умерщвлял, и люди идущие по рекам опрокидывал и потоплял; оный идол или бес перед взятием Казани исчез из капища своего в виде дыма, пререк прежде о пленении Казанцев» [Чулков, б. 67].

Әлеге легенда үзенең эчтәлеге белән бүгенге көндә татар фольклористларына мәгълүм булган Алабуга турындагы «Шайтан каласы» («Чертово городище») легендасы белән аваздаш. М. Бакиров Алабуга турындагы риваять һәм легендаларның иң борынгыларында сүз Кама

елгасы буендагы «кала»да канатлы зур елан-сазаган яшәгәнлеге һәм аның җирле халык тарафыннан изгеләштерелгән һәм саклаучы-яклаучы мифик зат итеп күз алдына китерелгәнлеге хакында яза [Бакиров, 2004, б. 93–108.]. Автор шулай ук XIX йөз галимнәре П. Рычков, Н. Рычков һәм Ф. Эрдман хезмәтләрендә бу легенданың вариантлары чагылыш тапканлыгын искәртә.

XVIII гасырда татар фольклорына караган икенче хезмәт – Г.Ф. Миллерның «Описание живущих в Казанской губернии языческих народов» [Миллер, с. 60–80.] Бу хезмәттә мәгълүмат тасвирый характерда бирелгән, шулай да текст ахырында китерелгән сүзлектә мифологик эчтәлекле терминнар һәм аларның рус теленә тәрҗемәсе китерелә (Бог – Тере Гудай, Дьявол – Шайтан, Гора – Ата, Бугор – Им-ата һ.б.).

XIX гасырда этнографик эзләнүләр уңаеннан фольклористик эзләнүләр дә башлана. 1816 елда Иван Добровольский тарафыннан чыгарылган «Азиатский журнал»да һәм 1830 еллардагы И. Снегирев хезмәтләрендә татар фольклоры үрнәкләре инде махсус туплана башлый. Шулай ук 1804 елны Казан университетының ачылуы, аның каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте оештырылуы Идел буе һәм Көнчыгыш халыкларының телен, әдәбиятын, тарихын, мәдәниятен өйрәнүнең шактый алга китүенә этәргеч бирә. Университет галимнәреннән К. Фукс, И. Березин, В.В. Радлов, Н.Ф. Катанов һ.б. татар халык иҗаты әсәрләрен җыюга һәм өйрәнүгә зур өлеш кертәләр. Бу урында В.В. Радловның себер татарларының фольклор әсәрләрен үз эченә алган күләмле махсус хезмәтен искәртеп үтәргә кирәк. «Образцы народной литературы тюркских племен» дип аталган ун томлык хезмәтнең дүртенче томы 41 әкият, 29 җыр һәм бәет, 23 риваять һәм шәҗәрә, 16 дастанны һәм аларның өзекләрен үз эченә ала [Сибирские татары, с. 39]. Бу хезмәт татар мифологиясен өйрәнү өчен мөһим чыганак булып тора, чөнки халык хәтереннән югала башлаган яисә бөтенләй төшеп калган мифологик персонажлар (Алып, Йилбәгән, Каракош һ.б.) турындагы күзаллауларны саклый.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар халкының, бигрәк тә керәшеннәрнең йолаларын һәм йола поэзиясен, имләү-дәвалау традициясен, мифологик ышануларын өйрәнү җанланып китә. «Оренбургский листок» газетасы битләрендә бер-бер артлы М.В. Лоссиевский һәм В.Н. Витевскийның Албасты, Бичура, Убыр, Шайтан, Кирәмәт кебек мифологик персонажларга багышланган мәкаләләре дөнья күрә [Витевский, 1878; Лоссиевский, 1878]. И.М. Софийскийның керәшен татарларында язып алынган имләү текстлары [Софийский, 1878], Н.Ф. Катановның Бәләбәй өязендә яшәүче керәшен татарларында таралыш тапкан төрле авыруларга бәйле ышанулар һәм аларны дәвалау ысуллары (күз, баш, теш авыртуы, бизгәк, эт имчәге һ.б.) җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә

[Катанов, с. 1–14]. Венгр галиме Г. Балинтның 1875 елда басылган хезмәтендә керәшен татарлары яшәешендә өй иясе, сарай (ат) иясе, урман иясе, шүрәле, албасты һәм убыр турындагы ышануларның тасвирламасы бирелә [Balint, 1875]. Г.Н. Потанинның 1884 елда басылган мәкаләсе Алабуга өязендә яшәгән удмурт, татар һәм мари халыкларының традицион мәдәниятенә багышлана. Биредә йорт-җир, кием-салым турындагы этнографик мәгълүмат белән бергә мифологик ышанулар һәм әкиятләр дә игътибар үзәгенә куела [Потанин, с. 189–255].

XIX гасырның икенче яртысында татар фольклоры үз галимнәребез тарафыннан да өйрәнелә башлый. Татар халкының бөек галиме, мәгърифәтче, энциклопедист Каюм Насыйри татар фольклористика тарихында тирән эз калдырган галимнәрнең берсе. Татар фольклористикасының аерым фән буларак оешуы XIX гасырның икенче яртысы һәм Каюм Насыйри исеме белән бәйләнгән... Ул, татар гуманитар фәннәрендә беренчеләрдән булып, халык иҗаты әсәрләренә, аерым жанрларга, казан татарлары мифологиясенә багышланган күләмле хезмәтләр яза... [Урманче, б. 22]. Әлеге хезмәтләрдә [Насыйри К. Поверья и обряды казанских татар...] татар фольклористикасында беренче тапкыр мифологик персонажларны төркемләү (су астында торучы әкәмәтләр, җир өстендә яшәүче әкәмәтләр) омтылышы ясала, елан һәм аның белән бәйле Ак елан, Аждаһа, Юха елан кебек персонажларның генезисы, функцияләре билгеләнә, татар халкының ышанулар системасында «ия»ле авыруларның үзенчәлекләре тасвирлана.

Күрәсең, әлеге хезмәтләр нигезендә XX гасыр башында Я.Д. Коблов казан татарлары мифологиясенә багышланган бер мәкаләсен һәм аерым китабын рус телендә бастырып чыгара. Эчтәлеге белән бу хезмәт Каюм Насыйринең «Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства» мәкаләсенә якын. Я.Д. Кобловның классификациясе дә шуңа охшаш, әмма ул җир өстендә яшәүче персонажларның урыннарын тәгаенләштереп, өйдә яшәүче затлар, кырда, урманда яшәүче затлар кебек төркемнәрне аера. Әлеге хезмәттә татар мифологиясенең ислам мәдәнияте һәм тәңречелек тәгълиматы синкретизмына нигезләнгән булуы хакындагы фикер бүгенге фән күзлегеннән караганда да актуальлеген югалтмый.

1913 елда Я.Д. Коблов хезмәтенең мифологик персонажлар турындагы өлеше, татарчага тәрҗемә ителеп, «Аң» журналында «Татар хорафаты» исемле мәкаләдә басылып чыга. Мәкаләнең ахырында «Былтыр» дигән имза куелган. Бу исем белән күренекле татар фольклорчылары Х. Бәдигый һәм Г. Рәхим файдаланганнар. Кереш сүзендә автор болай дип яза: «Бер халыкның хорафаты ул халыкның телдән-телгә, бабадан-бабага күчеп килә торган тарихи сәмәрәйе хәяте булганлыктан, түбәндә

укылачак татар хорафатын, үзебезнең тарихи байлыгыбыз дип карап, К. Насыйри әсәрләренә моктәбадә итеп тотып, соңыннан бик күп картларга вә хикәя нәвисләргә мөрәҗәгать итеп җыеп чыгарган Кобловның әсәреннән иң искеләрен кулыңнан килгән кадәр татарчалаштырып, әбиләр вә бабалардан ишеткәнемчә әйләндереп, төзәтеп тәкъдим итүне тарихи бер әсәребезне мәйданда сакланып калуына хезмәт дип таптым» [Аң, 1913. № 13, б. 230, Татар халык иҗаты. Риваятьләр... б. 359–360].

XX гасырның 20 нче елларында «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте» оешканнан соң, җәмгыять әгъзалары тарафыннан җыелган мәгълүматлар «Вестник Научного общества татароведения» дигән журналда басыла башлый. Журнал битләрендә күренекле татар археографы С. Вахиди җыйган риваятьләр һәм легендалар дөнья күрә. С. Гыйләҗетдинов искәртүенчә, аның тарафыннан җыелган риваятьләрнең бер өлеше генә журнал битләрендә басыла, калганнары исә хәзер Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Мирасханәсендә саклана [Гыйләҗетдинов, б. 8].

Югарыда телгә алынган җәмгыятькә бәйле рәвештә Н. Воробьев һәм аның энесе К. Воробьев эшчәнлегенә дә күз салырга кирәк. Н. Воробьев исеме һәм аның татар этнографиясе өлкәсендәге хезмәтләре һәр галимгә таныш булса да, энесе хакындагы мәгълүматның фәнни әдәбиятта күренгәне булмады. Н. Воробьев җитәкчелегендә Җәмгыять тарафыннан Татарстан районнарына оештырылган этнографик экспедицияләрнең берничәсендә Константин Воробьев та катнаша. 1929 елда аның казан татарлары һәм мишәрләрдә өй иясе, абзар иясе һәм йорт иясе турындагы ышануларны җыю буенча махсус программасы басылып чыга. [Воробьев, с. 93–103.] Н. Воробьевның укучысы, күренекле этнограф, Р.Г. Мөхәмәдова сүзләре буенча, Константин Ленинград дәүләт университетының географик факультетында белем ала һәм, абыйсы белән берничә экспедициягә чыкканнан соң, фән даирәсеннән югала. Кызганыч, аның тарафыннан җыелган материаллар табылмады, программасы исә безнең тарафтан фәнни җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде [Давлетшина, «Программа...», 2015]. Әлеге хезмәт бүген дә фәнни әһәмиятен югалтмый. Аның нигезендә халык мифологиясенә комплексłы якын килү, мифологик персонажларны алар турында сакланган сюжетлы истәлекләр рәвешендә генә түгел, ә бәлки исемнәре, кыяфәте, күренү урыны, вакыты һәм функцияләре ягыннан тикшерү алгы планга чыгарыла. Бу төр эзләнүләр рус фольклористикасында XX гасырның 80 нче елларында гына Н.И. Толстой җитәкләгән этнолингвистика мәктәбе кысаларында башланып китә.

М.А. Васильевның егерменче еллар башында дөнья күргән китабы – легендаларны өйрәнү өчен мөһим чыганак [Васильев]. Автор хезмәтендә татар халык авыз иҗатын җыю, туплау һәм өйрәнү эшенең фольклористика

фәне кысаларында алып барылырга тиешлеген ассызыклый. Текстларның фәнни паспортын (әсәрнең кайдан һәм кемнән язып алынуы) бирү һәм аларның халыкара параллельләрен күрсәтү җыентыкның фәнни әһәмиятен тагын да арттыра.

1939 елда Казанда Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырылгач, татарлар яшәгән төрле төбәкләргә күпсанлы фольклор, диалектологик һәм археографик экспедицияләргә чыгу эше җанланып китә. Экспедицияләр нәтиҗәсендә алып кайтылган тел материаллары белән бергә татар халкының ышануларын да чагылдырган мәгълүмат фольклор җыентыкларында һәм диалектологик материалларда даими басылып бара [Материалы по татарской диалектологии, 1955–1990, Татар халык әкиятләре, 1950]. Совет чорында киң эрудицияле фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт татар мифларыннан ифрат та зур һәм бай хәзинә туплый. Аларның байтагын ул татар халык иҗатының афористик жанрларына багышланган саллы томнарына һәм башка хезмәтләренә кертә [Исәнбәт, 1956].

XX гасырның җитмешенче елларыннан татар халык иҗатының прозаик жанрларын, йолаларын һәм йола шигърияте, шул исәптән ырымнарны өйрәнү киң колач ала. Башкорт дәүләт университеты доценты Р. Мөхәммәтҗанов һәм Казан дәүләт университеты профессоры М.Х. Бакиров җитәкчелегендә үткәрелгән фольклор экспедицияләре вакытында татар халкы яшәгән төрле төбәкләрдә тупланган материал нигезендә тирән фәнни фикерле һәм саллы хезмәтләр дөнья күрә [Мөхәммәтҗанов].

Күпьеллык экспедицияләр нәтиҗәсендә тупланган бай материал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләренә дә татар халык иҗатының күптомлы җыелмасын әзерләү мөмкинлеген тудыра. 1976–1993 елларда халык иҗаты бүлеге татар фольклорының иң матур үрнәкләреннән тупланган 12 томлык җыелма бастырып чыгара. «Татар халык иҗаты» сериясенең риваятьләр белән легендаларга багышланган томында мифологик хикәятләргә махсус бүлек бирелә, кереш мәкаләдә мифологик хикәятләр жанры турында да җитди фикерләр әйтелә [Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар, 1987]. Әмма биредә нигездә Я.Д. Коблов һәм К. Насыйри хезмәтләрендә урын алган хикәятләр һәм алар белән бәйле сюжетлы хикәяләр тасвир ителә, ә татар мифологиясенең башка өлкәләренә һәм жанрларына караган информация чагылыш тапмый.

XX гасыр ахырында исә төрки-татар мифологиясен бүгенге фән югарылыгында өйрәнү буенча мөһим адымнар ясала башлый. Биредә Ф.И. Урманчеев, М.Х. Бакиров, Г. Дәүләтшинның җитди хезмәтләренә игътибар юнәлтү зарури. Бу елларда татар гуманитар фәннәре тарихында беренче тәҗрибә буларак күзалланган тирән һәм киң эчтәлекле энциклопедик сүзлек басылып чыга [Урманчеев, 2007, 2009,

2011]. Төрки-татар рухи мәдәниятен, шул исәптән төрки-татар мифологиясен өйрәнүгә алынган галимнәр әлеге мөһим һәм, һичшиксез, ышанычлы китапларны берничек тә читләтеп үтә алмый. Бу уңайдан соңгы елларда татар халкының дини-мифологик карашларына бәйле махсус күзәтүләр ясаган хезмәтләр һәм мәкаләләрне дә атарга кирәк [Кариева, 2000].

Халык мәдәниятен өйрәнә торган галимнең кабинет кысалары, китапханә фондлары белән чикләнмичә, халыкның яшәешен өйрәнүе, традицияләрнең үсеш-үзгәрешенә игътибар бирүе бүгенге көн таләпләренең берсе. Озак еллар дәвамында формалашкан традицияләрне истә тотып, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты кыр эзләнүләрен дәвам итә. Соңгы елларда институтта Татарстан районнарына һәм татарлар яшәгән – Рәсәй Федерациясенең Курган, Төмән, Оренбург өлкәләренә, Башкортстан, Марий Эл Республикалары, Пермь краена комплекслы фәнни экспедицияләр оештырыла. Экспедицион эзләнүләр барышында җыелган материаллар ел да «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күреп бара [Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш...].

XXI гасырга кергәч, халкыбызның традицион мәдәнияте күренешләрен барлау һәм җыйнау өлкәсендә күләмле эзләнүләр алып барган Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге дә (элекке Татар дәүләт фольклор үзәге) халкыбыз тарихына, аның рухи мәдәниятенә, көнкүрешенә караган бай материалга ия булган мирасханә туплау эшен дәвам итә. Фондны тулыландыру чыганагы булып, беренче чиратта, Үзәк тарафыннан Татарстан Республикасына һәм татарлар яшәгән төрле регионнарга (Рәсәй Федерациясенең Самара, Свердловск, Чиләбе, Әстерхан, Түбән Новгород, Саратов өлкәләре һәм Башкортостан, Марий Эл республикалары) оештырылган комплекслы экспедицияләр тора. Шулай ук фольклор җыючы галимнәр һәм халык мәдәниятен сөючеләрнең шәхси архивыннан алынган материаллар, М.Х. Бакиров һәм Ф.Й. Йосыпов җитәкчелегендә КДУ студентлары тарафыннан тупланган халык авыз иҗаты үрнәкләре дә фондны баетуда мөһим роль уйный. Үзәк фондына тупланган материаллар нигезендә махсус эзләнүләр алып барыла, кыйммәтле ядкәрләр фәнни әйләнешкә кертелә тора [Юсупов, 2004].

Соңгы елларда диалектология, этнография, археографиянең аерым юнәлешләре буенча татар халкының рухи хәзинәсенә һәм аның фәнни кыйммәтенә кагылышлы хезмәтләр һәм текстлар бер-бер артлы басыла тора. Бу урында Ф.Й. Йосыпов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, М. Әхмәтҗанов китапларын күрсәтеп үтәргә мөмкин. [Юсупов, 2006]. Татар халкының төрле этнографик төркемнәре тарихын, тел үзенчәлекләрен һәм халык авыз иҗатын өйрәнгән диалектологлар рухи мәдәниятнең аерылгысыз бер өлеше булган мифологик ышанулар системасын да читтә калдырмыйлар. Традицион

мәдәниятнең бу юнәлешендә тупланган материаллар татар филологиясе өчен генә түгел, бөтен тюркология өчен кыйммәтле хәзинә булып тора.

Күргәнебезчә, татар мифологиясенең өйрәнелү тарихы мифологик күзаллауларны туплау һәм бастыра башлау чорына барып тоташа. Югарыда анализланган хезмәтләрдән күренгәнчә, татар мифологиясен өйрәнү яңа материаллар туплау, аларны дөньяга чыгару һәм фәнни яктан өйрәнү юнәлешендә бара. XVIII–XX йөз башы чыганакларын, XX гасыр дәвамында дөнья күргән фольклор җыентыкларын, татар теленең төрле диалектларына мөнәсәбәтле тел, халык иҗаты материалларыннан торган китапларны, фәнни монографияләрне, мәкаләләрне һәм төрле архивларга тупланган материалларны күз алдыннан кичерсәк, бүгенге көндә татар мифологиясенә кагылышлы шактый мәгълүмат тупланган булуы күренә. Бу өлкәдә эшләнгән эшләр, фәнни тикшеренүләр байтак булса да, татар халкының мифологик күзаллауларын һәм фикерләвен чагылдырган, татар халык иҗатының төрле жанрларына (мифологик хикәят, легенда, ырым, ышану, тыю, юрау һ.б.) караган текстларны фәнни нигездә бер китапка туплап чыгарган хезмәтләр әлегә юк. XX гасыр ахырында башланган фәнни тикшеренүләр алга таба дәвам иттерелеп, татарларның мифологик карашлар системасын күз алдына китергән яңа хезмәтләр басылыр дип ышанабыз.

**Әдәбият**

*Balint G.* Kazani-tatar nyelvtanulmanyok. I. Fuzet. Kazani-tatar szove gek. Budapest, 1875.

*Азадовский М.* К. История русской фольклористики. М., 1958. 54 с.

*Ахметзянов М.* Тексты татарских языческих заклинаний // Формирование татарского литературного языка. Казань, 1989.

*Әхмәтҗанов М.* Татар халкының борынгы ырым-арбаулары һәм төрле фалнамәләре. Казан, 2012.

*Бакиров М.* Болгарга тоташкан тамырлар // Мирас, 2004. № 3. Б. 93–108.

*Бакиров М.Х.* Древнетюркская поэзия: неразгаданные тайны устного и письменного поэтического творчества наших предков. Казань, 2015.

*Бакиров М.Х.* Котлы булсын туегыз. Казан, 2007.

*Бакиров М.Х.* Ступени развития тюрко-татарского стиха. Казань, 1973.

*Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан, 2008.

*Бакиров М.Х.* Татарский фольклор. Казань, 2012.

*Бакиров М.Х.* Фольклор жанры буларак ырымнар // Фольклор жанрларын анализлау. Казан, 1986.

*Бакиров М.Х.* Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары. Казан, 2001.

*Баязитова Ф.С.* Әлмәт төбәге татарлары. Рухи мирас: көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор текстлары. Казан, 2001.

*Баязитова Ф.С.* Әстерхан татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Казан, 2002.

*Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан, 1997.

*Баязитова Ф.С.* Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. Казан, 1995.

*Баязитова Ф.С.* Татар-мишәр рухи мирасы. Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Саранск, 2003.

*Баязитова Ф.С.* Урта Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор. Казан, 2002.

*Баязитова Ф.С.* Себер татарлары. Рухи мирас: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Казан, 2001.

*Брусько З.М., Завгарова Ф.Х.* В круге жизни (фольклор семейно-бытовой обрядности татар). Казан, 2012.

*Васильев М.А.* Памятники татарской народной словесности. Сказки и легенды. Казань, 1924. 178 с.

*Виноградова Л.Н., Толстая С.М.* К проблеме идентификации и сравнения персонажей славянской мифологии // Славянский и балканский фольклор. Верования. Текст. Ритуал. М., 1994. С. 16–44.

*Витевский В.Н.* Нагайбаки, их песни, сказки и загадки // Оренбургский листок. 1878. 9 апреля. № 15.

*Воробьев К.* Программа для собирания сведений о духах-хозяевах у казанских татар и мишарей // Труды Студенческого научного кружка «Любители природы» в г. Казани. 1929. Вып. 3. С. 93–103.

*Гыйләҗетдинов С.М.* Риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр турында // Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан, 1987. Б. 8.

*Давлетшин Г.М.* Волжская Булгария: духовная культура. Домонгольский период. X – нач. XIII в. Казань, 1990.

*Давлетшина Л.Х.* «Программа для собирания сведений о духах-хозяевах у казанских татар и мишарей» К.Н. Воробьева // Татарская фольклористика. Исследования молодых. Вып. 6. Казань, 2015.

*Давлетшина Л.Х.* Вредоносные персонажи в представлениях елабужских татар-кряшен // Фольклор в системе национальных и общечеловеческих ценностей. Материалы Международной научно-практической конференции. Казань, 2014.

*Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе. Казань, 2006.

*Давлетшина Л.Х.* О перевоплощениях духов-хозяев домашнего пространства (на материале татар Заказанья начала XXI века) // Вестник Башкирского университета. 2015. № 3.

*Дәүләтшин Г.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан, 1999.

*Завгарова Ф.Х.* Комплексный подход к сбору легенд, связанных со святынями и сакральными территориями // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. Фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы. 8 китап. Казан, 2013.

*Завгарова Ф.Х.* Мифологизированный персонаж өрәк в традиционной культуре татар Заказанья // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. Казан, 2012. 7 китап.

*Закирова И.Г.* Эпический фольклор периода Золотой Орды: мифологические и исторические основы. Казань, 2011.

*Исәнбәт Н.* Ни өчен ни булган яки утыз ялган. Казан, 1956.

*Кариева Л.А.* Татарская мифология в сравнительно-историческом аспекте: автореф... канд. филол. наук. Казань, 2000.

*Касимов Р.Н.* Традиционные религиозно-мифологические представления чепецких татар. Конец XIX – сер. XX века. Ижевск, 2004.

*Катанов Н.Ф.* Народные способы лечения у башкир и крещеных татар Белебеевского уезда Уфимской губернии // Известия общества археологии, истории и этнографии. 1900. Т.16. Вып. 1. С. 1–14.

*Кәримуллин Ә.Г.* Татар фольклоры. Аннотацияләнгән әдәбият күрсәткече. Казан, 1993. Б. 6.

*Лоссиевский М.В.* Из суеверий и легенд мусульман Оренбургского края // Оренбургский листок. 1878. 9 июля. № 28.

Материалы по татарской диалектологии. Казань. Вып. I–VII, 1955–1990.

*Мелетинский Е.М.* Поэтика мифа. М., 1976.

*Миллер Г.Ф.* Описание живущих в Казанской губернии языческих народов. СПб., 1791. Б. 60–80.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казань, 2015.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Актаныш. Казан, 2010.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. Казан, 2011.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Мари Эл татарлары. Бәрәңге. Казан, 2012.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород. Казан – Мәскәү, 2011.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Удмуртия татарлары. Казан, 2013.

Мифы народов мира. Энциклопедия. М., 1980. Т. 1. С. 14.

*Мөхәммәтҗанов Р.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Уфа, 1977, 1980, 1982. 1984.

*Насыйри К.* Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Записки Императорского русского географического общества. 1880.

*Насыйри К.* Образцы народной литературы казанских татар // Известия Общества археологии, истории и этнографии. Т. XIII. Вып. 2.

*Насыйри К., Поляков П.А.* Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов // Известия Общества археологии, истории и этнографии. Т. XVI. Вып. 2. и др.

*Потанин Г.Н.* У вотяков Елабужского уезда // ИОАИЭ. Т. 3. 1884. С. 189–255.

*Рамазанова Д.Б.* К истории формирования говора пермских татар. Казань, 1996.

Саба җәүһәрләре. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр / төз. Р. Имамиева; ред. Р.Х. Гатауллин. Казань, 2014.

Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры. Антология фольклора сибирских татар: дастаны, мунаджаты, баиты / авт.-сост. Ф.Ю. Юсупов. Казань, 2014.

*Софийский И.М.* Заговоры и заклинания крещеных татар Казанского края // Изв. по Казанской епархии. 1878. № 2.

Татар халык әкиятләре. Казан, 1950.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / төз. С.М. Гыйләҗетдинов. Казан, 1987.

Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. Китап 1–8, Казан, 2006–2013.

Татар халык мәкальләре. Казан. Т. 1. 1959; Т. 2. 1963; Т. 3. 1967.

Татар халык табышмаклары. Казан, 1970.

Татарская фольклористика. Исследования молодых. Вып. 1–6. Казан, 2009–2014.

Төш юрау китабы / текстларны туплаучы Марсель Әхмәтҗанов. Казан, 1991.

*Урманче Ф.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2005.

*Урманчеев Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. Казан, 2007, 2009, 2011.

*Урманчеев Ф.И.* По следам Белого волка: ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племен. Казань, 1994.

*Урманчеев Ф.И.* Эпоха, достойная сказаний. Древний фольклор и современная поэзия. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990.

Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе / М.Х. Бакиров, А. Яхин. Казань, 1979.

*Чулков М.Д.* Абевега русских суеверий, идолопоклоннических жертвоприношений, свадебных простнародных обрядов, колдовства, шаманства и проч. М., 1786. Б. 67.

*Юсупов Ф.Ю.* Красноуфимские татары: история, язык, фольклор. Казань, 2004. (на тат. яз.).

*Юсупов Ф.Ю.* Сафакүл татарлары. Тарих, тел, халык иҗаты. Казан, 2006.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 94(47)

*Р.И. Беккин*

# БЕР ДУСЛЫК ТАРИХЫ: Г. БАЯЗИТОВ ҺӘМ В.С. СОЛОВЬЕВ

В настоящей статье мы рассмотрели характер связей петербургского ахуна А. Баязитова в среде петербургских литераторов и ученых. Одной из фигур, с которой некоторые авторы вслед за поэтом и публицистом В.Л. Величко связывают имя Баязитова, был философ В.С. Соловьев. Мы попытались выяснить характер отношений между мусульманским богословом и христианским мыслителем.

**Ключевые слова:** А. Баязитов, мусульмане Петербурга, В.Л. Величко, В.С. Соловьев.

Петербург ахуны Гатаулла Баязитов (1846–1911) – XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы күренекле мөселман дин әһелләренең берсе. Мөселманнар арасында ул төрлечә кабул ителә, шәхесенә дә, эшчәнлегенә дә карашлар төрле була[1]. Шуңа да биографиясенә карата кызыксыну бүген дә сүрелми [Гафурова, 2010; Шангараев, 2010; Шангараев, 2012; Шангараев, 2014; Гафаров, Набиев, 2014; Баязитов, 2007; Баязитов, 2015].

Баязитов исеме бөтенроссия масштабында билгеле булган ике вакыйга белән тыгыз бәйләнгән: Петербургта җәмигъ мәчете салу һәм Россиядә беренче татар газетасы – «Нур» – чыга башлау. Рус телендә дөнья күргән хезмәтләре «Возражение на речь Э. Ренана» [Баязитов, 1883], «Отношение ислама к науке и иноверцам» [Баязитов, 1887] һ.б. аша ул тагын да киңрәк танылу ала.

Ахун Г. Баязитов эшчәнлеге мөселманнарның гына түгел, ә Россия империясенең башка халыклары вәкилләренең дә игътибарын җәлеп итә[2]. Шулай да фәнни әдәбиятта бу мәсьәлә як-

---

[1] «Фанатично настроенные современники покойного Баязитова не понимали его и считали “обрусевшим”» [*С.*, б. 3)]. «В мире мусульманства» газетасы төгәл чыганак түгел, шулай да Баязитов адресына моңа охшаш гаепләр ахунның башка замандашларында да очрый (мәсәлән, Петербург мөселманнарының Чит илләр диннәре буенча Рухи эшләр департаменты директоры А.Н. Мосолов исеменә язган хатында мондый юллар бар: «Почтительнейше просим сделать зависящее с Вашей стороны распоряжение о ревизии и отобрании книг и документов по сбору пожертвований на постройку мечети от сборщика ахуна 2-го гражданского прихода Атауллы Баязитова, который не пользуется между нами доверием и популярностью…» [цит. Тагирджанова, с. 70]); шулай ук: Письмо-донесение третьего секретаря...].

[1] С.А. Венгеров «Критико-биографический словарь русских писателей и ученых» хезмәтендә әйткәнчә: «Баязитов принадлежит к числу тех весьма редких представителей мусульманства, которые хотели бы примирить принципы новейшей цивилизации с духом Корана. Желание показать русской публике, что мусульманство вовсе не есть оплот мрака и невежества было главным стимулом, побудившим Баязитова выступить на русское литературное поприще» [Критико-биографический словарь...].

тыртылмый диярлек. Баязитов шәхесе мөселман дөньясы контекстында гына карала[1]. Ахунның мөселманнар арасында гына түгел, ә мөселман булмаганнар белән аралашуын өйрәнү Баязитовның үз биографиясен һәм XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы Россия җәмгыятенең кайбер группаларының ислам диненә, мөселманнарга булган карашын да ачарга ярдәм итә.

Философ һәм шагыйрь Владимир Сергеевич Соловьев ислам белән кызыксынган шәхес. Аның 1896 елда дөнья күргән «Магомет, его жизнь и религиозное учение» хезмәте бүгенге көн белгечләре тарафыннан да югары бәяләнә [Коростелев, 2015, с. 5]. Кайбер галимнәр фикеренчә, Соловьев бу хезмәтне әзерләгәндә Баязитовтан шактый ярдәм ала: «Биографический очерк Соловьёва «Магомет, его жизнь и религиозное учение» во многом был написан при участии и под влиянием Баязитова, уже имевшего опыт описания жизни пророка (1881)» [Гафаров, Набиев, 2014, с. 85–93][2]. Башка авторлар, дәлилләр китермичә генә, Соловьев Баязитов йортында еш кунак була, дип белдерәләр[3]. Баязитов турында барлыкка килгән кайбер мифларга җирлек булып ахунның вафатыннан соң «В мире мусульманства» газетасында С. имзасы белән басылган мәкалә тора. Соловьев һәм Баязитов мөнәсәбәтләре турында бу мәкалә болай ди: «Владимир Соловьев был одним из близких друзей Ахунда Баязитова. В сочинении Вл. Соловьева «Магомет и его жизнь» (изд. Павленкова) очень много сведений написано под влиянием А. Баязитова» [С., 1911, с. 3]. Кайбер бүгенге авторлар бу мәкаләдән тикшерелмәгән, башка бернәрсә белән дә дәлилләнмәгән мәгълүмат китерәләр, хәтта анда булган хаталарны да яңадан бастыралар.

---

[1] Мәсәлән, Г. Баязитовның фәнни һәм мәгърифәт эшчәнлеген өйрәнгән Р.Р. Шаңгәрәев болай дип яза: «[Баязитов] известен как крупнейший религиозный и государственный деятель, начавший служить одновременно и на религиозном, и на государственном поприще, заслуживший всероссийскую славу талантливого публициста, плодотворного журналиста, активного педагога-просветителя, мыслителя, дальновидного организатора общественной активности мусульман» [Шангараев, 2015. с. 156]. Ләкин алга таба мәкаләдә ул Баязитовның «Возражение на речь Эрнеста Ренана “Ислам и наука”» китабында булган берничә фикерен карау белән чикләнә.

[2] Башкача әйтсәк, бу мәкалә авторлары фикеренчә, Г. Баязитовның 1881 елда Мөхәммәт пәйгамбәргә багышланган татар телендә брошюрасы булу, Соловьев үзенең «Мөхәммәт»е өстендә эшләгәндә Баязитовтан киңәш алган, дигән тезис файдасына сөйли.

[3] Мәсәлән, Ф.Г. Газизуллин күрсәткәнчә: «[Баязитов] был принят в высших правительственных кругах, пользовался большим авторитетом в научном сообществе. Достаточно сказать, что ложа № 11 в Мариинском театре, предоставленная семье Баязитова, находилась рядом с ложей Николая II. В его доме бывали министры, ученые (Витте С.Юл., Гаспринский Исмаил-бей, Соловьев В.С. – религиозный философ и др.) [Газизуллин, с. 77].

Мәсәлән: «Лесников[1] был близким другом покойного» [С., 1911, с. 3][2].

Петербург имамы һәм рус философы арасындагы бәйләнешләр турында без бик аз беләбез. Төп чыгынак булып хатлар хезмәт итә: Баязитов хатлары [Письмо Баязитова В.С. Соловьеву] һәм адресаты я авторы Соловьев булган хатлар [Письмо В.С. Соловьева к В.П. Величко]. Тагын бер мөһим чыганак – В.С. Соловьевның В.Л. Величко тарафыннан язылган биографиясе [Величко, 1902].

Бу чыганаклар һәм башка басылган я әле дөнья күрмәгән материалларга таянып, без дини фикер ияләре В.С. Соловьев һәм Г. Баязитовның бәйләнеш тарихын торгызырга тырышып карарбыз.

**Гатаулла Баязитов: кыскача биографиясе**

Баязитовның Петербург җәмгыятендә тоткан урынын аңлар өчен аның биографиясенең төп сәхифәләрен искә төшерү урынлы булыр. Гатаулла Баязитов 1846 елда Рязань губернасы Касыйм өязе Төмәнсу авылында дөньяга килә. 14–15 яшьләрендә Четаево авылы мәдрәсәсенә укырга керә. Мөгаллиме шәкертләргә мавыктыргыч итеп гарәп, грек фәлсәфәсен, аеруча Аристотель логикасын укыткан Шиһабетдин Алтынбаев була [Баязитов. Автобиография (1889), л. 1]. Баязитов мәдрәсәдә 8 ел укый [шунда ук, л. 1об.]. Бу вакыт эчендә ул гарәп диалектикасын, грек-гарәп фәлсәфәсен, физика, гарәп шигъриятен, астрономия, борынгы тарих, башка гамәли фәннәрне дә өйрәнә [шунда ук, л. 1–1об.].

Рус теленә килгәндә, аны Гатаулла үз теләге белән аерым мөгаллим яллап өйрәнә [шунда ук, л. 1об.]. 1871 елда, әле Баязитов мәдрәсәдә шәкерт чагында һәм бер үк вакытта кечерәк шәкертләргә дәресләр биргәндә, ул Петербургта яшәүче якташлары, касыйм татарлары тарафыннан шәһәрдә барлыкка килгән икенче мөселман мәхәлләсенә җитәкче итеп чакырыла.

Яңа мәхәллә барлыкка килүгә төп этәргеч булып 1869 елда Санкт-Петербург шәһәре ахуны итеп Мөхәммәтшакир Юнысов билгеләнү тора. Ул Бохара яклы булып, Урта Азиядән Себергә килеп төпләнгән, аннан Россиянең Европа өлешендә көченгән сәүдәгәрләр мәнфәгатен кайгырта, шулай ук Түбән Новгород татарларын яклый. Шәһәр мөселманнарының шактый зур өлеше булган Касыйм татарлары моның белән килешмиләр, билгеле. Касыйм татарлары җирле оешмасы вәкиле – «Касыйм татарларының Бикбулатов хәйрия җәмгыяте» башлыгы Хәбибулла Бикбулатов – чиновникларга хат-

---

[1] Язучы Н.С. Лесков күз уңында тотыла. Бу турыда тәфсилләп алдарак карагыз.

[2] Чагыштыру өчен: «Его (Баязитова. – *Р.Б.*) близкими друзьями стали философ В. Соловьев, писатель Лесников (! – *Р.Б.*), востоковед В. Бартольд. Атаулла был вхож в высшие круги имперской администрации, был знаком, например, с председателем Совета министров П.А. Столыпиным» [Баязитов, 2007, с. 6].

лар яудыра башлый, Петербург мөселманнарына икенче имам кирәклеген дәлилли [Беккин, Тагирджанова, с. 144].

Касыймлылар үз дини башлыкларын акча белән тәэмин итүне үз өсләренә алалар. Бу урынга кандидат итеп Бикбулатов тарафыннан Гатаулла Баязитов исеме әйтелә. Баязитов Уфадан кирәкле документаларны алгач, касыймлылар аерым мәхәллә булдыру таләбе белән чыгалар. Бу фикерне хуплап күмәк гариза языла, анда 400 дән артык кеше имза куя. 1870 елның ноябрь аенда, берникадәр икеләнүләрдән соң, Эчке эшләр министрлыгы яңа мәхәллә булдыруга рөхсәт бирә [шунда ук, б. 145].

Икенче мөселман мәхәлләсе шәһәрнең нәкъ уртасында – Мойка буенда 22 нче йортта, Кышкы сарайдан ун минутлык юлда урнашкан була. Мәхәллә халкы арасында касыйм татарлары күпчелек була. Алар Невский проспектында һәм якын-тирә урамнарда урнашкан рестораннарда официант булып хезмәт итәләр.

1880 елда Баязитовка ахун дәрәҗәсе бирелә. Шул ук елда ул Чит ил эшләре министрлыгына тәрҗемәче (драгоман) булып чакырыла. 1888 елда, Азия департаментының уку-укыту эшләре бүлеге җитәкчесе М.А. Гамазов (1812–1893) тәкъдиме белән коллеж регистраторы чинында төрки телләр укытучысы итеп билгеләнә [Баязитов. Автобиография (1889), л. 1об.]. Димәк, Баязитов икенче мөселман мәхәлләсе имамы функцияләренә өстәп, штат службасы да алып бара.

Бу ике билгеләнү арасында 1883 елда Баязитовның рус укучылары арасында кызыксыну тудырган «Возражение на речь Э. Ренана “Ислам и наука”» хезмәте басылып чыга. Күпләр мөселман кешесенең француз философына җавап биргәненә гаҗәпләнәләр. Китапка дәрәҗәле басмаларда берничә рецензия да дөнья күрә[1].

Баязитов Э. Ренанны тәнкыйть иткән беренче мөселман түгел, билгеле. 1883 елда, Ренанның «Ислам и наука» лекциясе басылып чыгу белән үк, Җамаледдин әл-Әфганинең (1839–1897), француз философын тәнкыйть итеп[2], башта гарәп телендә [Jamāl al-Dīn al-Hussaynī al-Afghānī, 1883. 3 may], соңрак французча [Jamāl al-Dīn al-Afghānī, 1883. 18 May] җавап-хаты басыла. Баязитов бу басма белән таныш булырга бик мөмкин[3]. Шул ук 1883 елда билгесез авторның «Восточное обозрение»дә «Мусульманство и рационализм» [Мусульманин...] мәкаләсе басыла. Ләкин рус укучыларында нәкъ менә Баязитов китабы кызыксыну уята.

---

[1] Мәсәлән, карагыз: Новости. 1884. № 7. С. 1–2. Рецензияләр: *N.* Новое исследование об исламе; Новое время. 1887. № 3961. С. 3; *Sylva S.* Ислам и наука; һ.б. Г. Баязитов хезмәтләренең тәфсилле тәнкыйте православ миссонеры М.А. Миропиев тарафыннан языла: [Миропиев, с. 20–41].

[1] Әл-Афганинең Э. Ренанга җавабы турында тулырак карагыз: [Keddie, p. 181–187].

[2] Баязитов үзе Ренан лекциясе белән А. Ведров тәрҗемәсендә рус телендә таныша булса кирәк: [Ренан].

Баязитовның мөселман булмаганнар арасында да билгеле булуына В.Л. Величко – М.Г. Муретова әдәби түгәрәге вәкилләре белән танышлыгы да булыша[1].

### Г. Баязитовның Петербургта фәнни һәм әдәби бәйләнешләре

1880 еллар ахыры – 1890 еллар башында Петербург һәм Мәскәүдә әдәби салоннар һәм түгәрәкләр эшчәнлегенең яңарышы күзәтелә [Сапожков, 2001]. Шундый түгәрәкләрнең берсе Мария Георгиевна Муретова (1912 елда вафат) фатирында җыела. Муретова француз аристократы Г. де ла Барт кызы һәм двор киңәшчесе Д.В. Муретов хатыны була. Иренең вафатыннан соң, 1887 елда, Петербургка күченә. Биредә туганы шагыйрь һәм журналист В.Л. Величко (1860–1903) белән якынаеп китә, аның хатыны, дусты, киңәшчесе була[2].

Василий Львович Величко тормышында ике чор аерып күрсәтергә мөмкин. Чик булып 1896 ел тора. Бу елда Величко озак еллар буена шагыйрь булып танылу алырга омтылган җиреннән, Петербургтан, Тифлиска күченеп китә, анда тиздән «Кафказ» газетасының баш редакторы була. Моңа кадәр әдәби даирәләрдә Величко өметле генә күренгән шагыйрь, фарсы, төрки һәм грузин шагыйрьләре тәрҗемәчесе булып таныла[3]. Петебургтан киткәч аны, лирик шигърияттән битәр, сәяси сюжетлар кызыксындыра башлый.

1890 еллар ахыры – 1900 еллар башында Величконың иҗтимагый һәм публицистик эшчәнлеге кайбер галимнәргә аны черносотен хәрәкәтенә нигез салучыларның берсе итеп карау өчен нигез бирә [Степанов, 2010, с. 14]. Величкода булган бу үзгәрешне калку итеп аның нашир А.С. Суворинга (1834–1912) язган хаты күрсәтеп тора. Кавказга киткәнче Василий Львович күбрәк үзенең әдәби әсәрләре турында кайгыртса, мәсәлән иң мөһим шигъри әсәре «Первая муха» [Письма В.Л. Величко..., л. 1–4об.] турында, Кавказдан язылган хатлары исә тирә-якта күзәтелгәннәрдән туган авыр хисләр белән тулы [шунда ук, л. 5–8об.]. Величко тәнкыйтенең үзәгендә «әрмән плутократиясе» тора.

В.Л. Величко Кавказ һәм Кавказ арты хәлләрен сурәтләгән мәкаләләрендә һәрвакыт ассызыклап килә: хакимияткә Кавказның мөселман халыкларына таянырга кирәк, ә ышанычсыз әрмәннәргә түгел: «Во многих городах восточного Закавказья мусульмане составляют подавляющее *большинство населения*, а

---

[1] Баязитовның рус мәдәнияте вәкилләре белән якын танышлыгы турында сөйләгән башка сүзләрдән аермалы буларак, ахунның Величко һәм Муретова белән аралашу факты безнең карамакта булган аз санлы чыганаклар белән раслана. Бу турыда тулырак итеп алдарак сөйләнер.

[2] М.Г. Муретованың В.Л. Величконың дусты гына түгел, ә чынлыкта хатыны булуы турында аз санлы якын танышлары гына белә. Мәсәлән, карагыз: [Лесков, с. 416].

[3] Мәсәлән, Гомәр Хәйам әсәрләре рус телендә беренче тапкыр В.Л. Величко тәрҗемәсендә басыла: [Из Омара Кайяма, с. 319–323].

между тем они не пользуются в городском самоуправлении одинаковыми правами с армянами, под предлогом, что эти последние «христиане». Таким предлогом можно морочить только людей, имеющих понятие о Кавказе лишь на основании календарных сведений» [Величко, 1990, с. 115]. Величко фикеренчә, үз мәнфәгатен генә кайгырткан әрмән плутократиясе Россиягә каршы эшли. Шул ук вакытта мөселманнар империянең ышанычлы кешеләре һәм аларны әрмәннәр кысрыклавыннан якларга кирәк [Величко, 2010, с. 78–79].

В.Л. Величко хакимлек итүнең прагматик ысулы яклы була. Дәүләтнең теге яки бу халыкка булган мөнәсәбәте турыдан-туры халыкның Россия хакимиятенә мөнәсәбәте белән билгеләнә, ә дин я кан принциплары буенча түгел: «Ограничения прав некоторых групп населения полезны и необходимы в пестроплеменном государстве, но должны вытекать из бытовых условий, а не основываться на формальных признаках. Ограничивать нужно эксплуататоров, стачников, политиканов, людей кагальнаго строя; таковыми же являются именно армяне, а не мусульмане. Христианство без христианской морали есть подделка, и недаром один православный иерарх, знающий Кавказскую жизнь, однажды высказал мне, что считает мусульман по духу и нравственной основе более близкими к православным, нежели монофизитов-армян» [Величко, 1990, с. 115][1].

Кавказда В.Л. Величко андагы мөселманнар, беренче чиратта Кавказ арты татарлары (азәрбайҗаннар), тормыш-көнкүреше белән якыннан таныша. «Кавказ» битләрендә ул берничә тапкыр әрмән провокацияләреннән мөселманнарны яклап чыгыш та ясый [Величко, 1990, с. 88]. Әйтергә кирәк, мөселман дине белән Величко Петербургта яшәгән вакытында ук кызыксына башлый, хәтта мөселман намазларында да булгалый.

Россия дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивында (РГАЛИ) 1891 елның февраль аенда чыккан «Новое время» газетасы кисәге саклана. Анда В.Л. Величконың Оренбург Диния нәзарәте мөфтие Мөхәммәдьяр Солтанов[2] һәм ахун Г. Баязитов катнашкан тантаналы намаз турында язмасы бар. Намаз мөфтинең Петербургка килүе хөрмәтенә үткәрелә [Величко, 1891, л. 1–2]. Величко биргән мәгълүматта Солтанов һәм гомумән мөселманнар турында бик җылы әйтелә. Шулай да безнең өчен, бу мәгълүматтан битәр (Величконың исламга булган мөнәсәбәтен без инде ачыкладык), газета

---

[1] Кайбер мәкаләләрендә Величко Евразия галимнәреннән алда ук мөселманнарны рус халкына комплиментар (Л.Н. Гумилев терминында) итеп белдерә: «Не надо забывать, что, как выше сказано, разумно направленное культурное развитие мусульман неминуемо приведет их к теснейшему сближению с русскими, с которыми они состоят в кровном и в идейном родстве, как показывает вся наша история» [Величко, 1990, с. 177].

[2] Солтанов Мөхәммәдьяр (1837–1915) – мөселман дин әһеле, Оренбург диния нәзарате мөфтие (1886–1915).

кисәге кырыйларына язылган Н.С. Лесков комментарийлары кызыклы. Искә төшерик, бер ара Н.С. Лесков М.Г. Муретова салонына йөри, алар Величко белән карашлары бөтенләй туры килми башлаганга кадәр аралашып яшиләр [Де-ла-Фарт, с. 9, 17]. Н.С. Лесковтан гайре Муретова – Величко салонына шулай ук төрле елларда философ һәм шагыйрь В.С. Соловьев, язучылар Д.Л. Мордовцев һәм А.К. Шеллер, рәссамнар И.Е. Репин һәм Н.Н. Каразин, профессорлар А.Н. Веселовский һәм А.М. Ладыженский, композитор Г.А. Лишин һ.б. [шунда ук, с. 9] булалар. Муретова фатирында ахун Г. Баязитов та булгалый[1]. Бәлки, нәкъ менә бирەдә ул Н.С. Лесков белән танышкандыр да.

Түбәндәрәк Величко язмасыннан өзекләр китерәбез. Лесков астына сызып билгеләп куйган сүз һәм сүзтезмәләрне аерып күрсәттек. «Приехавший на днях в Петербург оренбургский муфтий Мухаммед-Яр-Султанов присутствовал 1-го февраля на торжественном богослужении (джума-намаз) в мусульманской молельне 2-го столичного прихода. Настоятель этой молельни, *ахун* А. Баязитов, встретил мусульманского иерарха кратким приветствием от имени своей паствы. Муфтий отвечал речью, в которой увещевал своих единоверцев стремиться к добродетели и быть искренними слугами религии и Царя, так как в жизни нравственные стороны обеих служб совпадают… Муфтий худощав, высок и строен… Он без малейшего акцента говорит по-русски и во время почти всего завтрака разговор шел исключительно на этом языке, в разговоре муфтий проявил всестороннее образование… здешние магометане давно мечтают о сооружении мечети… Отчего бы, в самом деле, и не выстроить им здесь своего храма, коль скоро евреи возвели свою «мавританскую» синагогу, при виде которой возликовал бы сам Моисей Маймонид!! Конечно, евреи богаче потомков Чингис-хана, но за этими подданными нельзя не признать многих нравственных преимуществ, вызывающих сочувствие к их благочестивому желанию» [Величко, 1891, л. 1–2]. Текст кырыйларында уңда астына сызылган текстка каршы якта сорау билгеләре һәм бер өндәү билгесе куелган.

Лесковның газета тексты астына язылган кыска язмасы аеруча кызыклы: «М.И.П. узнав про это, сказал, что это пишет пьяный Чехов» [шунда ук, л. 2][2]. М.И.П. – Н.С. Лесковның якын дусты Михаил Иванович Пыляев (1842–1899) булса кирәк. Ул Лесковка әсәрләре өчен төрле кызыклы һәм көлке фактлар тупларга булыша. Лесковның Россия дини

---

[1] Моңа, турыдан ук булмаса да, В.С. Соловьев хаты дәлил: Карагыз: [Письмо В.С. Соловьева В.Л. Величко (1894), с. 210].

[2] РГАЛИда эш тасвирында ялгышлык белән комментарий авторы язучының улы А.Н. Лесков итеп күрсәтелә. Әдәбият белгече В.Н. Сажинның безгә җиткергән фикеренчә, текст кырыйларындагы язу, һичшиксез, язучы Н.С. Лесковныкы.

тормышын дикъкать белән күзәтеп баруы билгеле, шул исәптән рус булмаган халыкларныкын да. Шулай да Н.С. Лесковның бу иронияле комментарийлары турында сүз алып барганда, аларның ахун Баязитовка түгел, ә күбрәк аның яклаучысы, язма авторы В.Л. Величкога каршы икәнлеген истә тотарга кирәк.

Баязитовның Муретова – Величко түгәрәге белән бәйләнешләре турында Петербург мөселманнарына да яхшы билгеле була. Бу бәйләнешләр, Г. Баязитов исеме астында рус телендә дөнья күргән «Возражение на речь Э. Ренана» [Баязитов, 1883], «Отношение ислама к науке и иноверцам» [Баязитов, 1887] һ.б. китапларының авторы ахун түгел, дигән сүзләр таралуга сәбәп була. Бу гаеп Гази Булат улы Вәли-ханның (1844–1909) Исмәгыйль Гаспралыга язган хатыда да чагыла. Вәли-хан язганча: «Я удивляюсь смелости таких безграмотных людей, как Баязитов, решающихся издавать газету под громким именем «Блеск ислама»[1], ради только того, чтобы эксплуатировать невежественный мусульманский народ… Наверное, он думал воспользоваться услугами господина Величко… и компании, которые написали ему брошюры «Возражение на речь Ренана», «Ислам и наука» и статью в Петербургских ведомостях против Смирнова[2], составленную общими силами; под всеми этими статьями красовалась только одна фамилия: «Мудар[3]… Баязитов…» [цит.: Зайцев, с. 130].

Югарыда китерелгән өзектә ачык күренә: Петербург мөселманнары арасында 1880–1890 елларда Баязитов исеме астында басылып чыккан хезмәтләрнең авторы бер ул гына түгел, дигән сүз йөри. Бу сүз дөрес булмаган очракта да, Вәли-хан хаты башкала мөселманнарының Баязитовка булган мөнәсәбәтен ачып бирә.

Мөселман замандашларының ахун Баязитовка булган шактый шикле мөнәсәбәтенә Санкт-Петербург шәһәрендә төрек илчелегенең өченче сәркатибе Абдур-Резак язган рәсми документ да дәлил була ала: «…хотя и нет оснований сомневаться в благочестии имама Атауллаха эфенди, [все же] он получил образование в русской школе, русские выдают ему законное жалование, а также дали ему чин, соответствующий [османскому] чину гражданского служащего первого ранга. Здешние мусульмане знают, что Атауллах эфенди со своей шляпой и служебным мундиром ушел к русским, и ***многие*** (безнең

[1] Биредә сүз беренче номеры 1905 елда чыккан «Нур» газетасының башлангыч, эшче исеме турында бара булса кирәк.

[2] И.В. Зайцевның дөрес фикеренчә, Вәли-хан 1891 елда «Санкт-Петербургские ведомости»да, № 96, басылып чыккан мәкалә турында сөйли. Ләкин бу мәкалә «В защиту татарской литературы от цензуры» дип түгел, ә «Обманчивые призраки» дип исемләнгән [Баязитов, 1891, с. 2–3].

[3] Биредә Баязитов китапларының титул битенә урнаштырылган «мөдәррис» сүзе күз алдында тотыла: [Сочинение] С.-Петерб. мухамед. ахун имам-джамиа хатым мударрисса Атаулы Баязитова.

тарафтан аерып күрсәтелде. – *Р.Б.*) не любят его [за это]» [Письмо-донесение..., 2008].

Баязитовның урыслар ягына хезмәткә китүе итеп төрек дипломаты ахунның Чит ил эшләре министрлыгындагы хезмәтен атый. Югарыда күрсәтелгәнчә, ахун бу министрлыкка 1880 елда эшкә керә. Баязитовның төп җитәкчесе – шәрык белгече Матвей Авелевич Гамазов – Чит ил эшләре министрлыгының Азия департаменты уку-укыту бүлеге мөдире була. Безнең карамакта булган чыганаклырдан күренгәнчә, баштарак Гамазов Баязитовка зур өметләр баглый. Мәсәлән, генерал-лейтенант Гобәйдулла Чыңгызханның (1840–1909) Гамазовка 1888 елда язган хатында мондый сүзләр бар: «Относительно избранника Вашего – учителя, он же вновь испеченный чин я надеюсь Вы не ошиблись в нем, он будет очень стараться заслужить Ваше спасибо» [Письмо Чингис-хана Тору..., л. 1]. Чыңгызхан, гомеренең күп өлешен Петербургта яшәгән мөселман кешесе буларак, Баязитовны белмәскә мөмкин түгел. Бәлки нәкъ менә ул Гамазовка Азия департаментына тәрҗемәче һәм мөгаллим буларак ахунны тәкъдим иткәндер дә. Генерал Чыңгызхан өметләре тулысынча ук акланмый. Бәлки Гамазовны Г. Баязитовның мөгаллим буларак эшчәнлеге канәгатьләндерәдер дә, ләкин аның фәнни өлкәдә ясаган адымнары бернинди дә яклау тапмый. А.Н. Пыпинга (1833–1904) шәрык белгече М.В. Готовицкийның «О происхождении названия Саратов» [Протоколы IV общего...] рефераты хакында язган хатында Гамазов болай ди: «Ахун не намерен уступать г. Готовицкому. Препровождаю к Вам новую записку сего вновь испеченного коллежского регистратора. Поступите с нею по вашему усмотрению. Если эта букворастирательная белиберда покажется Вам не годною к отправке по назначению, потрудитесь предать ее всесожжению. По просьбе моей, Баязитов, в сем последнем произведении, оставил меня, не желающего более принимать участие в подобного рода ломании копий, совершенно в стороне» [Письма М.А.Гамазова.., л. 11–11об.].

Хатка Баязитов язуы кушымта итеп бирелгән. Биредә гарәп һәм төрки сүзләрнең транслитерация үзенчәлекләре турында әйтелә; кайбер топонимнарның, Баязитов фикеренчә, антропонимнарга кайтып калуы хакында сөйләнә: мәсәлән, Касыйм шәһәре – Касыйм хан, Әстерхан – Аждар хан, Казан – Казан хан [шунда ук, л. 17об–18] исемнәренә. Гарәп һәм төрки сүзләрнең транслитерациясе мәсьәләсе ул вакытта әле академик шәрык белеме дәрәҗәсендә дә эшләнмәгән була. Топонимнарның килеп чыгышы мәсьәләсе исә тагын да катлаулырак: Касыйм шәһәре турында галимнәр арасында фикер төрлелеге күзәтелми, ә Казан исеменең Казан, я Газан[1], хан исеменнән

[1] Бу версияне Ш. Мәрҗани яклый: «нужно думать, что основал его (город) хан сарайский Казан-хан, сын Туган-хана, сына Батый-хана» [Марджани, с. 30].

килеп чыгуы күпчелек галимнәр тарафыннан кире кагыла[1]. Әстерхан атамасының Әждар хан исеменнән булуы да шик тудыра.

Күргәнебезчә, Баязитовның шәрык белгечләре (Гамазов һәм Готовицкий[2]) арасында дәрәҗәсе түбән була[3]. Баязитов үзе дә ориенталистларны бик үк өнәп бетерми, хәтта В.В. Радлов (1837–1918) һәм Ф.Е. Корш (1843–1915) хезмәтләре хакында да фикере югары булмый [Письмо А. Баязитова к В.К. Трутовскому, л. 1об.].

Философ Владимир Сергеевич Соловьев ислам белгече түгел, шулай да Мөхәммәд пәйгамбәрнең иң уңышлы биографияләренең берсе аның тарафыннан языла. Шуңа бәйле рәвештә сорау туа: Соловьев, Муретова – Величко түгәрәге әгъзасы буларак[4], Баязитов белән таныш булгач, «Магомет, его жизнь и религиозное учение» китабын язганда ахун Баязитовка ярдәм сорап мөрәҗәгать иттеме икән?

### В.С. Соловьев һәм А. Баязитов

В.Л. Величко белдергәнчә, Баязитов философ һәм шагыйрь В.С. Соловев белән дустанә мөнәсәбәттә тора: «Когда он (В.С. Соловьев. – *Р.Б.*) писал для биографической библиотеки Павленкова очерк жизни и учения Мухаммеда… он внимательно проверял каждое слово при помощи авторитетной критики академика барона В.Р. Розена и здешнего гражданского ахуна, почтенного муллы Баязитова, ***с которым затем был дружен до самой смерти*** (безнең тарафтан аерып күрсәтелде. – *Р.Б.*)» [Величко, 1902, с. 184].

Кайбер галимнәр тагын да алгарак китәләр: «Биографический очерк Соловьева «Магомет, его жизнь и религиозное учение» (1896) во многом был написан при участии и под влиянием Баязитова, уже имевшего опыт описания жизни пророка (1881)» [Гафаров, Набиев, 2014, с. 88]. Шул ук вакытта сүзләрен бернәрсә белән дә дәлилләмиләр. Чынлап та, 1881 елда Баязитовның татар телендә «Мөхәммәд Мостафа (салла-л-лаһу галәйһи вә сәлам) дөньяга килүе вә диннең башлануы» [Баязитов, 1881] китабы дөнья күрә. Ләкин бу китапның В.С. Соловьев хезмәте белән уртак ягы бик аз. Ул дини хезмәт һәм, Соловьевның биографик очеркыннан аермалы буларак, бөтенләй башка укучы өчен әзерләнгән[5].

---

[1] Бу турыда тулырак карагыз: [Кляшторный].

[2] Готовицкий Мәскәүнең Лазарев көнчыгыш телләр институтын бетерә. Гарәп телен һәм төркине искиткеч әйбәт белә.

[3] Биредә рус ориенталистларының башка милләт кешесенә карата тискәре фикердә булуы турында уйларга урын юк. Петербургта яшәгән һәм шәрык белгечләре арасында зур хөрмәт казанган Хөсәен Фәезханов (1823–1866) һәм шәех Мөхәммәд Аййада ат-Тантави (1810–1861) исемнәрен искә төшерү дә җитә.

[4] Муретованың туганы Ф. де ла Барт әйтүенчә, ул Соловьев белән түгәрәк утырышларының берсендә 1889 елда таныша [Де-ла-Барт, с. 9].

[5] Шул ук 1881 елда А.С. Суворин типографиясендә рус телендә А.А Дәүләт-Кильдеевның «Магомет как пророк» очеркы басыла: [Девлет-Кильдеев].

Соловьев «Магомет» очеркын 1892 елда эшли башлый[1]. Димәк, бу чор аның В.Л. Величко белән тыгыз аралашкан, Муретова йортында да еш булган вакыты [Де-ла Фарт, с. 8–9]. Шулай ук, Соловьев «Магомет» очеркын эшләгән вакытта, Баязитовның Величко белән контактлры өзелгән, дип тә әйтеп булмый. Димәк, объектив яктан караганда, В.С. Соловьев Баязитов белән очрашырга бик мөмкин.

Шулай да В.С. Соловьев яки аңа язылган хатлар Величко язган философ һәм ахун дуслыгы турында бернәрсә дә әйтмиләр. «Итак отложите «Магомета» до будущей недели, – дип яза Соловьев Величкога 1894 елда. – ***Я не знаю, какой человек ахун*** (безнең тарафтан аерып күрсәтелде. – *Р.Б.*), – если он дурно примет эту отсрочку, то, пожалуй, можно в виде компенсации предложить ему читать у нас» [Письмо В.С. Соловьева В.Л. Величко, с. 210]. В.Л. Величко сүзләренә караганда [Величко, 1902, с. 184], китабының һәр сүзен диярлек мулла Баязитовтан тикшерткән, аның авторитет фикере аша үткәргән автор өчен сәер күренеш.

Тагын бер сәер факт: китапның кереш өлешендә В.С. Соловьев барон В.Р. Розега рәхмәт сүзләрен җиткерә, ә Баязитовны хәтта искә дә алмый [Соловьев, 1992, с. 3]. Соловьев һәм Баязитов арасында дуслык җепләре 1894 елда, инде язылган «Магомет» китабын басмага әзерләгән чорда гына ныгып киткән, дип фараз итсәк тә, Соловьевның керештә баронны телгә алган вакытта Баязитов «ярдәме» турында искә алмавын ничек аңлатырга[2]? Владимир Сергеевич бик төгәл һәм итагатьле кеше буларак билгеле[3], мондый игътибарсызлык аның өчен булмастай эш.

Ниһаять, безнең карамакта Баязитовның В.С. Соловьевка язган хаты бар. Ул эчтәлгеге белән генә түгел, язылу стиле белән дә кызыклы. Шуңа да бу хатны, автор орфографиясен һәм пунктуациясен саклап, тулысынча китерергә булдык. Бу Баязитовның үз кулы белән рус телендә язылган азсанлы хатларының берсе. Башкаларга гадәттә аның имзасы гына куелган.

---

[1] 1892 елның 30 июнендә нашир Ф.Ф. Павленковка язган хатында Соловьев «Магомет» кулъязмасын иң соңгысы шул ук елның 20 сентябрендә китерергә вәгъдә итә [Письма В.С. Соловьева к Ф.Ф. Павленкову (1891–1892), л. 3]. Ләкин башка бер хатында Владимир Сергеевич 1893 елның 10 гыйнварына кадәр вакыт бирүен сорый [Письма В.С. Соловьева к Ф.Ф. Павленкову (1891–1892), л. 6]. Бу вакытка инде, Соловьев сүзләре белән әйтсәк, китап язылып беткән диярлек, аңа бары кулъязманы чарлап бетерү өчен 12–15 көн кирәк [шунда ук].

[2] Нашир Ф.Ф. Павленковка язган хатларында да Соловьев Баязитов турында искә төшерми. Мәсәлән, Мөхәммәднең исемен Магомет дип түгел, ә Мухаммед дип язу дөресрәк икәнне ул барон Розенга сылтып дәлилли, ә ахунга түгел.

[3] Бу турыда В.С. Соловьевны якын белгән кешеләр яза. Мәсәлән, сеңлесе М.С. Безобразова искә алуынча, «особенно страдал от малейшей измены верности и дружбе и сам исключительно глубоко и сильно чувствовал благодарность за всякую, и даже небольшую, услугу» [Безобразова, с. 147].

«Многоуважаемый
Владимир Сергеевич!

Хороший тон книги мог-бы произвести магометанам привосходный впечатление но помещенная в ней изображение Магомета в таком дурном виде и так неудачно рисованный к сожалению может омрачить прекрасное впечатление, даже мне думается такая неподходящая образ Магомета будет принета многими как-бы нарочно так дурно изображенном в такую ни подходящий вид. Не лучше-ли задержать выписку в свет и выпустить без изображении Магомета, спасти бочку меда от ложки дегтя все таки мудрость.

С искренним почтением
А. Баязитов.
1896 го года. 8го июля»
[Письмо А. Баязитова
В.С. Соловьеву].

Величко тексты турында Н.С. Лесковның югарыда китерелгән сүзләре биредә бик тә урынлы булыр иде!

Хатта дата күрсәтелгән: 1896 елның 8 июле. Бу вакытта инде Баязитовның «Возражение на речь Эрнеста Ренана «Ислам и наука»» һәм «Отношение ислама к науке и иноверцам» китаплары, башка фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләре басылып чыккан була [По поводу помещенного...,1882. с. 3; Вопрос о просвещении инородцев, 1885, с. 10–11; По поводу мусульманского фанатизма, 1886, с 1–2; Очерк развития..., 1890, с. 668–673 и др.]. Шулар арасында Соловьевның «Магомет» очеркына «Неделя» газетасында басылган рецензия дә бар [Баязитов, 1896, с. 1164–1168]. Баязитов бәяләмәсендә Соловьев брошюрасының уңай һәм тискәре яклары турында тәфсилләп сөйләнә. Тискәре яклар ягында Мөхәммәднең Лейпциг граверы Гедан тарафыннан эшләнгән портреты атала: «Прежде чем сказать что-либо о содержании самой книжки, мы не можем не выразить нашего сожаления по поводу помещения в ней вполне неудавшегося гравированного (с чего?) портрета Магомета; во-1-х, подлинного изображения его совсем не существует, а во-2-х, помещенное изображение совсем не подходит и не соответствует ни тем описаниям наружности пророка, ни тем сведениям о его нравственном укладе, которые сохранила для нас история, как единственные источники. Позволим себе заметить, что лучше-бы было уже поместить портрет Магомета, находящийся в журнале «Звезда», в № 4-м 1895 года, взятый из академии художеств. Последний, по нашему мнению, более соответствует характеру Магомета по имеющимся преданиям» [Баязитов, 1896, с. 1164].

Күргәнебезчә, бу фрагментның теле югарыда китерелгән хат теленнән бик нык аерыла! Хат авторының русча сөйләм телен үзләштергәне, ләкин язма теле юк икәне күренеп тора. Рус телендә фикерләрен шулай начар язган кеше китап әзерләгәндә чит кеше ярдәменнән башка эшли алдымы икән? Җавап ачык: Г. Баязитов текстларын рус телендә басмага әзерләгәндә тәҗрибәле редактордан башка эш алып бармаган. Шулай да Баязитовка

ярдәм иткән кешенең төгәл генә исемен атый алмаганга, бу турыда шул сүз белән чикләнәбез.

Шуны да әйтеп китик, Баязитов рецензиясендә, югарыда китерелгән хаттагы кебек үк, Соловьевның «Мухаммед» исеме урынына «Магомет» исемен куллануы хакында бер сүз дә әйтелми. Гәрчә мөселман дин әһеле беренче чиратта бу турыда әйтергә тиеш иде! Владимир Сергеевич үзе «Магомет» исеменә кискен каршы була, бу хакта аның Павленковка язган хатыннан да аңлашыла: «Но тут опять возникает вопрос с именем. Я уступаю Вам заглавный лист (и следовательно объявления), но стою за Мухаммеда в тексте (с объявлением в предисловии), – не только ради студентов барона Розена, но также и для множества русских мусульман, на которых как на читателей имею основание рассчитывать и которые привыкли писать и произносить не иначе как Мухаммед» [Письма В.С. Соловьева к Ф.Ф. Павленкову (1891–1892), л. 7об.–8].

Г. Баязитовның В.С. Соловьевка язган хаты философның Величкога адресланган һәм югарыда өзеге китерелгән хатына мөһим бер өстәмә булып тора [Письмо В.С. Соловьева к В.Л. Величко, с. 210].

Ике хатның да эчтәлекләрен анализлау түбәндләге нәтиҗәләргә килергә мөмкинлек бирә:

1) В.С. Соловьевның В.Л. Величкога язган хатыннан күренгәнчә, 1894 елга кадәр Владимир Сергеевич Баязитов белән таныш булмый диярлек («Магомет, его жизнь и вероучение» китабының караламасы инде 1894 елда әзер була);

2) Г. Баязитов «Магомет»-ны инде язылып беткәч кенә күрә, китап язылу вакытында фикер алышуда актив катнашмый. Шулай да, Соловьевның Величкога язган хатыннан күренгәнчә, Баязитов Муретова фатирында «Магомет» кулъязмасын укыган вакытта булып, башкалар белән беррәттән әңгәмәдә катнашырга мөмкин. Ләкин В.С. Соловьев китапны язган вакытта ахун консультант булмый. Моны Г. Баязитовның китап дөнья күргәч басылып чыккан рецензиясе дә дәлилләп тора [Баязитов, 1896, с. 1164–1168]. Баязитовның философ белән хезмәттәшлеге турында В.С. Соловьевның Павленковка булган хатларында да әйтелми;

3) Баязитов хатының характеры аның Соловьев белән дустанә мөнәсәбәтләрдә булуы турында сөйләми. Һәрхәлдә, 1894 елга кадәр (ә Соловьевның «Магомет»ка язган кереш сүзенә караганда, 1896 елга кадәр). Башка чыганаклар да (Соловьевка адресланган яки аның үз хатлары, мемуарлар һ.б.) В.С. Соловьевның Г. Баязитов белән 1896 елдан соң да элемтәсе булуын расламыйлар.

Бу мәкаләдә без башкала ахуны Гатаулла Баязитовның Петербург әдипләре һәм галимнәре белән бәйләнешләренең характерын тикшердек. Рус телендә «Возражение на речь Эрнеста Ренана “Ислам и наука”» һәм «Отношения ислама к науке и к иноверцам» китаплары басылып чыккач, Баязитов башкала мөселманнары арасында гына түгел,

читтә дә танылу ала. Мәкалә язылуга этәргеч – Петербург мөселманнарының күренекле вәкиле Г.Б. Вәли-ханның И. Гаспралыга язган хатында китерелгән гипотеза: генерал ачыктан-ачык Г. Баязитовны аның исеме астында дөнья күргән китапларының авторы түгел дип белдерә.

Бу гипотезаны дәлилләү яки кире кагу мәкаләнең төп бурычы түгел. «Возражение на речь Эрнеста Ренана “Ислам и наука”» һәм «Отношения ислама к науке и к иноверцам» хезмәтләренең авторы кем, дигән сорауга яңа архив материалларын җәлеп итеп, хезмәтләрнең үз текстларын анализлап кына җавап табарга була[1].

Безне беренче чиратта Г. Баязитовның Петербург җәмгыятендә тоткан урыны кызыксындырды. Ахунны якыннан белгән кешеләрнең аның фәнни эшчәнлегенә бирелгән бәяләмәләренә караганда, Г. Баязитов рус әдипләре һәм җәмәгать эшлеклеләре арасында үз кеше булмый, гәрчә язмыш күп кенә күренекле шәхесләр белән танышлык бүләк иткән булса да. Шәрык белгечләре арасына да кабул итмиләр аны.

Шагыйрь һәм публицист В.Л. Величкога ияреп Г. Баязитов исеменә бәйле Владимир Сергеевич Соловьев исемен дә атыйлар. Без бу мөселман дин белгече һәм христиан фикер иясе бәйләнешенең характерын ачыкларга тырышып карадык. В.С. Соловьев очрагы ачык күрсәтә, В.Л. Величконың Соловьев һәм Баязитовны якынайтуга куйган бар тырышлыгына карамастан, бу ике кеше арасында дуслык һәм хезмәттәшлек җепләре сузылмый, гәрчә мөмкинлек булса да: «Магомет, его жизнь и вероучение» китабын эшләгәндә В.С. Соловьев В.Л. Величко белән актив аралаша, Муретова фатирында да әдәби салонда еш була. Безнең карамакта булган документлар раслаганча, Величконың, В.С. Соловьев һәм Г. Баязитов гомерлек дуслар булалар, дип әйтүе – теләгәнне чынлык итеп күрсәтергә тырышу гына.

Г. Баязитов философ В.С. Соловьев һәм рус мәдәниятенең башка вәкилләре белән дустанә мөнәсәбәттә булган, дип язган бүгенге көн галимнәре, тикшереп карамыйча, башкалар тарафыннан уйлап чыгарылган мифны кабатлыйлар, я үзләре яңа миф тудыралар. Г. Баязитов шәхесенә Россия тарихы контекстында урын билгеләү өчен, алар бу күренекле дин әһеленә Петербург җәмгыятендә бервакытта да тотмаган авторитет һәм бәйләнешләр өстәп язалар.

---

[1] Кайбер рецензентлар «Ислам и прогресс» китабының текстында мөселман кешесе өчен (бигрәк тә мөселман рухание өчен) сәер булган үзенчәлекләргә игътибар итәләр. Мәсәлән, Миропиев болай дип яза: «При этом весьма интересно, почему г. Баязитов приводит стихи Корана по переводу Николаева с французского перевода Казимирского (М., 1876), а не с более точного перевода, сделанного прямо с арабского текста Г.С. Саблуковым. Это странно, но сделано не без цели, наверно. Это во 1-х. Во 2-х, на каком основании... г. Баязитов, говоря об уважении ислама к Иисусу, называет его «Иисусом Христом»? Ведь Коран не дает ему на это права. Не есть ли это желание подделаться под вкус русской православной публики, для которой написана брошюра?» [Миропиев, с. 36].

**Әдәбият**

[Jamāl al-Dīn al-Afghānī] Gemmal Eddine Afghan. Au Directeur du Journal des débats // Journal des débats. 1883. 18 May.

*Jamāl al-Dīn al-Hussaynī al-Afghānī.* 3 May 1883b. "al-Islām wa al-'ilm" // Al-Basīr. 1883. 3 may.

*Keddie N.R.* An Islamic Response to Imperialism: Political and Religious Writings of Sayyid Jamal al-Din "al-Afghani". Berkeley, 1983. P. 181–187.

*N*. Новое исследование об исламе // Московские ведомости. 1887. № 218.

*Sylva S.* Ислам и наука // Саратовский дневник. 1889. № 76, 80.

*А. Баязитов.* Автобиография (1889) // ИРЛИ. Ф. 377. Оп. 7. Д. 331.

*Баязитов А.* Возражение на речь Эрнеста Ренана «Ислам и наука». СПб., 1883.

*Баязитов А.* Избранные труды / сост. и авт. предисл. А.Ш. Гафурова. Казань, 2007.

*Баязитов А.* Мөхәммәд Мостафа (салла-л-лаһу галәйһи вә сәлам дөньяга килүе вә диннең башлануы). СПб., 1881.

*Баязитов А.* Обманчивые призраки. Ответ на статью «Среди татар» в газете «Новое время» // Санкт-Петербургские ведомости. 1891. № 96. С. 2–3.

*Баязитов А.* Отношение ислама к науке и к иноверцам. СПб., 1887.

*Баязитов А.* Что проповедует ислам? // Неделя. 1896. № 36. С. 1164–1168.

*Баязитов Г.* Отношение ислама к науке и к иноверцам. Изд. 2-е. М., 2015.

*Безобразова М.С.* Воспоминания о брате Владимире Соловьеве // Минувшие годы. 1908. Май–июнь.

*Беккин Р.И., Тагирджанова А.Н.* Мусульманский Петербург. СПб., 2016.

*Величко В.Л.* [О мусульманском торжественном богослужении]. Заметка. // Новое время. 1891. Февр. Пометы и комментарий Н. С. Лескова // РГАЛИ. Ф. 275. Оп. 1. Д. 785.

*Величко В.Л.* Владимир Соловьев: Жизнь и творения: с прил. рис. И.Е. Репина, портр. и факс. СПб., 1902.

*Величко В.Л.* Кавказ. Русское дело и междуплеменные вопросы. Баку, 1990.

*Величко В.Л.* Русские речи / сост. предисл. и коммент. А. Д. Степанова. М., 2010.

Вопрос о просвещении инородцев // Восточное обозрение. 1885. № 10. С. 10–11.

*Газизуллин Ф.Г.* Актуальность трудов Атауллы Баязитова для формирования толерантного сознания в современных условиях // Проблемы современной экономики. 2013. № 4 (48). С. 77–78.

*Гафаров А.А., Набиев Р.А.* Модернистский дискурс в трудах А. Баязитова (80–90-е годы 19 века) // Ученые записки Казанского университета. 2014. Т. 156, Кн. 3. С. 85–93.

*Гафурова А.Ш.* Татарская газета «Нур» в Санкт-Петербурге и ее основатель Атаулла Баязитов. СПб., 2003.

*Девлет-Кильдеев А.А.* Магомет как пророк: [Очерк]. СПб., 1881.

*Де-ла-Барт Ф.* Литературный кружок 90-х годов (из воспоминаний о Вл. Соловьеве, Н.С. Лескове и друг.) // Известия общества славянской культуры. 1912. Т. 2. Кн. 1. С. 8–21.

*Зайцев И.В.* Новые документы об Исмаиле Гаспринском // Гасырлар авазы. Эхо веков. 2014. № 3–4. С. 126–133

Из Омара Кайяма / пер. с персид. В. Величко // Вестник Европы. 1891. Кн. 5, Т. III. С. 319–323.

*Кляшторный С.* О времени основания Казани // Татарский мир. 2003. № 8. URL: www.tatworld.ru/article.shtml?article=81

*Коростелев С.* Михаил Пиотровский: «Именно в серии “ЖЗЛ” вышла одна из самых великих книг» // Вселенная ЖЗЛ. 2015. № 4 (17). Ноябрь. С. 5.

Критико-биографический словарь русских писателей и ученых. СПб., 1891. Т. II. Вып. 22–30: Бабаджано-Бензенгр.

*Лесков А.Н.* Жизнь Николая Лескова. М.: Художественная литература, 1984. Т. 2.

*Марджани Ш.* Очерк истории Булгарского и казанского царства. Казань, 1884. Т. 1.

*Миропиев М.А.* О положении русских инородцев. СПб., 1901.

Мусульманин. Мусульманство и рационализм // Восточное обозрение. 1883. № 24. 16 июня.

Новости. 1884. № 7. С. 1–2.

Новое время. 1887. № 3961. С. 3.

«Очерк развития религиозно-философской мысли в исламе» С. Уманца. СПб., 1890 // Исторический вестник. 1890. июнь. С. 668–673.

Письма В.Л. Величко А.С. Суворину // РГАЛИ. Ф. 459. Оп. 1. Д. 664.

Письма В.С. Соловьева к Ф.Ф. Павленкову (1891–1892) // РГАЛИ. Ф. 400. Оп. 1. Д. 40.

Письма М.А. Гамазова А.Н. Пыпину // ОР РНБ. Ф. 621. Д. 189.

Письмо А. Баязитова В.С. Соловьеву // ОР РНБ. Ф. 718. Д. 39.

Письмо А. Баязитова к В.К. Трутовскому // РГАЛИ. Ф. 890. Оп. 2. Д. 46.

Письмо В.С. Соловьева В.Л. Величко (1894) // Письма Владимира Сергеевича Соловьева / Под ред. Э.Л. Радлова. СПб., 1908. Т. 1. С. 210.

Письмо Чингис-хана Тору М.А. Гамазову // ОР РНБ. Ф. 172. Д. 121.

Письмо-донесение третьего секретаря Османского посольства в Санкт-Петербурге Абдуррезака адъютанту султана Дервиш паше о положении российских мусульман // Гасырлар авазы=Эхо веков. 2008. № 2. URL: www.archive.gov.tatarstan.ru/magazine/go/anonymous/main/?path=mg:/numbers/2008_2/02/04/).

По поводу мусульманского фанатизма // Санкт-Петербургские ведомости. 1886. № 123. С. 1–2.

[По поводу помещенного в одной из газет известия о скором обращении всех в ислам] // Голос. 1882. № 308. С. 3.

Протоколы IV общего собрания Саратовской ученой архивной комиссии / под ред. Н. Соколова. Саратов, 1887.

Протоколы VI общего собрания Саратовской ученой архивной комиссии / под ред. Н. Соколова. Саратов, 1888.

*Ренан Э.* Ислам и наука: Речь, произнес. Эрнестом Ренаном в собр. «Науч. фр. ассоц.» (основ. в 1861 г. Леверье), б. 29 марта в большом Сорбон. амфитеатре / пер. Алексея Ведрова. СПб., 1883.

*С.* Ахунд Баязитов // В мире мусульманства. 1911. № 4. С. 3.

*Сапожков С.К.* М. Фофанов и репинский кружок писателей // НЛО. 2001. № 48 // http://magazines.russ.ru/nlo/2001/48/sap.html

*Соловьев В.С.* Магомет, его жизнь и религиозное учение. СПб., 1992.

*Степанов А.Д.* Предисловие // Величко В.Л. Русские речи / сост. предисл. и коммент. А. Д. Степанова. М., 2010.

*Тагирджанова А.Н.* Мусульмане в жизни и культуре Петербурга (XVIII–XIX вв.). СПБ., 2013.

*Шангараев Р.* «Книга об исламе» (Ислам китабы) Атауллы Баязитова как показатель отхода от традиционного религиозного сознания татар в конце XIX века // Габдулла Апанаев (1862 – 1919) – известный татарский педагог и общественный деятель: материалы всероссийской научно-практической конференции (г. Казань, 29 марта 2012 г.). Казань, 2012. С. 135–141.

*Шангараев Р.* Атаулла Баязитов: просветитель и защитник ислама // История мусульманской мысли в Волго-Уральском регионе. Казань, 2010. С. 265–283.

*Шангараев Р.* Гатаулла Баязитов как представитель мусульманского модернизма в России (статья) // Казанская наука. Казань, 2014. № 12. С. 42–45.

*Шангараев Р.* Отношение ислама к женщине и семейному быту в трудах Гатауллы Баязитова // Татар педагогик фикере үсеше мәсьәләләре (Проблемы развития татарской педагогической мысли). Казан, 2011. С. 129–136.

*Шангараев Р.Р.* Единство традиции и обновления во взглядах петербургского ахунда Гатауллы Баязитова // Ислам в современном мире. 2015. Т. 11, № 4. С. 155–160.

***Беккин Ренат Ирек улы,***
*икътисад фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясе профессоры,*
*Сёдерторн Университеты (Стокгольм, Швеция) докторанты*

УДК 37.02

*Л.Р. Мортазина*

# МӨХӘММӘТХАН ФАЗЛУЛЛИННЫҢ (1883–1964) ФӘННИ-ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье рассматривается педагогическая деятельность профессора, доктора филологических наук М.А. Фазлуллина; проведен анализ некоторых педагогических и методических трудов ученого. При написании статьи использованы документы из фонда ученого, хранящиеся в Национальном музее РТ.

**Ключевые слова:** научно-педагогичекая деятельность, татарское просвещение, воспитание, учебники, методические пособия, история педагогики.

Хәзерге заман педагогикасы, дөньякүләм фәнни казанышларга ачык булган хәлдә, үткән мирасыбызның иң якты сәхифәләрен дә кире какмый. Киресенчә, халкыбызның күп гасырлар буена тупланып, байый барган рухи кыйммәтләрен, тәрбия һәм белем бирү өлкәсендәге тәҗрибәсен, татар мәгарифе үсешендә тирән эз калдырган педагогларыбызның еллар узган саен әһәмиятен югалтмаган мирасын тәрбия һәм белем бирүдә файдалану мөмкинлеге ачыла. Бу яктан караганда, XX гасырда, бигрәк тә аның беренче яртысында хезмәт иткән педагогларыбызның эшчәнлеге аеруча кызыклы. Татар мәгарифендә мәгърифәтчелек идеяләрен дәвам итеп, яңа мәктәп, яңача белем һәм тәрбия бирү системасын булдыру өстендә эшләгән, шактый бай педагогик мирас калдырган күренекле шәхесләребезнең берсе – профессор, филология фәннәре докторы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, РСФСР ПФА мөхбир әгъзасы Мөхәммәтхан Әшрәфҗан улы Фазлуллин.

Билгеле булганча, Мөхәммәтхан Фазлуллин 1883 елның 2 декабрендә Казан губернасы Чуел (Цивиль) өязе (Татарстанның хәзерге Яшел Үзән районы) Әрә авылында укымышлы, зыялы гаиләдә дөньяга килә. Аның әтисе Әшрәфҗан Фазлуллин икенче мәхәлләнең имам-хатыйбы була. Туган авылындагы мәдрәсәдә башлангыч белем алганнан соң, 1895 елда әтисе Мөхәммәтханны Казандагы Апанай («Күл буе») мәдрәсәсенә бирә. Бираедә укыган чорда ул педагогика, логика һәм әдәбият-тел белеме өлкәсенә караган фәннәр белән тирәнтен кызыксына башлый. Бер үк вакытта бик нигезле итеп төрки-татар, гарәп-фарсы, рус телләрен һәм әдәбиятларын өйрәнә. Дүрт ел дәвамында мәдрәсә каршындагы рус классларында да укуы Мөхәммәтханга КТУШка (Казанкая татарская учительская школа) керергә һәм 1908 елда аны «бишле» билгеләренә генә тәмамлап чыгарга мөмкинлек бирә. КТУШта укыган елларында ул укуда югары күрсәткечләргә ирешә, шул сәбәпле 1906 елда

император Алекандр II стипендияенә лаек була. Бу турыда Казан уку-укыту округы тарафыннан 1908 елның 26 маенда бирелгән шәһадәтнамә ТР Милли музее фондларында саклана [ТР ММ, ф. 224 а, 154 эш]. 1935–1938 елларда М. Фазлуллин Татарстан өлкә комитеты каршындагы Марксизм-ленинизм университетының философия бүлегендә укый.

М. Фазлуллинның хезмәт эшчәнлегенең башлангыч чоры мәдрәсә һәм мәктәпләр белән бәйле. 1903 елдан ул үзе яңа гына тәмамлаган Апанай мәдрәсәсендә укытырга чакырыла, рус-татар мәктәпләрендә эшли. 1918 елда Халык мәгариф бүлеге йөкләмәсе нигезендә Мамадышта Укытучылар семинариясе оештыра, аның мөдире булып эшли. 1919 елда Казанга күченеп килгәннән соң, М. Фазлуллин 3 еллык педагогик курсларда татар теле һәм әдәбияты, рус теле методикасын укыта, соңыннан, 1922 елда, бу курслар педагогик техникум итеп үзгәртелә. Әлеге яңа уку йортының барлыкка килүендә, әлбәттә, М. Фазлуллинның да роле зур була. Мөхәммәтхан Әшрәфҗан улының 1929 елдан соңгы педагогик эшчәнлеге югары уку йортлары белән бәйле. Ул Казандагы Татар коммунистик университетында, Казан дәүләт университеты рабфагында укыта, озак еллар дәвамында (вафатына кадәр) Казан дәүләт педагогия институтында: татар теле укытучысы, профессоры (1930 елдан), татар теле кафедрасы мөдире (1934–1954), тел һәм әдәбият факультеты деканы (1934–1935) булып эшли [ТР ММ, ф. 224а, 154 эш].

Әлбәттә, Мөхәммәтхан ага Фазлуллин фәнни даирәдә беренче чиратта татар тел гыйлеме белгече, филология, татар язуы тарихы буенча күпсанлы хезмәтләр авторы буларак билгеле. Ләкин күп еллык педагогик эшчәнлеге, тәрбия теориясе, укыту методикасына караган фәнни китаплары, дәреслекләре аны иң атаклы татар педагогларының берсе итеп танытты. Революциядән соңгы елларда татар мәгарифе тарихын өйрәнгән галим М.К. Мөхәррәмов Мөхәммәтхан Фазлуллинны заманының мәшһүр педагоглары Мөхетдин Корбангалиев, Исхак Казаков, Мозаффар Мөштәриев, Габбас Сәйфуллин, Габдрахман Рафиковлар белән бер рәткә куя [Мухарямов, с. 145]. Дөрестән дә, Мөхәммәтхан Әшрәфҗан улының XX гасыр татар мәгарифе үсешенә керткән өлеше шактый зур һәм ул берничә юнәлеш белән билгеләнә.

Беренчесе – практик эшчәнлек. Әйтеп узылганча, М. Фазлуллинның төп педагогик һәм фәнни эшчәнлеге Казан дәүләт педагогия институты белән бәйле. Ул – татар теле һәм әдәбияты кафедрасын оештыручы буларак татар тарихына кереп калды [Организатор...]. 1929 елның 20 апрелендә М. Фазлуллин татар теле кафедрасы укытучысы итеп билгеләнә. Кафедраның үсеше, педагогик коллектив туплау, киң карашлы, төпле белемле татар теле белгечләре әзерләү белән беррәттән, М. Фазлуллин педагогик эшчәнлекнең бер үк дәрәҗәдә әһәмиятле булган икенче яссылыгына – фәнни хезмәтләр язуга да зур игътибар бирә.

Фәнни эшчәнлек белән, М. Фазлуллин, үзе билгеләп үткәнчә, ул 1903 елдан ук шөгыльләнә башлый [ТР ММ, ф. 224а, 154 эш]. Аның фәнни хезмәтләре нигездә педагогик-методик һәм лингвистик характерга ия. Революциядән соң яңа мәктәп төзү чорында М. Фазлуллин үзен тулы мәгънәсендә методист итеп таныта. Әлифбалар, уку китаплары төзү белән ул үзе шәхсән 20 нче еллардан ук шөгыльләнә [Фазлуллин, 1929; 1939]. Аның зурларны укырга-язарга өйрәтү методикасы үсешенә керткән өлеше шактый зур [Фазлуллин, 1940; 1945]. Татар мәктәпләре өчен программалар, уку планнары төзүчеләрнең берсе һәм беренчесе дә ул була [Шарафутдинов, с. 277]. Ә инде 1922 елдан соң татар башлангыч, җидееллык һәм урта мәктәпләр, педагогия һәм укытучылар институтларының татар бүлекләре өчен барлык программалар, дәреслек һәм методик әсбаплар турыдан-туры аның җитәкчелегендә дөнья күрә [Рамазанова, б. 8].

М. Фазлуллин – педагогика тарихы буенча шактый күп хезмәтләр язган галим. «Мәгариф» журналының җаваплы сәркатибе булып эшләгән чорда (1920–1921) ул рус һәм Европа педагогларының мирасын татар укытучыларына җиткерүгә үзеннән зур өлеш кертә. М. Фазлуллинның татар мәгърифәтчесе һәм педагогы Каюм Насыйри, күренекле татар педагогы, татарлар арасында беренчеләрдән булып Петербург император сәнгать академиясе дипломы алган рәссам Шакирҗан Таһири эшчәнлегенә югары бәя биреп язылган мәкаләләре яхшы билгеле. Г. Тукайның уку китаплары турында 1946 елда ясаган чыгышында галим фәнни даирәдә беренчеләрдән булып шагыйрьнең педагогик эшчәнлегенә туктала [ТР ММ, ф. 224а, 154 эш]. Ул халкыбызның рухи кыйммәтләренә мөрәҗәгать итүнең әһәмияткә ия булуын ачык ассызыклый. Укытучылар, М. Фазлуллин фикеренчә, педагогик мирасыбызга таянып, аны хәзерге чор белән чагыштырып, үзенчәлекле рәвештә кулланып эш итәргә тиешләр; бу аларның үз методикаларын камилләштерергә булышлык итәчәк һ.б. [Фазлуллин, 1920, б. 7]. Галим шулай ук патша Россиясендә мөселман мәктәпләре, хатын-кызларны укыту, совет чорында татар мәктәпләренең үсеше мәсьәләләрен өйрәнүгә дә зур игътибар бирә.

М. Фазлуллинның фәнни-педагогик хезмәтләренең тагын бер юнәлеше – тәрбия мәсьәләләре. Бу юнәлештә безгә билгеле хезмәте – 1913 елда «Йолдыз» газетасында басылып чыккан «Тәгълим вә тәрбия бабыннан» дигән мәкаләсе [Фазлуллин, 1913]. 1922 елда язылган «Баланың теле ничек ачыла?» дигән хезмәтендә ул бала үсешендәге әлеге чорга зур әһәмият биреп, аны дөрес сөйләшергә, авазларны әйтергә өйрәтү, һәр аваз һәм сүзнең мәгънәсенә төшендерү, сөйләм үзенчәлекләрен истә калдыру белән бергә берттән, тәрбияви күзлектән чыгып караганда да иң мөһим чорларның берсе дип саный. Бала белән сөйләшергә, аның сорауларына һәрвакыт җавап бирергә кирәклеген аңлата,

әмма, кызганычка каршы, татарларда баланы олылар арасына алу, аның белән бер югарылыктан торып сөйләшү гадәте таралмаганлыгына борчылуын белдерә: «Бу эшләр, билгеле, балага һәм баланың рухына тәэсирсез калмыйлар, шуның өчен дә, ихтимал, безнең балаларның мәктәпкә яңа килгән вакытларында белемнәре бик аз була һәм булган кадәресен дә сөйләп аңлата алмый торган булалар, телләре җитми, олылар янында сөйли алмый аптырап, боегып торалар» [Фазлуллин, 1922, б. 9]. Шул рәвешле, ул үзен бер үк дәрәҗәдә бала психологиясе белгече итеп тә таныта. Галимнең «Иҗтимагый тәрбияне ничек гамәлгә куярга?» дигән мәкаләсе дә педагогик һәм психологик күзлектән чыгып язылган [Фазлуллин, 1921, б. 9]. Балаларның тән һәм рухи сәламәтлекләрен кайгыртып, ул аларга тәрбия бирүне дәүләт югарылыгында оештыру, тәрбиянең махсус хәзерлекле кешеләр тарафыннан алып барылу мәҗбүрилеген ассызыклый, балаларны җәмгыять эшләренә тарту, хезмәт тәрбиясе бирүнең әһәмиятенә туктала.

Бу уңайдан М. Фазлуллинның татар телен укыту методикасы фәне үсешенә керткән төп хезмәтен дә әйтеп китү дөрес булыр. Аның «Татар теле методикасы» китабы югары уку йортлары өчен методика буенча язылган махсус дәреслекләрнең беренчесе булып тора [Российская.., с. 498]. Һәм ул, билгеле булганча, озак еллар дәвамында студентларга белем бирүдә бердәнбер әсбап буларак файдаланыла. Әлеге кулланма методика фәненә яңача күзлектән чыгып карау ягыннан әһәмиятле. Автор укыту методикасының психологик-педагогик принциплар белән бик тыгыз бәйләнештә булырга тиешлеген ассызыклый, чөнки, аның фикеренчә, нәкъ менә психология нигезләрен яхшы белмәү белем һәм тәрбия бирүдә ялгышларга китерергә мөмкин [Фазлуллин, 1954, б. 20–21]. Ул шулай ук белем бирүдә тәрбиянең роле, телләрне чагыштырмалы ысулга нигезләнеп өйрәнү кебек мәсьәләләргә дә зур игътибар бирә.

Мөхәммәтхан Фазлуллинның методик әсбаплары практикага нигезләнеп, практик укытучы күзлегеннән чыгып язылулары белән әһәмиятле. Әлеге алым татар методикасы тарихында моңарчы да билгеле булган. Мәсәлән, алда искә алынган Шакирҗан Таһириның әлифбаларын үз балаларына укытып тикшергәннән соң гына бастыруы, татарча беренче мөстәкыйль химия дәреслеге авторы буларак билгеле Ибраһим Шинасиның әлеге дәреслеген мәдрәсә шәкертләренә биргән гамәли дәресләренең конспектларына таянып язуы билгеле, ягъни әсбаплар укучылар кулына барып ирешкәнче үк үзенчәлекле апробация үткәннәр. М. Фазлуллинның кулланмалары да, белгечләрнең бик дөрес билгеләвенчә, экспериментларга, төрле дәрәҗәдәге сораштыру-фикер алышулар (анкета уздыру) нәтиҗәләренә нигезләнеп язылган [Шарафутдинов, с. 283]. Әлеге файдалы алым, кызганычка каршы, бүгенге көндә дәреслекләр төзүдә һәр белем өлкәсендә дә кулланылмый.

М. Фазлуллинның иҗтимагый эшчәнлегенә килгәндә, ул турыдан-туры мәгариф белән бәйле, һәм бу өлкәдә дә педагогның шактый нәтиҗәле эшләве билгеле. Мәсәлән, аны революциядән соң барлыкка килгән татар мәктәпләре өчен дәреслекләр төзү буенча комиссия җитәкчесе итеп билгелиләр. Биредә М. Фазлуллинга күренекле педагог-методистлар М. Корбангалиев, Н. Мөхетдинов, Г. Алпаровлар белән бергәләп хезмәт итәргә туры килә. 1917–1919 елларда М.Ә. Фазлуллин татар мәктәпләре инспекторы вазифаларын башкара, бу чорда бик күп яңа мәктәпләр, вузлар оештырыла (өяздә татар мәктәпләренең гомуми саны 230 га җитә [ТР ММ, ф. 224а, 154 эш]). Татар телен гамәлгә кую, татар алфавитын латин графикасына күчерү дәүләт комиссияләре, Татар педагогия җәмгыяте Президиумы Советы әгъзасы, «Мәгариф» журналының җаваплы сәркатибе (1920–1921), 1930–1934 елларда Татарстанны өйрәнү җәмгыятенең «Мәдәният һәм көнкүреш» секциясе, 1931–1932 елларда Татар педагогия институтының коренизация штабы әгъзасы [ТР ММ, ф. 224а, 154 эш] һ.б. – болар М. Фазлуллин башкарган җәмәгать эшләренең кайберләре генә. 1943 елда татар теле терминологиясе буенча хөкүмәт комиссиясе составында Г. Камай, Ш. Рамазанов, Т. Гыйззәт, Х. Мөштәри, У. Контюковлар белән беррәттән, М. Фазлуллин да кертелә [ТР ММ, ф. 224а, 154 эш]. Бу эшләр аның фәнни-педагогик эшчәнлегендә дә чагылыш табалар. Мәсәлән, Фазлуллинның «Яңа әлифбасы» латин графикасында язылган әлифбаларның беренчесе була [Российская.., с. 498].

Гомумән алганда, М. Фазлуллинның татар җәмәгатьчелегенең тел практикасы өлкәсенә караган хезмәтләрен түбәндәге юнәлешләргә бүлеп карарга мөмкин:

– Татар әдәби теленең орфография нигезләре;

– Яңалиф нигезендә татар язуы;

– Рус графикасына нигезләнгән яңа татар алфавиты проектын әзерләү;

– Яңа алфавит нигезендә татар теленең орфографик принциплары;

– Татар фонетик транскрипциясе;

– Сүзлекләр өстендә эш.

Әлеге юнәлешләр галимнең тел белеме өлкәсендәге эшчәнлегенә карау сәбәпле, аларга махсус тукталмыйбыз. Тел галимнәре Д. Рамазанова, С. Сәгыйтов хезмәтләрендә бу турыда шактый мәгълүмат бирелә. Ләкин шулай да, М.Ә. Фазлуллинның искә алынган хезмәтләренең татар мәгарифе, татар мәктәбе, татар телен укыту белән турыдан-туры бәйләнешләре булуын ассызыклыйсы килә.

М. Фазлуллинга 1940 елда ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, шул ук елда «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены бирелә, 1950 елда ул РСФСР ПФАнең мөхбир әгъзасы итеп сайлана. Татар мәгарифе өлкәсендә башкарган эшләре, кыйммәтле фәнни-методик мирасы белән Мөхәммәтхан Әшрәфҗан улы Фазлуллин татар педагогик фикере

тарихында үзенең дәрәҗәле урынын алды. Аның исеме төрле энциклопедик басмаларга кертелгән [Татарская.., с. 72; Российская.., с. 498], басмага әзерләнгән «Татар педагогик фикере антологиясе»нең [Татар...] 2 томында М. Фазлуллинның педагогик эшчәнлегенә багышланган махсус мәкалә бирелде.

**Әдәбият**


*Мухарямов М.К.* Развитие народного образования // Культурная революция в Татарии (1917–1937 гг.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 303 с.

Организатор кафедры татарского языка и литературы // За педагогические кадры. 1940. 7 ноября. № 32 (172).

*Рамазанова Д.Б.* Фазлуллин Мухаметхан Ашрафзянович // Казанская педагогичекая школа. Книга 1. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. С. 86–87.

Российская педагогическая энциклопедия. Т. 2. М.: БРЭ, 1999. С. 498.

Татар педагогик фикере антологиясе. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. ... б.

Татарская энциклопедия: в 6 т. Т. 6. Казань: ИТЭ, 2014 . С. 72.

Татарстан Республикасы Милли музее (ТР ММ), в. 224а, 154 эш.

*Фазлуллин М.* Тәгълим вә тәрбия бабыннан // Йолдыз. 1913. 13, 18 гыйнвар.

*Фазлуллин М.* Дидактика кагыйдәләре: укыту һәм тәрбия өчен кыскача кулланма. Казан: ТССҖ дәүл. нәшр., 1920. 44 б.

*Фазлуллин М.* Иҗтимагый тәрбияне ничек гамәлгә куярга? // Мәгариф. 1921. № 3–4.

*Фазлуллин М.* Баланың теле ничек ачыла? Ата-аналар һәм тәрбия итүчеләр өчен кирәкле китап һәм бала теленең ачылуы турында тәҗрибә ясарга теләгән кешеләр өчен кулланма. Казан: ТХМК, 1922. 32 б.

*Фазлуллин М.* Кызыл юл: Балалар әлифбасы. Казан: Татиздат, 1929. 16 б.

*Фазлуллин М.* Әлифба. Укырга-язарга өйрәтү мәктәбе өчен. Казан: Татгосиздат, 1939. 94 б.

*Фазлуллин М.* Уку китабы. Укырга-язарга өйрәтү өчен. Казан: Татгосиздат, 1939. 186 б.

*Фазлуллин М.* Зурлар өчен әлифба. Казан: Татгосиздат, 1940. 95 б.

*Фазлуллин М*. Әлифба: Грамота мәктәпләре өчен. Казан: Татгосиздат, 1945. 88 б.

*Фазлуллин М.* Татар теле методикасы. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 295 б.

*Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И.* История педагогики Татарстана. Казань: 1998. 306 с.



***Мортазина Ләлә Рәис кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты,*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 517.3

***Ә.Ф. Галимҗанов, А.Ф. Гыйлемҗанов, Ч.Б. Миңнегалиева***

# МАХСУС ИНТЕРПОЛЯЦИОН ПОЛИНОМИАЛЬ ОПЕРАТОР НИГЕЗЕНДӘ ТӨЗЕЛГӘН КВАДРАТУР ФОРМУЛАЛАР

В статье описывается исследование квадратурной формулы для интеграла с ядром Гильберта. Подынтегральная функция приближается интерполяционным полиномом по равноотстоящим узлам, таким, что значения дробного интеграла Вейля для функции и полинома в этих узлах совпадают. Полученные квадратурные формулы проверены при помощи системы Wolfram Mathematica.

**Ключевые слова:** дробный интеграл Вейля, тригонометрический полином, интерполяционный полином, полиномиальный оператор, интеграл с ядром Гильберта

## Кереш

Вакланма тәртиптәге интегралларны өйрәнү хәзерге вакытта күп авторлар тарафыннан дәвам иттерелә. Без алдарак [Галимҗанов, Миннегалиева, б. 99–110] периоды $2\pi$ булган функциягә $I_{\pm}^{\alpha}(T_n)(t_k) = I_{\pm}^{\alpha}(\varphi)(t_k)$ шарты үтәлерлек тригонометрик полином тиңдәш итеп куючы операторның рәвешен билгеләүне караган идек ($t_k$ – $(-\pi;\pi)$ дә бер-берсеннән тигез ераклыкта урнашкан нокталар, $I_{\pm}^{\alpha}$ – Вейль буенча вакланма тәртиптәге интеграл).

Бу эштә Гильберт төшле интеграл өчен тригонометрик интерполяцион күпбуын нигезендә төзелгән квадратур формулалар тикшерелә.

$S(\varphi;t) = \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)ctg\frac{t-x}{2}dx$ рәвешле интеграл Гильберт интегралы дип атала. Монда $ctg\frac{t-x}{2}$ – Гильберт төше. Бу функция беренче тәртиптәге үзенчәлеккә ия. Шуңа интеграл Коши буенча төп кыйммәте мәгънәсендә карала, ягъни

$$S(\varphi;t) = \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)ctg\frac{t-x}{2}dx = \lim_{\varepsilon\to 0}\left[\frac{1}{2\pi}\int_0^{1-\varepsilon}\varphi(x)ctg\frac{t-x}{2}dx + \frac{1}{2\pi}\int_{1+\varepsilon}^{2\pi}\varphi(x)ctg\frac{t-x}{2}dx\right]$$

$S(e^{ikx};t) = i\,\mathrm{sgn}\,k\cdot e^{ikt}$, $\mathrm{sgn}\,k = \begin{cases} 1, k>0 \\ 0, k=0 \\ -1, k<0 \end{cases}$, икәне мәгълүм.

$S(\cos kx;t) = -\sin kt$, $k+1\in N$;

$$S(\cos k\,x;t) = -\sin k\,t\ ,\ k \in N;$$

$$S(const) = 0.$$

Гильберт төшле сингуляр интеграл өчен квадратур процесс һәм төгәллекне бәяләү ысуллары Б.Г. Габделхәев тарафыннан өйрәнелгән иде.

**Гильберт төшле интеграл өчен квадратур формулаларны чыгару**

Гильберт төшле интеграл $S(I^{\alpha}\varphi;t)$ өчен квадратур формулаларны төзик.

Функцияне тригонометрик полином ярдәмендә якынайтыйк.

$$\varphi(t) \approx \varphi_n(t) = \frac{a_0}{2} + \sum_{k=-n}^{n} a_k \cos k\,t + b_k \sin k\,t,\ \text{монда}$$

$$a_k = \frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\cos k\,t_j,\ b_k = \frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\sin k\,t_j \quad (1).$$

Бер-берсеннән бертигез ераклыкта урнашкан нокталарны карыйк

$$t_j = \frac{2j\pi}{2n+1},\ j = \overline{-n,n}.$$

Бу очракта $I^{\alpha}(\varphi_n;t) =$

$$= \underbrace{\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\frac{a_0}{2}\Psi^{\alpha}(x)dx}_{=0} + \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\sum_{k=1}^{n}\left[a_k \cos k(t-x) + b_k \sin k(t-x)\right]\Psi^{\alpha}(x)dx =$$

$$\sum_{k=1}^{n}\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\left[a_k \cos k(t-x) + b_k \sin k(t-x)\right]\Psi^{\alpha}(x)dx =$$

$$\sum_{k=1}^{n}\underbrace{\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}a_k \cos k(t-x)\Psi^{\alpha}(x)dx}_{=I_1} + \sum_{k=1}^{n}\underbrace{\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}b_k \sin k(t-x)\Psi^{\alpha}(x)dx}_{=I_2}$$

$$I_1 = \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}a_k \cos k(t-x)\Psi^{\alpha}(x)dx = \left(I^{\alpha}a_k \cos kx\right)(t) = a_k k^{-\alpha}\cos\left(kt - \frac{\alpha\pi}{2}\right).$$

Шул рәвешле

$$I_2 = \frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}b_k \sin k(t-x)\Psi^{\alpha}(x)dx = b_k k^{-\alpha}\sin\left(kt - \frac{\alpha\pi}{2}\right).$$

Димәк $I^{\alpha}(\varphi_n;t)=\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\left[a_k\cos\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)+b_k\sin\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\right]$ (2).

Дәвам итик:

$$S\left(I^{\alpha}\varphi_n;t\right)=\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\left[I^{\alpha}\varphi_n(x)\right]ctg\frac{x-t}{2}dx=$$

$$\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\left[a_k\cos\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)+b_k\sin\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\right]ctg\frac{x-t}{2}dx=$$

$$\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\left[\int_0^{2\pi}a_k\cos\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)ctg\frac{x-t}{2}dx+\int_0^{2\pi}b_k\sin\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)ctg\frac{x-t}{2}dx\right]=$$

$$\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\left[-a_k\sin\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)+b_k\cos\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\right].\ (3)$$

$a_k$, $b_k$ урынына (1) формулаларын куйыйк һәм (2) белән (3) не карыйк:

$$I^{\alpha}(\varphi_n;t)=$$

$$=\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\left[\frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\cos kt_j\cdot\cos\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)+\frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\sin kt_j\cdot\sin\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\right]=$$

$$\frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\left[\cos kt_j\cdot\cos\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)+\sin kt_j\cdot\sin\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\right]=$$

$$\frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\cos\left[k(t-t_j)-\frac{\alpha\pi}{2}\right].$$

$\Psi_{-}^{\alpha}(t)=2\sum_{k=1}^{\infty}\frac{\cos\left(kt+\frac{\alpha\pi}{2}\right)}{k^{\alpha}}$ булуын истә тотсак,

$I^{\alpha}(\varphi_n;t)=\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\Psi_{n-}^{\alpha}(t_j-t)$, монда

$$\Psi_{n\pm}^{\alpha}(t)=2\sum_{k=1}^{n}\frac{\cos\left(kt\mp\frac{\alpha\pi}{2}\right)}{k^{\alpha}}.$$

$$S(I^{\alpha}\varphi_n;t)=$$

$$=\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\left[-\frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\cos kt_j\cdot\sin\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)+\frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\sin kt_j\cdot\cos\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\right]=$$

$$\frac{2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\sin\left(k(t_j-t)+\frac{\alpha\pi}{2}\right).$$

$$\overline{\Psi}_{n\pm}^{\alpha}(t)=2\sum_{k=1}^{n}\frac{\sin\left(kt\mp\frac{\alpha\pi}{2}\right)}{k^{\alpha}}$$ дип билгелик.

$S(I^{\alpha}\varphi_n;t)$ интегралы булсын өчен $\overline{\Psi}_{n\pm}^{\alpha}(t)$ рәте җыелуы кирәк.

Яки $\overline{\Psi}_{n\pm}^{\alpha}(t)$ түбәндәге рәвештә күрсәтелә ала

$$\overline{\Psi}_{n\pm}^{\alpha}(t)=2\cos\frac{\alpha\pi}{2}\sum_{k=1}^{n}\frac{\sin kt}{k^{\alpha}}\mp 2\sin\frac{\alpha\pi}{2}\sum_{k=1}^{n}\frac{\cos kt}{k^{\alpha}}.$$

$t\neq 0$ булганда бу рәтнең җыелуы түбәндәге теоремадан чыга

**Теорема**

Әгәр $u_0(x)+u_1(x)+...+u_n(x)+...$ рәте тигез җыелса һәм $\{w_v\}$ чикләнгән үзгәрүле эзлеклелек булса, $u_0(x)w_0+u_1(x)w_1+...$ рәте шулай ук бертигез җыела. Әгәр $u_0(x)+u_1(x)+...+u_n(x)+...$ рәтенең өлешчә суммалары тигез чикләнгән булса һәм чикләнгән үзгәрешле $\{w_v\}$ эзлеклелеге нульгә омтылса, бу очракта $u_0(x)w_0+u_1(x)w_1+...$ рәте тигез җыела.

Бу очракта $S(I^{\alpha}\varphi_n;t)=\dfrac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}\varphi(t_j)\overline{\Psi}_{n-}^{\alpha}(t_j-t)$.

$A_n(\varphi;t)$ нигезендә квадратур формулалар төзик.

Гильберт төшле сингуляр интеграл карыйк

$$S(\varphi;t)=\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)ctg\frac{t-x}{2}dx$$

Интеграл астындагы $\varphi(x)$ функциясен интерполяцион полином ярдәмендә якынайтыйк:

$$\varphi(t)\approx A_n(\varphi;t)=\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{|k|=1}^{n}(ik)^{\alpha}e^{i[k(t-t_j)]}.$$

$$S(\varphi;t)=\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)ctg\frac{t-x}{2}dx\approx\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}A_n(\varphi;x)ctg\frac{t-x}{2}dx=$$

$$=\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{|k|=1}^{n}(ik)^{\alpha}e^{i[k(x-t_j)]}ctg\frac{t-x}{2}dx=$$

$$=\frac{1}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{|k|=1}^{n}(ik)^{\alpha}e^{-ikt_j}\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}e^{ikx}ctg\frac{t-x}{2}dx$$

$\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}e^{ikx}ctg\frac{t-x}{2}dx=i\,\mathrm{sgn}\,k\,e^{ikt}$ икәне билгеле. Димәк:

$$S(\varphi;t)\approx\frac{i}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{|k|=1}^{n}\mathrm{sgn}\,k(ik)^{\alpha}e^{k\,(t-t_j)}.$$

$(ik)^{\alpha}=|k|^{\alpha}e^{\frac{\alpha\pi i}{2}\mathrm{sgn}\,k}$ булуын кулланыйк.

$t-t_j=p$ булсын

$$\sum_{|k|=1}^{n}\mathrm{sgn}\,k(ik)^{\alpha}e^{ikp}=\sum_{|k|=1}^{n}\mathrm{sgn}\,k|k|^{\alpha}e^{\frac{\alpha\pi i}{2}\mathrm{sgn}\,k+ikp}=\sum_{|k|=1}^{n}\mathrm{sgn}\,k|k|^{\alpha}e^{i[\frac{\alpha\pi}{2}\mathrm{sgn}\,k+kp]}=$$

$$=\sum_{|k|=1}^{n}\mathrm{sgn}\,k|k|^{\alpha}\left[\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\mathrm{sgn}\,k+kp\right)+i\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\mathrm{sgn}\,k+kp\right)\right]=$$

$$=\sum_{|k|=1}^{n}\mathrm{sgn}\,k|k|^{\alpha}\left[\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\mathrm{sgn}\,k\right)\cdot\cos kp-\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\mathrm{sgn}\,k\right)\cdot\sin kp+\right.$$

$$\left.+i\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\mathrm{sgn}\,k\right)\cdot\cos kp+i\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\mathrm{sgn}\,k\right)\cdot\sin kp\right]=$$

$$=\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\left[\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\cos kp-\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\sin kp+i\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\cos kp+i\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\sin kp-\right.$$

$$\left.-\cos\left(-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\cos(-kp)+\sin\left(-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\sin(-kp)-i\sin\left(-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\cos(-kp)-i\cos\left(-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\sin(-kp)\right]=$$

$$=\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\left[\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\cos kp-\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\sin kp+i\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\cos kp+i\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\sin kp-\right.$$

$$\left.-\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\cos kp+\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\sin kp+i\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\cos kp+i\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\sin kp\right]=$$

$$=\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\left[2i\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\cos kp+2i\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)\cdot\sin kp\right]=2i\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\cdot\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}+kp\right).$$

Бу нәтиҗәне кулланcак, Гильберт төшле интеграл өчен квадратур формула табабыз:

$$\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)ctg\frac{t-x}{2}dx=\frac{-2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}+k(t-t_j)\right) \quad (4).$$

**Wolfram Mathematica системасын кулланып исәпләүләр**

Wolfram Mathematica системасын кулланып үткәргән исәпләүләрнең нәтиҗәсен карыйк. Бу система формулаларны тикшерү өчен еш кулланыла.

Тикшерелгән очрак өчен Вейль буенча вакланма тәртиптәге интеграл Риман-Лиувилль вакланма тәртиптәге интегралы белән тәңгәл килә. Без башта $\varphi(t)=\sin 3{,}6t$ функциясе өчен $n=6$, $\alpha=0{,}6$ булган очракта $I_+^{\alpha}\varphi=\frac{1}{\Gamma(\alpha)}\int_{-\infty}^{t}\frac{\phi(x)dx}{(t-x)^{1-\alpha}}$ һәм $I^{\alpha}(\varphi_n;t)=\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\left[a_k\cos\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)+b_k\sin\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\right]$ (2) формулалары буенча исәпләнгән вакланма тәртиптәге интеграл кыйммәтләрен чагыштырдык (1 нче таблица):

1 нче таблица

| $t$ | $-\frac{12}{13\pi}$ | $-\frac{10}{13\pi}$ | $-\frac{8}{13\pi}$ | $-\frac{6}{13\pi}$ | $-\frac{4}{13\pi}$ | $-\frac{2}{13\pi}$ | 0 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| $I_+^{\alpha}\varphi$ | 0,1887 | 0,12625 | −0,54124 | 0,07313 | 0,39437 | −0,18985 | −0,41678 |
| $I^{\alpha}(\varphi_n;t)$ | 0,42945 | 0,10006 | −0,46314 | 0,05589 | 0,44432 | −0,2055 | −0,37513 |

| $t$ | $\frac{2}{13\pi}$ | $\frac{4}{13\pi}$ | $\frac{6}{13\pi}$ | $\frac{8}{13\pi}$ | $\frac{10}{13\pi}$ | $\frac{12}{13\pi}$ |
|---|---|---|---|---|---|---|
| $I_+^{\alpha}\varphi$ | 0,35012 | 0,22119 | −0,39345 | −0,17624 | 0,51682 | −0,15303 |
| $I^{\alpha}(\varphi_n;t)$ | 0,33181 | 0,2634 | −0,4205 | −0,12181 | 0,46152 | −0,03359 |

$\varphi(t)=\sin 3{,}6t$, $n=20$, $\alpha=0{,}6$ өчен исәпләү нәтиҗәләре 1 нче рәсемдә күрсәтелгән:




**1 нче рәсем.** Якынча исәпләүләр

Аннары Гильберт төшле интеграл өчен (4) формуласын тикшердек:

$$\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)ctg\frac{t-x}{2}dx=\frac{-2}{2n+1}\sum_{j=-n}^{n}I^{\alpha}(\varphi;t_j)\sum_{k=1}^{n}k^{\alpha}\sin\left(\frac{\alpha\pi}{2}+k(t-t_j)\right) \quad (4)$$

Бу формуланы тикшерү өчен без Б.Г. Габделхәев тарафыннан чыгарылган формуланы кулландык:

$$\frac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)ctg\frac{t-x}{2}dx=\frac{2}{2n+1}\sum_{k=0}^{2n}\varphi_k\frac{\sin(n+1)\frac{t_k-x}{2}\cdot\sin n\frac{t_k-x}{2}}{\sin\frac{t_k-x}{2}} \quad (5)$$

2 нче рәсемдә $\varphi(t)=\sin 3{,}6t$, $n=50$, $\alpha=0{,}6$ өчен [0.1, 3] кисемтәсендә 0.01 адымы белән (4) һәм (5) формулалары буенча исәпләнелгән кыйммәтләр китерелгән. Бу очракта $I^{\alpha}(\varphi;t_j)$ кыйммәтләре $I_+^{\alpha}\varphi=\frac{1}{\Gamma(\alpha)}\int_{-\infty}^{t}\frac{\phi(x)dx}{(t-x)^{1-\alpha}}$ формуласы буенча табылды.




**2 нче рәсем**. Гильберт төшле интеграл кыйммәтләре, $\varphi(t)=\sin 3{,}6t$, $n=50$, $\alpha=0{,}6$

3 нче рәсемдә $\varphi(t)=\sin 3{,}6t$, $n=50$, $\alpha=0{,}6$ өчен [0.1, 3] кисемтәсендә (4) һәм (5) формулалары буенча исәпләнелгән кыйммәтләр китерелгән. Бу очракта $I^{\alpha}(\varphi;t_j)$ кыйммәтләре $I^{\alpha}(\varphi_n;t)=\sum_{k=1}^{n}k^{-\alpha}\left[a_k\cos\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)+b_k\sin\left(kt-\frac{\alpha\pi}{2}\right)\right]$ формуласы буенча табылды.




**3 нче рәсем.** Төрле формулалар буенча исәпләнелгән Гильберт төшле интеграл кыйммәтләре

4 нче рәсемдә $\varphi(t)=\sin 3{,}6t$, $n=100$, $\alpha=0{,}6$ өчен [0.1, 3] кисемтәсендә (4) һәм (5) формулалары буенча исәпләнелгән кыйммәтләр китерелгән.




**4 нче рәсем.** Гильберт төшле интеграл кыйммәтләре, $\varphi(t)=\sin 3{,}6t$, $n=100$, $\alpha=0{,}6$

5 нче рәсемдә $\varphi(t)=\sin 3{,}6t$, $n=100$, $\alpha=0{,}9$ өчен [0.1, 3] кисемтәсендә (4) һәм (5) формулалары буенча исәпләнелгән кыйммәтләр китерелгән.




**5 нче рәсем.** Гильберт төшле интеграл кыйммәтләре,
$\varphi(t) = \sin 3{,}6t$, $n = 100$, $\alpha = 0{,}9$

Исәпләүләрне дәвам итеп без башка функцияләрне карадык. С.Г. Самко, А.А. Килбас, О.И. Маричев вакланма тәртиптәге интегралларның Вейль буенча вакланма тәртиптәге интеграл үзлекләрен өйрәнгәндә $\varphi_0 = \dfrac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)dx = 0$ шарты үтәлүче функцияләрне карыйлар. $\varphi(t) = \sin 3{,}6t$ функциясе өчен $\varphi_0 = \dfrac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)dx \approx 0{,}07997$.

$\varphi(t) = \sin 3{,}01t$ функциясе өчен $\varphi_0 = \dfrac{1}{2\pi}\int_0^{2\pi}\varphi(x)dx \approx 0{,}0001$.

6 нчы рәсемдә $\varphi(t) = \sin 3{,}01t$, $n = 100$, $\alpha = 0{,}6$ өчен [0.1, 3] кисемтәсендә (4) һәм (5) формулалары буенча исәпләнелгән кыйммәтләр китерелгән.




**6 нчы рәсем.** Гильберт төшле интеграл кыйммәтләре,
$\varphi(t) = \sin 3{,}01t$, $n = 100$, $\alpha = 0{,}6$

$\varphi(t)=\sin 3{,}01t+\cos t$ функциясе өчен $\varphi_0=\dfrac{1}{2\pi}\int\limits_0^{2\pi}\varphi(x)dx\approx 0{,}0001$.

7 нче рәсемдә $\varphi(t)=\sin 3{,}01t+\cos t$, $n=100$, $\alpha=0{,}6$ өчен [0.1, 3] кисемтәсендә (4) һәм (5) формулалары буенча исәпләнелгән кыйммәтләр китерелгән.




**7 нче рәсем.** Гильберт төшле интеграл кыйммәтләре,
$\varphi(t)=\sin 3{,}01t+\cos t$, $n=100$, $\alpha=0{,}6$

## Нәтиҗә

Тикшерелә торган квадратур формула буенча табылган кыйммәтләр моңарчы кулланылган формула нигезендә исәпләнгән кыйммәтләр белән чагыштырылды. $n$ санының артуы төгәллекне арттыра, якынайту шулай ук $\alpha$ кыйммәтенә бәйле икәне күренә. Төрле функцияләр алып тикшергәндә С.Г. Самко, А.А. Килбас, О.И. Маричев шартыннан тайпылу әзрәк булган саен төгәллек артуы күренә.

### Әдәбият

*Габдулхаев Б.Г.* Об аппроксимации тригонометрическими полиномами и погрешности квадратурных формул для сингулярных интегралов // Ученые записки Казанского государственного университета. Т. 127, кн. 1: Функциональный анализ и теория функций. Сб. 4. Казань, 1967. С. 54–74.

*Габдулхаев Б.Г.* Об одном общем квадратурном процессе для сингулярных интегралов [Текст] // Ученые записки Казанского государственного университета. Т. 127, кн. 1: Функциональный анализ и теория функций. Сб. 4. Казань, 1967. С. 75–90.

*Галимҗанов Ә.Ф., Миңнегалиева Ч.Б.* Гомумиләштерелгән интерполяцион полиномиаль оператор // Фәнни Татарстан. 2015. № 4. Б. 99–110.

*Зигмунд А.* Тригонометрические ряды. Том 1. М.: Мир, 1965. С. 11–13.

*Самко С.Г., Килбас А.А., Маричев О.И.* Интегралы и производные дробного порядка и некоторые их приложения. Минск: Наука и техника, 1987. С. 263–265.

*Galimyanov Anis F., Minnegalieva Chulpan B.* Generalized Interpolating Polynomial Operator An [Text] // International Journal of Applied Engineering Research ISSN 0973-4562 Volume 10, Number 24 (2015). pp 45194–4520.

*Qian Chen, Jin Rong Wangb, Fulai Chen, Yuruo Zhang.* Periodic solutions of quadratic Weyl fractional integral equations // Commun Nonlinear Sci Numer Simulat 19 (2014) 1945–1955.

***Галимҗанов Әнис Фуат улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының функцияләр теориясе кафедрасы доценты*

***Гыйлемҗанов Алмаз Фердинант улы,***
*Казан (Идел буе) федераль университетының Исәпләү математикасы һәм информацион технологияләр институты, информацион системалар кафедрасы аспиранты*

***Миңнегалиева Чулпан Бакый кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының мәгълүмати системалар кафедрасы доценты*

УДК 821.512.145

*К.М. Миңнуллин*

# ТУКАЙНЫ ӨЙРӘНҮ ФӘНЕ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕ КАЗАНЫШЛАРЫБЫЗ, КИЛӘЧӘК ХАКЫНДА УЙЛАНУЛАР

Исследования феномена Тукая продолжаются на протяжении века, за это время изданы сотни научных трудов, в которых дается оценка личности поэта, его роли в общественной, политической жизни татарского народа, места в литературном процессе в масштабах всего тюркского мира.

В статье предпринята попытка показать историю развития тукаеведения с упором на современные его достижения, включая работу над Энциклопедией Г. Тукая, ставящей целью рассмотреть жизнь и творчество поэта в их целостности, в контексте исторической обстановки и литературного окружения, и нового академического собрания сочинений Г. Тукая в 6 томах.

**Ключевые слова:** тукаеведение, татарская литература начала XX века, Энциклопедия Г. Тукая, академическое собрание сочинений Г. Тукая в 6 томах.

«Без – бәхетле, без – шагыйрьле халык,
Без – Тукайлы халык мәңгегә»,

дип яза замандашыбыз! Чыннан да, менә 130 ел инде татар халкы Тукайлы халык булып яши. Мәдәни тормышның төрле өлкәләрендә Тукай нигезләгән сукмаклар зур юлларга әверелгән. Фән һәм сәнгатьтә күп казанышлар Тукай исеме белән бәйле, аның башлангычларына барып тоташа. Татар әдәбият белеме дә – шундыйлар исәбендә.

Тукай феномены шагыйрь иҗатының әдәби мәйданга чыккан вакытыннан алып хәзергә кадәр һәр чорда да игътибар үзәгендә булуы белән дә аңлатыла. Ул татар халкының рухи-мәдәни хәзинәсендә Тукай шәхесенең урыны һәрвакыт түрдә булуны да белдерә. Чөнки нинди генә заманнар килеп, Тукай мирасын кысан идеологик чикләүләр арасына кертеп һәм «вак буржуаз шагыйрь» дип тикшерергә омтылулар, субьектив кире кагулар яки чиктән тыш зурлау-олылау, таң калып мактаулар, аннан атеист яки кызыл көрәшче ясарга тырышулар булмасын, шагыйрьнең олы талант иясе икәнлеге беркайчан да шиккә алынмады.

Әмма әдәбият белеме тарихын Тукай белән бәйләүнең сәбәбе башкада. Фән буларак татар әдәбият белеме егерменче йөз башында формалаша, Тукай иҗаты бу хәрәкәтнең үзәгенә куела. Чөнки яшь Тукай иҗатының төрле якларын тикшерү һәм бәяләү шагыйрьнең беренче әсәрләре укучы кулына барып ирешүгә үк башлана һәм XX йөз башында инде Тукай турындагы фәннең (Тукай гыйлеменең) нигезләре салына.

Бер яктан, әле генә дөнья күргән әсәрләрне бәяләү әдә-

би тәнкыйть белән үрелеп китә. Тукайның шигырь җыентыклары басылып чыгу уңаеннан язылган Ф. Әмирхан хезмәтләре – моңа ачык мисал. «Г. Тукаев шигырьләре» (I) (1907), «Г. Тукаев шигырьләре» (II) (1908), «Г. Тукаев диваны» (1909) мәкаләләрендә шагыйрь иҗаты тарихи планда, үсеш барышында күзәтелә. «Г. Тукаев шигырьләре, 3-нче дәфтәр» җыентыгына нисбәтле Ф. Әмирхан: «Тукаев шигырьләрендә хис ителгән хосуси татарлык рухының аңкуы безгә Тукаевның озакламый камил мөстәкыйль татар шагыйре булачак икәнчелеген күрсәтәдер», дисә [Әмирхан, б. 93], озак та үтми, ул аны «бөтенләй татар шагыйре» дип бәяли. Татар әдәбияты тарихына багышланган беренче язмаларда ук, Тукай милли әдәбиятның борынгы чордан башланган юлын яңа заманга тоташтыра, дигән фикер уздырыла [Гыйләҗев, 2005]. Г. Ибраһимовның «Әдәбият мәсьәләләре» (1910) дигән күләмле хезмәтендә бу шулай: автор Тукай иҗатына, аның халыкчанлыгына, фольклордан килгән үзенчәлекләрне саклавына югары бәя бирә.

XX йөз башы – татар әдәбиятының кискен үзгәреш чоры, шуңа да татар шигъриятендә үзе хакында көчле хәбәр иткән Тукай иҗаты милли әдәбиятның киләчәккә үсеш юлларын барлау, «Нәрсә ул матур әдәбият?», «Татар шигыре нинди булырга тиеш?» дигән сорауларга бәйле бәхәсләр үзәгенә куела. Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре», Җ. Вәлидинең «Татар шагыйрьләре» кебек күләмле хезмәтләрендә Тукай иҗатының татар әдәбияты тарихындагы урынын шушы мәсьәләләр яктылыгында билгеләү омтылышы башкарыла. Татар әдәбияты теориясеннән беренче хезмәтләрдә Тукай шигырьләре нәзари төшенчәләргә, кагыйдәләргә мисал була [Заһидуллина, 2000].

Гомумән алганда, Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Р. Фәхретдин, М. Бигиев, Н. Думави, һ.б. язмаларында бәхәсләр һәм фикерләр каршылыгы аша шагыйрьнең иҗатына мөнәсәбәт формалаша. Тукай иҗаты шагыйрь үзе исән вакытта ук татар әдәбиятының үсеш-үзгәрешендә хәлиткеч роль уйнаган, аның кыйбла үзгәртүен, рус-европа әдәбиятларындагы әдәби-эстетик казанышларны үзләштерүен тәэмин иткән, үз шигъри мәктәбен булдырган бөек иҗатчы дип бәяләнә.

Нәтиҗә ясап, бүген без тагын бер хакыйкатьне күрсәтә алабыз: әдәбият фәне тарафыннан Г. Тукай тормышы һәм иҗаты бер гасырдан артык вакыт эчендә шактый тулы һәм эзлекле өйрәнелеп килә, татар әдәбият белеме Тукайны өйрәнү фәне белән янәшә, аңа таянып үсә.

1917 елдан соң да татар галимнәре Тукай иҗатына кыйммәтле мирас итеп карау тенденциясен сакларга омтыла. Г. Рәхим, Җ. Вәлиди, Ф. Борнаш, Г. Сәгъди хезмәтләрендә бу иҗат тирән бәя ала, Г. Сәгъдинең 1926 елда Тукайны татарның Пушкины дип атавы да шул хакта сөйли [Гыйләҗева, 2012]. Әмма 1928–1937 еллар арасында, әдәби-мәдәни мираска мөнәсәбәт үзгәрүгә

бәйле, Тукай иҗатын сыйнфый көрәш күзлегеннән бәяләү омтылышлары да булып ала.

1960–1980 еллар – Тукай иҗатына социологик чикләүләрдән арынып әйләнеп кайту, бер үк вакытта әсәрләренә шактый төгәл идея-эстетик анализлар ясау чоры. Бу чорда Тукай иҗатын тулаем XX йөз татар шигърияте барышында, фонында анализлау эше башкарыла. Бу нисбәттән, әдәбият галимнәреннән Г. Халитнең, М. Гайнуллинның, И. Нуруллинның хезмәтләре аерым бер югары урын тота.

Совет чорында Тукайны өйрәнү фәнендә аның тормыш биографиясен мөмкин кадәр тулы тергезү эше алып барыла. Бу урында Р. Нәфыйговны, аның архивларда, Тукай белән бәйле урыннарда эзләнеп язылган хезмәтләрен искә алу урынлы булыр. Тукай тормышы-иҗатының төрле якларын фәнни, әдәби-публицистик планда тергезгән соңгырак чор галимнәреннән Р.К. Ганиева, М. Мәһдиев, Н. Лаисов, И. Пехтелев, Р. Башкуров һ.б. тукайчы буларак танылдылар.

XX–XXI гасырлар чигендә Тукай иҗатын тикшерү тагын да колачлырак төс алды. Бигрәк тә моңа кадәр игътибар үзәгеннән читтә калдырылып килгән яклар: бу иҗатта шәркый-романтик һәм суфыйчылык традицияләренең чагылышы (Р.К. Ганиева, Н.Ш. Хисамов, Ф.З. Яхин), Тукайның Аллага, Коръән тәгълиматына мөнәсәбәте (Д.М. Абдуллина) шундыйлардан.

Тукай һәм татар әдәбият белеме бәйләнешләренең төрле яклары хакында озаклап һәм тәфсилләп сөйләргә мөмкин. Шулардан төп өч юнәлешне аерып күрсәтү максатка ярашлы булыр. Беренчесе – XXI гасырда Тукай иҗатын кабат барлау, эзләнү һәм текстологик эш башкарып, халыкка кайтару юнәлеше. Әлбәттә, Тукай иҗаты үзе исән вакытта да, аннан соңгы йөз елда да даими нәшер ителә, хәтта күптомлыклар рәвешендә алты мәртәбә дөнья күрә. Бу басмалар, аларның тарихы әдәбият галиме Зөфәр Рәмиев тарафыннан шактый тулы тергезелде, халыкка җиткерелде [Рәмиев, 2014, б. 17–22, 60–72].

Тукай язма мирасын басмага әзерләү, тәнкыйди тикшерү, теге яки бу текстларның анықы икәнлеген раслау эшен менә 70 елдан артык Татарстанның Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре алып бара. Институт төзелгәч тә, 1939 елда андагы әдәбиятчылар алдына Тукай әсәрләренең академик басмасын әзерләү бурычы куела. Бу эшне Якуб Агишев белән Хәй Хисмәтуллин башкарып чыгалар. Академик басма булып чыкмаса да [Юзиев, б. 40], ул алдагы басмалар өчен нигез була һәм һәр буын галимнәргә академик басма әзерләү кирәклеген искәртеп тора. Хәтта 1985–1986 елларда шагыйрьнең 100 еллыгына багышлап биштомлык нәшер ителгәндә дә, аның төзүчесе, текстларны, аңлатма һәм искәрмәләрне әзерләүчесе Рашат Гайнановның Тукай текстологиясен гаять югары баскычка күтәрүенә карамастан, идеологик чикләүләр аның эчтәлегенә йогынты ясый. XXI гасырда татар галимнәренә бу эшне объектив

һәм чикләүләрсез башкарырга мөмкинлек ачылды: Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты текстологлары алтытомлык булып чыгачак академик басма әзерләүгә керештеләр. Аның шигъри әсәрләрдән торган 1 нче һәм 2 нче томнары 2011 елда басылып чыкса, бүген инде без алты томлыкны тулысынча кулыбызга алдык.

Академик басма – бүгенге Тукай текстологиясенең зур казанышы, ул Тукайга нисбәтле татар телендәге һәм кайбер башка телләрдәге барлык вакытлы матбугат сәхифәләрен, кулъязма һәм басма чыганакларны кабат барлап, эзләнеп, авторлык мәсьәләсендә яшәп килгән каршылыклар ачыкланып әзерләнде. Төзүчеләр һәрбер текстны чыганаклар буенча тикшереп, аларга күпсанлы төзәтмәләр кертте, искәрмә һәм аңлатмаларны тулыландырып, идеологик ялгышлардан арындырды. Томнарга Тукай исән вакытта чыккан китаплардагы иллюстрацияләр, «Яшен», «Ялт-йолт» журналларындагы карикатуралар урнаштырылды. Академик басма нәшер ителеп, без бүген Тукай текстологиясе хәзерге шартлар мөмкинлек биргән дәрәҗәдә тулы эшләнгән дия алабыз. Академик басманы әзерләү вакытында Тукай әсәрләренең язылу тарихы (вакыты, урыны, сәбәбе, максаты, кулъязма нөсхәләре ачыкланды), кулъязмалар һәм авторлаштырылган басмалар үзара чагыштырылды, автографлар анализланды, әсәрләренең язылышы психологик-эстетик планда күзәтелде һ.б. Тукай тормышы-иҗатының иң тулы елъязмасы эшләнде [Габдулла Тукай, 2003].

Бүген татар әдәбият белемендә башка шагыйрьләр һәм язучыларның академик басмаларын әзерләү өчен Тукайның алтытомлыгы үрнәк булып тора. Нәкъ шушы үрнәктә Институтыбыз Г. Ибраһимовның 15 томлыгын әзерләүгә керешә. Киләчәктә Ф. Әмирхан, Ш. Камал һ.б. күренекле иҗатчыларыбызның да академик басмалары төзелер дип ышанабыз.

Шул ук вакытта, академик басма Тукай иҗатын төгәл-фактологик барлау юнәлешендә яңа бурычлар куя. Бу юлда кала килүче «бушлыкларны» тутыруга аның тормышы-иҗаты белән бәйле барлык басма чыганаклар исәпкә алынган тулы библиографик күрсәткеч этәргеч булыр иде. Бу хакта татар матбугатында кырык елга якын сөйләсәк тә [Җамалетдинов, 1978; Рәмиев, 2014, б. 55–60], аның башкарылганы юк әле.

Тукай юбилеена институт галимнәре әзерләгән тагын бер зур бүләк – «Тукай энциклопедиясе» – бу көннәргә нәшер ителеп өлгермәсә дә, якын арада укучы кулына барып ирешер. Татар әдәбият белемендә беренче тапкыр без татар телендә персональ, шәхси энциклопедия әзерләдек. Сигез тематик юнәлешне үз эченә алган олы хезмәттә Тукай феномены төрле яклап ачыла. Монда Тукайның һәр әсәренә анализ бирелә, аның иҗтимагый-сәяси, әдәби-эстетик, фәлсәфи карашлары шактый тулы урын алган, Тукайга яки аның иҗатын өйрәнүгә бәйләнеше булган һәр шәхес хакында мәгълүмат

китерелә. Тукайның башка халыклар мәдәнияте, бигрәк тә төрки дөнья белән бәйләнешләре аерым урын тота. Тукай образының әдәбиятта һәм сәнгатьтә чагылышы, иҗатының фәнни өйрәнелеше, аның белән бәйле урыннар да күз уңыннан читтә калмады. Тукайга кагылышы булган бөтен мәгълүматларны бергә туплаган гаять бай хәзинә килеп чыкты.

«Тукай энциклопедиясе» – Тукайны өйрәнү фәненең бүгенге торышын гына түгел, бәлки татар әдәбият белеменең хәзерге хәлен дә ачык күрсәтеп тора. Тукай шәхесе, аның иҗаты бүген дә татар фәнен югарырак баскычка күтәрүгә хезмәт итә, Тукайны өйрәнү фәне исә татар әдәбият белемен әйдәп бара.

Бу басма татар халкының башка күренекле шәхесләрен дә энциклопедик форматта өйрәнү мөмкин һәм кирәк икәнлекне дәлилли! Үз чиратында, энциклопедиядәге материалларны башка укучылар төркеме өчен кабат әзерләү, әйтик, кыскартып һәм чит аудиториягә кабул итәр өчен яраклаштырып рус телендә яки инглиз телендә нәшер итүне дә көн тәртибенә куя.

«Тукай энциклопедиясе» Тукайны өйрәнү фәненең дә, гомумән татар әдәбият белеменең дә үсеш перспективаларын билгеләүгә этәргеч бирә. Бу урында алдарак искәртелгән өченче юнәлеш турында искәртү урынлы булыр. Ул – күренекле каләм әһелләренең иҗатын, шул исәптән Тукайны өйрәнү, анализлау, бәяләү юнәлеше.

Тукай иҗатын әлеге яссылыкта тикшерү менә йөз елдан артык татар әдәбияты тарихын, аның аерым чорларын, шул чорларда иҗат иткән күренекле язучы-шагыйрьләрнең иҗатын тикшерү белән үрелеп бара. Бу ноктадан караганда, Тукай иҗатын өйрәнү тарихи яктан (нигездә тормыш фактларына таянып) һәм поэтик яктан (иҗатын бәяләү) кебек ике сукмакка аерыла. Соңгы 20–25 елда тарихи якын килү сукмагы нык саекты, бу өлкәне дә филолог-галимнәр яки төбәкне өйрәнүче һәвәскәрләр алып бара башлады. Поэтик яктан исә Тукай иҗатын өйрәнү аны теге яки бу тар проблема яссылыгында караш ташлау, фикер әйтү рәвешен алды, бу эшкә барлык татар галимнәре диярлек тартылды. Шагыйрьнең юбилейлары һәм туган көннәре уңаеннан уздырылган фәнни-гамәли конференция материалларында, аларны туплаган махсус җыентыкларда Тукай хакында сөйләшүнең тукталганы юк. Татар әдәбият белемендә Тукай темасы монографик планда эзләнүләрнең дә бер өлеше булып кала. Институтыбызда 2005 елда Д. Абдуллина тарафыннан Тукай иҗатында Коръән мотивлары хакында әзерләнгән диссертация [Абдуллина, 2005] – моның ачык мисалы. Шулай ук Институтта моңа кадәр билгесез әдәби-тарихи мирас кайтуга [Ил йолдызы, 2006] бәйле дөнья күргән җыентыклар, әйтик, 2006 елда басылган «Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай» җыентыгы, яки яңа эзләнүләр нәтиҗәсе булып чыккан хезмәтләр, мәсәлән, Зөфәр Рәмиевнең текстологиягә

кагылышлы күпсанлы хезмәтләре дә [Рамеев, 2008] шул хакта сөйли.

Яңа материаллар кайту, фәнни әйләнешкә керү, бигрәк тә тарихи һәм әдәби мәгълүматларның энциклопедик форматта бер урынга җыйналуы Тукай шәхесенә, аның эшчәнлегенә мөнәсәбәтне баета, тирәнәйтә. Иҗтимагый-сәяси һәм милли-тарихи карашларының киңлеге, концептуальлеге Тукайның көчле фикер иясе, татар яңарышының лидерларыннан берсе булуына ныграк игътибар итү кирәклекне дә көн тәртибенә куя. Татар җәмгыятен яңарту, милли үзаң үстерү максатыннан башланган XX гасыр башы яңарыш хәрәкәтенең башка күренекле әйдаманнары: Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Муса Бигиев, Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинов һәм башкалар тормышы-эшчәнлегенә, иҗатына, карашларына бәйле күптөрле һәм бай тарихи-мәдәни материаллар кайту Тукай феноменын шулар янәшәсендә, татар яңарышы тарихы фонында, шушы яңарышның күптөрле агымнары, партияләре, төркемнәре, аларның карашлары, хыялы-өметләре, ихтыяҗлары яктылыгында өйрәнү вакыты җиткәнлек турында сөйли.

**Әдәбият**


Абдуллина Д. Коранические мотивы в творчестве Габдуллы Тукая: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2005.

Әмирхан Ф. Әсәрләр: 4 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Т. 4: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар.

Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы / төз.: Ә.Х. Алеева, Ф.И. Ибраһимова; ред.: Н.Г. Юзеев, Ә.Х. Алеева, З.З. Рәмиев. Казан, 2003.

Гыйләҗев Т.Ш. Габдулла Тукай: әдәби мирасы һәм заман // Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 13–86.

Гыйләҗева Ч.М. Әдәбият фәне һәм Габдрахман Сәгъди. Казан, 2012.

Җамалетдинов Л. Тукай библиографиясе // Соц. Татарстан. 1978. 25 апрель.

Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият теориясеннән беренче дәреслекләрдә Тукай иҗаты // Тукай укулары, 1999. Казан, 2000. Б. 117–122.

Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай / төз.: З.Г. Мөхәммәтшин. Казан, 2006.

Рамеев З.З. Текстология татарской литературы начала XX века. Казань, 2008.

Рәмиев З. Тукай иҗаты библиографик хезмәтләрдә // Рәмиев З. Әдәбиятчы текстолог язмалары. Казан: Ихлас, 2014. Б. 55–60.

Рәмиев З. Әдәбиятчы-текстолог язмалары. Казан: Ихлас, 2014.

Юзиев Н. Әдәбият чыганаклары белеме. Казан, 1998.



***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

УДК 821.512.145

***Р.М. Галиева***

# «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНДА Г. ТУКАЙ ТЕМАСЫНЫҢ КУЕЛЫШЫН ӨЙРӘНҮ

Статья посвящена изучению темы Г. Тукая в периодической печати. Цель данной статьи – рассмотреть особенности представления поэтического наследия Г. Тукая в газете «Ватаным Татарстан» (1918–2016 гг.). Основные задачи исследования связаны с выявлением тукаевской темы в газетных материалах, изучением художественных особенностей творчества поэта. Газета «Ватаным Татарстан», являясь рупором общества, вносит неоценимый вклад в создание истории общественно-политической жизни страны, а также позволяет наиболее полно представить творческое наследие Г. Тукая.

**Ключевые слова:** поэт, газета, материалы.

Татарның мәшһүр улы, танылган шагыйрь, XX гасыр башы татар иҗтимагый тормышында актив катнашкан Габдулла Тукай шәхсиятенең вакытлы матбугатта бирелешен, аның иҗатына карата бәяне без «Ватаным Татарстан» газетасы аша анализларга омтылдык. 98 ел дәвамында чыгучы әлеге газетаның бай тарихи үткәне бар. Татарстан халкының елъязмасын язучы бу басмада татар халкының мәдәни һәм рухи тормышы тулы чагылыш тапкан. «Эш» (1918–1920), «Татарстан хәбәрләре» (1920–1922), «Татарстан» (1922–1924), «Кызыл Татарстан» (1924–1951), «Совет Татарстаны» (1951–1960), «Социалистик Татарстан» (1960–1992) дип аталган хәзерге «Ватаным Татарстан» газетасында халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай иҗатына да урын бирелгән. Моны күпсанлы язмалар аша күзәтергә һәм өйрәнергә була.

Габдулла Тукай темасы, гомумән, көндәлек басмада ни дәрәҗәдә яктыртыла? Матбугаттагы язмаларда Тукайга мөрәҗәгать итү, иҗатына бәя бирү бармы? Әлбәттә, бар! Бу хакта шулай дип белдерәбез, әмма, реаль чынбарлык, архивтагы газета төпләнмәләре башка төрле мәгълүмат бирә. Нигездә, язмалар Тукайның үлеменә һәм тууына бәйле рәвештә генә әзерләнгән. Тагын бер факт: 1945 елга кадәр шагыйрьнең үлеменә бәйле 15 апрель көннәрендә, соңрак 26 апрель – туган көне алдыннан искә алынып язылган мәкаләләр урын алган. 1918, 1919, 1924, 1930 һәм 1940 елгы төпләнмәләрдә Тукай хакында бер язма да табылмады. Димәк, кайбер елларда шагыйрь иҗатына игътибар бик аз булган яки бөтенләй дә әһәмият бирелмәгән дигән фикер кала. Күбрәк вафатына һәм тууына бәйле түгәрәк даталарда гына шагыйрь, аның иҗаты турында искә алына.

Газетаның кайбер язмаларына тукталып үтик. «Кызыл Татарстан»ның 1928 ел, 15 апрель санында Демьян Фәтхинең «Габдулла Гариф улы Тукаев»,

Галимҗан Нигъмәтинең «Үлгәненә 15 ел тулды» дип аталган мәкаләсе басыла. Соңгысы Тукайның зур рәсеме белән бирелә. 1929 елның 14 апрелендә Гадел Кутуйның «Тукай янында» шигыре, Тукай турында бүгенге хезмәтләрнең кайберләренә хәзерлек мәсьәләсе турында язма урын алган. Шулай ук газетада Тукайның рәсеме бирелгән. Шунда ук бер хәбәр игътибарны җәлеп итә: «Тукай һәм Бабич. Аларның хәзерге тормышка карата әйткән сүзләре. Һәркем 25 тиен әзерләп торсын, "Чаян"ның 14 номерында әзерләнә» диелгән.

1942 елның 15 апрель санында шагыйрь үлеменә 29 ел тулу уңае белән Гадел Кутуйның «Патриот Тукай» язмасы бирелгән, шагыйрьнең портреты да урнаштырылган. Мәкаләдә Г. Тукайның «Китмибез», «Шүрәле» шигырьләре аша туган җирнең изгелеген анализлап, менә нинди нәтиҗә ясала: «Тукайның бу шигъри юллары сугыш кырларында фашизмга каршы җимергеч ударлар ясаучы батырларның йөрәкләрендә яшиләр. Алар белән янәшә үз туган иле өчен патриот Тукай да көрәшә». Гадел Кутуй 16 нчы апрельдә шул ук темага Татарстан Совет Язучылары Союзында доклад укый. Бу хакта газетада игълан да басылган.

1943 елның 15 апрелендә Тукай вафатына 30 ел тулу уңае белән газетада Якуп Агишевның «Безнең Тукай» язмасы, Кави Нәҗминең шагыйрь иҗатына анализ ясаган язмасы урын ала. Шунда ук Тукай рәсеме һәм шигырьләреннән өзекләр китерелә. Газетада Гази Кәшшафның «Татар халкының бөек улы» язмасында шагыйрь иҗатына әчтәлекле бәя бирелгән. Автор аның «Өзелгән өмит», «Тормыш», «Ваксынмыйм» шигырьләрен анализлый. «Бөек шагыйрьнең гомере кыска булды, һәм ул гомер коточкыч авыр чорга туры килде... Тукайның шатлыгы да, кайгысы да халык язмышы, халык тормышы белән уртак, үзе яшәгән чорның теләк һәм омтылышларына ятышлы иде...», – дип яза автор.

«Кызыл Татарстан»ның 1946 ел, 6 апрель санында «Татар халык шагыйренең тууына 60 ел тулу алдыннан» рубрикасында «Габдулла Тукай лирикасы» дип аталган Салих Баттал язмасы урын ала, шигырьләренә анализ ясала. 19 апрель санында «Тукай көннәре алдыннан» рубрикасында Минзәлә, Чүриле, Арча районнары һәм В.И. Ленин исемендәге китапханә яңалыклары белән таныштыралар. Шул ук санда газетада фоторәсем дә урнаштырыла. Рәсемдә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе сынчы Садри Ахунның Габдулла Тукай бюстен ясаган вакыты күрсәтелә. Газетаның 24 апрель санында «Тукай көннәре алдыннан» рубрикасында Тымытык, Шөгер, Киров районнарыннан яңалыклар бирелә. Шунда ук Габдулла Тукайның тууына 60 ел тулу көне уңае белән рус һәм татар телендә күп кенә яңа китаплар әзерләнүе хәбәр ителә, аларның кайберләре белән таныштырып та үтәләр. 1946 елның 16 нчы июнь номерында шагыйрьгә багышланган тантаналы җыелыштан хәбәр бирелә һәм шунда ук Казан

дәүләт университеты һәм педагогия институтының әдәбият факультеты студентларына һәм аспирантларына Тукай исемендәге стипендия билгеләү турында хөкүмәт карары урнаштырылган. Ул чакта кайсы студентларга бу премия бирелде икән? Сәнгать кешеләренә Тукай премиясе 1958 елда гына бирелә башлый. Димәк, 1946 елда ук Тукай исемен йөрткән премия булдыру турында уйланганнар. Бу эшнең башында кайсы шәхесләрнең торуын да белү кызыклы булыр иде. Татар тормышында Тукай образы бар, эсәләре бар. Әлеге газета текстларында каләм тотып язучыларны гына түгел, бу темага бөтен халыкның мөнәсәбәтен дә күрергә мөмкин. Югарыда телгә алынган газета өземтәләрендә 1928 елдан башлап 1946 елга кадәр басылган Тукай турындагы текстлар хакында хәбәр ителде. Кыскача гына күзәтү ясалды. Бу вакыт аралыгында Тукайның үлгәненә 30 ел тулу һәм Тукайның тууына 60 ел тулу даталары бар һәм моның белән бәйле яңа материаллар урнаштырыла. Матбугат көндәлек була торган вакыйгаларны теркәп бара. Бу уңайдан тарихи яктан да әһәмияте зур булган мәгълүматлар тупланган.

1947 елның 22 апрель көнендә газетада Тукай әсәрләренең академик басмасының икенче томы әзерләнүе хәбәр ителә. 2 томга Тукайның 1905–1913 кадәр язган әсәрләре кертелүе әйтелә. Бу материаллар үз вакытында «Фикер», «Әлислах», «Йолдыз», «Кояш», «Идел» газеталарында, «Әлгасрелҗәдит», «Уклар», «Яшен», «Ялт-йолт» журналларында һәм аерым җыентыкларда басылган була. «Җыентыкны институтның фәнни сотруднигы иптәш Хисмәтуллин төзеде. Материалларны туплауда М. Гали, Г. Халит, М. Гайнуллин иптәшләр катнашты» дип язылган. Биредә сүз Г. Ибраһимов исемендәге тел һәм әдәбият институты хезмәткәрләренең эшчәнлеге турында бара.

1948 елның 14 апрелендә Габдулла Тукайның үлүенә 35 ел тулу уңае белән Хәсән Хәйринең зур мәкаләсе шагыйрьнең фоторәсеме белән урнаштырылган. Шунда ук Мәхмүт Хөсәеннең «Тукай исән» дип аталган шигыре урын алган. Язучылар Союзында Тукайга багышланган чаралар хакында да мәгълүмат бирелә. «16 апрельдә искә алу кичәсе үткәрелә. Биредә шагыйрьнең иҗаты, тормыш һәм үсеш юлы турында Г. Халит доклады тыңланачак. Докладтан соң татар совет язучылары Г. Тукай турында истәлекләрен, аңа багышланган шигырьләрен һәм башка әсәрләрен укыячак».

«Совет Татарстаны»ның 1951 елгы 27 апрель санында «Габдулла Тукай» дип аталган күләмле язма шагыйрьнең фоторәсеме белән бирелгән. Аны филология фәннәре кандидаты Гали Халит әзерләгән. 1956 елның 26 апрель номеры тулысынча шагыйрь иҗатына багышлана. Р. Башкуровның «Рус әдәбияты һәм Тукай», «Китмибез» һәм «Эш» шигыреннән өзекләр китерелә. Шунда ук Роберт Әхмәтҗановның «Тукайга» дип аталган шигыре урын алган. Ибраһим Нуруллинның «Халык шагыйре» дип аталган күләмле мәкаләсе Тукайның

фоторәсеме белән бирелгән. Бу еллардан соң шагыйрь иҗатына зур урын бирелә башлый.

Шагыйрьнең йөз еллыгы Татарстанда киң масштабта үткәрелә. Бу уңайдан зур чаралар Казанда, Арча районының Яңа Кырлай авылында уза, эчтәлекле конференцияләр оештырыла. Моннан тыш, татар яшәгән һәр җирдә китап бәйрәмнәре, театральләштерелгән тамашалар, әдәби-музыкаль кичә һәм башка чаралар үткәрелә. Нәкъ шул елны Казанда Г. Тукай музее ачылган, Кырлайда мемориаль зона яңартылган. Фәнни даирә, әдипләр эзлекле рәвештә иҗади мирасын өйрәнү, китапларын чыгару мәсьәләләренә багышланган публицистик язмалар тәкъдим иткән. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Шагыйрь үлде... Шагыйрь яши» (5 апрель,1986), Фоат Галимуллинның «Шагыйрьнең иҗтимагый йөзе» (23 апрель, 1986) язмалары әнә шундыйлардан. Газетаның 26 апрель санында Гәрәй Рәхим Тукайның 100 еллыгын бөтен төрки халыклар билгеләп үтүен хәбәр итә. Моңа дәлил итеп ул ЮНЕСКОның «1986–1987 елларда бөек кешеләр һәм тарихи вакыйгаларның еллыкларын бәйрәм итү» календарен китерә. Анда Г. Тукайга 100 яшь тулу да кертелгән. Бу сан тулысынча Г. Тукайга багышланган. Шигъри тәлгәшләр белән беррәттән, Рашат Низамиевның «Давыл алдыннан» дигән документаль әсәреннән өзек, Сибгат Хәкимнең «Тукай нигезләре» публицистик язмасы урын алган.

1996 елда замандаш әдипләр язмаларыннан тыш, «Тукай китабы» дигән рубрика булдырылып, анда Г. Тукай иҗатыннан матур үрнәкләр бирелеп бара. Төрки әдипләр чыгышларына да игътибар бирелә: «Нинди бөек бу Тукай. Бары тик талантлы халык кына поэтик фикерләрнең шундый титанын, кешеләр йөрәгенең шундый гигантын тудыра ала». (Н. Доможаков, хакас шагыйре, 20 апрель, 1996).

2003 елда – Тукайның вафатына 90 ел тулган елны – Тукай музее директоры Мөҗип Низамиев язмасы басылган. Ул беркадәр шагыйрьне кайсы елларда ничек искә алуларына анализ ясый һәм Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев сүзләре белән нәтиҗә ясый: «XX гасырда Тукай белән яшәдек, XXI гасырга аның белән атлап кердек».

2006 елда Татарстанда Әдәбият һәм сәнгать елы игълан ителә. Әлеге нисбәттән дә Тукай иҗатына, аның исемен мәңгеләштерү проблемаларына багышланган язмалар шактый күренә. Проблемалы язмалардан Фоат Хәсәновныкын атап үтәргә була. Ул шагыйрь иҗатын һәм тормыш юлын тирәнрәк өйрәнергә кирәк дигән фикер җиткерә. 2013 елда Тукайның вафатына 100 ел тулу да билгеләп үтелде. Монда Тукай эзләрен барлау («Әйләнечтән юлны ничек турыларга?» Риман Гыйлемханов, 10 апрель, 2013; «Тукай якташлары ничек яши?» Гөлинә Гыймадова, 16 март, 2013), аның маршрутын булдыру кебек проблемалар белән беррәттән, укучылар Тукай премиясенең вакланувы турында да уйлана.

Вакытлы матбугатта Тукай темасы эзлекле рәвештә дәвам

ителә. Газета вакыт белән бергә атлаучы матбугат чарасы ул. Матбугат төпләнмәләреннән халыкның тормышы көзгедәге кебек күренеп тора. Монда чын мәгънәсендә шагыйрьгә карата мөнәсәбәтне билгеләргә була. Тукай шәхесенә караш төрлечә булган. Газетаның кайбер елларында, шул ук сугыш чоры төпләнмәләрендә дә Тукай исеме күренми диярлек. Үзгәртеп кору елларыннан соң, шагыйрьгә карата игътибар арткан. Бу халыкның милли үзаңы уяну белән дә бәйле күренеш була. Соңгы вакытта Тукайга мөнәсәбәтле проблемалы язмалар да шактый күп күренә башлады. Шул ук вакытта вакытлы матбугатта Тукай темасына аның үлеме һәм тууына бәйле түгәрәк даталарда яки туган көннәрендә генә мөрәҗәгать итү ачык күренә. Бу татар милләтенең Тукайга мөнәсәбәтен чагылдыра кебек. Газета һәм журналларда Тукай темасын яктыртучы даими рубрикалар булдырырга кирәк дигән фикер кала. Соңгы вакытта Тукай премиясе алыр вакыт җиткәч кенә Тукай исеме газеталарда пәйда була. Монысы бигрәк тә аяныч. Шуңа да публицистларның бу хакта язган кискен-кискен язмалары газетада басылып чыгуы да урынлы. Шул ук вакытта Язучылар берлегенә кергән өч йөздән артык язучы һәм шагыйрьнең Тукайга багышланган язмалары матбугатта ешрак күренсә, уңай күренеш булыр иде.

«Ватаным Татарстан» газетасының архивын барлаганнан соң, вакытлы матбугатта Тукай темасының аерым урыны бар, дип әйтә алабыз. Татар басмасы Тукайга мөрәҗәгать итмичә кала алмый. Вакыт узган саен, без тарихта калган язмаларның никадәр әһәмиятле икәнен аңлыйбыз. Газетаның тарих елъязмасы язуының әһәмияте дә шунда чагыла. Без тарихта Тукай белән эзлебез. Мәкаләне Гаяз Исхакыйның «Ил» газетасында 1914 елның 29 мартында басылган «Тукай мәктәптә» язмасыннан өзек белән тәмамлыйсы килә. «Тукай һичбер вакыт үлмәенчә – буыннан-буынга күчеп – баладан балага мирас булып калырга тиештер. Тукай, һичбер вакыт безнең күңелебездән чыкмаенча, безнең хәсрәтебез белән кайгырып, безнең шатлыгыбыз белән сөенеп, безнең белән бергә, безнең мәдәниятебез, әдәбиятыбыз белән бергә барырга тиештер». Бер гасыр элек язылган фикерләр бүген дә актуаль булып кала. Матбугат язмаларында Тукайның халык күңелендә кадерле урын алуы һәм киләчәктә дә шулай булачагы исбатланып килә.

**Әдәбият**

*Әһлиуллин М.А., Ризванов Г.Г., Галиева Р.М.* «Ватаным Татарстан». Газетаның 90 еллыгы уңаеннан истәлекләр, документлар, фоторәсемнәр. Казан: Идел-Пресс нәшрияты, 2009. 224 б.

*Мәрдиева М.Б.* Татар журналистикасы тарихы буенча очерклар. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2003. 132 б.

***Галиева Рәсимә Муллаян кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының татар журналистикасы кафедрасы доценты*
*E-mail: grasima@yandex.ru*

УДК 821

***Р.А. Абзалина***

# ТУКАЙНЫҢ ИҖАДИ ВАСЫЯТЕ

В статье приводится перечень произведений Г. Тукая, который он составил лично для сборника, включив туда лишь те произведения, которые сам хотел видеть.

**Ключевые слова:** Г. Тукай, татарская литература начала XX века, сборники произведений Г. Тукая.

Хөрмәтле Тукай һәр татар баласына иптәш тә, дус та, остаз да, киңәшче дә. Ничә еллар һәм буыннар узса да, ул һәрвакыт үз урынында, буй җитмәслек, аңламаслык ераклыкта түгел, бәлки, күз күреме кадәр җирдә янәшә тора, кирәк вакыт кирәк сүзне табып бирә. Баксаң, мин инде хәзер аңа ана тиешле яшьтә икән.

Тукай – чын мәгънәсендә халык шагыйре, аның кимчелекләре дә, дәрәҗәсе дә халыкныкы. Тукай тирәсендә булган ыгы-зыгы сүзләр еллар үтү белән артмый да, кимеми дә. Мирас сакчылары булып эшләп, шушы яшькә җитеп, хөрмәтле шагыйребезнең васыятен җиренә җиткерә ала алмавыбызга – оят. Ул исән чакта, соңгы көннәрендә үзенең иҗатын тикшереп чыга һәм 340 исемнән торган әсәрләрен кертеп, җыентык әзерләп калдыра. Җыентык беренче мәртәбә 1914 елда «Мәгариф» нәшриятында Казанда басылып чыга. Кереш сүзе Җамал Вәлиди тарафыннан язылган. Эчтәлеге хәзерге альбом-җыентыкларны хәтерләтә. Китапны кулга алуга бу җыентыкны туплап чыгарган һәр кешенең ихлас күңел нуры сирпелә: Тукай үзе, дуслары Әхмәтгәрәй Хәсәни, Фатыйх Әмирхан, Җамал Вәлиди, бертуган Шәрәфләр, фотограф Кыям Зөлфәкаров һ.б.

Вакытлар узу белән татар язуы ике мәртәбә алмашып, бабасы язганны әтисе, әтисе язганны баласы аңламаслык дәрәҗәгә килде, Тукай иҗатын укып юанган татар кешесенә шагыйренең укучысына васыять ителгән иҗатының үзе теләгән микъдары һәм вариантында барып ирешкәне булмады. Соңгы елларда чыккан томлыкларның ахырларында бик күп иҗтиһад белән табылган искәрмәләр булса да, Тукайның үзе искәрткән кыйммәтле сүзләре кирилл хәрефләрен генә аңлаган укучыларга мәгълүм түгел.

Мәсәлән, «Яшен яшьнәгәндә» шигыре. Бу шигырьнең искәрмәсендә (Г. Тукай. Сайланма әсәрләр. 5 томда Казан, 1985, II том, 367 бит) «Тукай кулъязмалары арасыннан табылып, беренче тапкыр «Яңалиф» басмасының 2 нче томында (1929) басылган» дип язылган. Шигырьнең оригиналы шагыйрь тарафыннан 1911 ел 26 июньдә язылган һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел,

әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Тукай фондында саклана. Шул ук томда, 181 биттә, шигырьнең үзе, кульъязмасының фотосурәте урнаштырылган.

Тукай үзе исән чакта шигырь беркая да басылмаган булып чыга. Шигырьнең исеме астында кульъязмада автор үзе «Исерек вакытымда язылган» дип язып куйган, димәк, аннан тәүбә иткән, ваз кичкән.

Габдулла Тукай үзе әзерләгән 340 әсәрен «Җитди шигырьләр», «Көлке вә җөһү», «Балалар кыйсеме», «Нәсер кыйсеме» дигән өлешләргә бүлгән. Шунысына игътибар итәсе килә: «Шүрәле» поэмасы балалар кыйсеменә түгел, җитди шигырьләр бүлекчәсенә кертелгән.

«Мәҗмугаи әсәр»нең 1913 елгы басмасында әсәрләр түбәндәге тәртип белән урнаштырылган.

| Җитди шигырьләр | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | «Бер татар шигыйренең сүзләре» – 1907 | 25. | «Булмаса…» – 1909 |
| | | 26. | «К…, …гә» – 1908 |
| 2. | «Утырышу» – 1907 | 27. | «Көз» – 1907 |
| 3 | «Гашыйк» – 1909 | 28. | «Яшьләр» – 1910 |
| 4. | «Ишек бавы» – 1907 | 29. | «Кайчакта» – 1910 |
| 5. | «Туган җиремә» – 1907 | 30. | «Нәсихәт» – 1910 |
| 6. | «Пар ат» – 1907 | 31. | «Миһраҗ» – 1910 |
| 7. | «Авыл хатынының бала тирбәткәндәге өмедләре» – 1907 | 32. | «Өзелгән өмет» – 1910 |
| | | 33. | «Хур кызына» – 1906 |
| 8. | «Бүген бәйрәм» – 1907 | 34. | «Шиллердән» – 1907 |
| 9. | «Бәйрәм һәм сабыйлык вакыты» – 1908, гыйнвар | 35. | «Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә? – 1906 |
| 10. | «Чын һәм ялган» – 27 апрель 1908 | 36. | «Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма» – 1907 |
| 11. | «Таэссер» – 21.01.1908 | 37. | «Алтынга каршы» – 1907 |
| 12. | «Васиятем» – 1909 | 38. | Мөритләр каберстанынннан бер аваз» – 1906 |
| 13. | «Күңел» – 1907 | | |
| 14. | «Вакыт гаҗизем» (Күңел дәфтәреннән) | 39. | «Иттифакъ хакында – 1905 |
| | | 40. | «Тавыш»хакында» – 1907 |
| 15. | «Тәрәддөд вә шөбһә» – 1909 | 41. | «Мәхбус» – 1907 |
| 16. | «Сөбханалла, сөбханалла!» | 42. | «Театр» – 1907 |
| 17. | «Милләтчеләр» – 1908 | 43. | «Шагыйрьгә» – 1907 |
| 18. | «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» – 1908 | 44. | «Күк сыер» – 27 июль 1908 |
| | | 45. | «Пәйгамбәр» – 1909 |
| 19. | «Тормыш» – 13 июль 1908 | 46. | «Исемдә» – 1909 |
| 20. | «Киңәш» – 15 сентябрь 1908 | 47 | «Газаптан соң» – 1910 |
| 21. | «Мәхәббәт» – 30 сентябрь 1908 | 48. | «Бишектәге бала» – 1907 |
| 22. | «Алдандым» – 10 июнь 1908 | 49. | «Җәйге таң хатирәсе» – 1910 |
| 23. | «Яратырга ярый – 13 июль 1908 | 50. | «Япон хикәясе» – 1909 |
| | | 51. | «Катыйль нәфескә» – 1910 |
| 24. | «Форьяд» – 1908 | 52 | «Вәгазь» – 17 декабрь 1907 |

| | |
|---|---|
| 53. | «Кемнән ярдәм эзләргә?» – 6 август 1908 |
| 54. | «Өмид» – 2 июль 1908 |
| 55. | «Шатлык вә хәсрәт» – 23 сентябрь 1908 |
| 56. | «Шагыйрь» – 17 март 1908 |
| 57. | «Кызык гыйшык» – 17 июль 1908 |
| 58. | «Бер рәсемгә» – 8 сентябрь 1908 |
| 59. | «Соңра» – 1908 |
| 60. | «Яшен»журналы хакында» – 1908 |
| 61. | «Вак-өяк» – 1908 |
| 62. | «Шекспирдан» – 1908 |
| 63. | «Төрекчәдән» – 1908 |
| 64 | «Эштән чыгарылган татар кызына» – 1909 |
| 65. | «Төрекчәдән» – 1909 |
| 66. | «Янә» – 1908 |
| 67. | «Төлке һәм Йөзем җимеше» – 1908 |
| 68. | «Кисекбаш»ка гыйлавә» – 1908 |
| 69. | «Сәрләүхәсез» – 1909 |
| 70. | «Теләү бетте» – 1909 |
| 71. | «Ачы тәҗрибә авазы» – 1910 |
| 72. | «Үкенеч» – 1910 |
| 73. | «Китап» – 1909 |
| 74 | «Киңәш» – 1909 |
| 75. | «Күңел йолдызы» – 1909 |
| 76 | «…га («И матур! иренмиче…»)»– 1907 |
| 77. | «Сөткә төшкән тычкан» – 1907 |
| 78. | «Байроннан» – 1907 |
| 79. | «Гыйлавә» – 1907 |
| 80. | «Ислахчыларга» – 1907 |
| 81. | «Охшату» – 1907 |
| 82. | «Үз-үземә» – 1906 |
| 83 | «Кемне сөергә кирәк?» – 1906 |
| 84. | «Үпкә» – 1908 |
| 85. | «Теләнче» – 1907 |
| 86. | «Мужик йокысы» – 1905 |
| 87. | «Мөхәммәдия»дән – 1908 |
| 88. | «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» – 1907 |
| 89. | «Яшь бала» – 1908 |
| 90. | «Шекспирдан» – 1909 |

| | |
|---|---|
| 91. | «Төркиядән» – 1911 |
| 92. | «…га» («Шома тормыш юлында…» – 1911 |
| 93. | «Төш» – 1910 |
| 94. | «Татар мөхәрриренә» – 1910 |
| 95. | «Сакмар суы» көенә» – 1911 |
| 96. | «Актык тамчы яшь – 1910 |
| 97. | «Мөбәрәк тәсбих өзелде» – 1910 |
| 98. | «Толугышшәмси мин мәгърибиһа» – 1912 |
| 99. | «Тәләһһеф» – 1912 |
| 100. | «Егетләр» – 1912 |
| 101. | «Читен хәл» – 1912 |
| 102. | «Бала оҗмахта» – 1912 |
| 103. | «Дошманнар» – 1912 |
| 104. | «Зур җаным» – 1912 |
| 105. | «Кичке теләк» – 1912 |
| 106. | «Ваксынмыйм» – 1912 |
| 107. | «Гөнаһ» – 1911 |
| 108. | «Сагыныр вакытлар» – 1912 |
| 109. | «Гакыллылар фәлсәфәсе» – 1911 |
| 110. | «Кадер кич» – 1911 |
| 111. | «Тәүбә вә истигъфар» – 1911 |
| 112. | «Картлар» – 1912 |
| 113. | «Толстой фикере» – 1911 |
| 114. | «Үземнән гыйлавә» – 1911 |
| 115. | «Көзге җилләр» – 1911 |
| 116. | «Буран» – 1912 |
| 117. | «Көтмәгәндә» – 1912 |
| 118. | «Көлке түгел» – 1912 |
| 119. | «Әхлаксызлык» – 1912 |
| 120. | «Монафикъка» – 1912 |
| 121. | «Ни кирәк тагы?» (Экспромт) – 1912 |
| 122. | «Интикадка мөтәгалликъ» – 1912 |
| 123. | «Мәхәббәт шәрхе» – 1912 |
| 124. | «Казан вә Кабан арты» – 1912 |
| 125. | «Татар яшьләре» – 1912 |
| 126. | «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» – 1912 |
| 127. | «Янә бер хатирәм» – 1912 |
| 128. | «Казан вә Казан арты» – 1912 |
| 129. | «Авыл мәдрәсәсе» – 1912 |
| 130. | «Дин вә гавам» – 1912 |
| 131. | «Мәҗлес» – 1910 |

| | |
|---|---|
| 132. | «Җил тавышы» – 1912 |
| 133. | «Тәмсил» – 1911 |
| 134. | «Өч хәкыйкать» – 1912 |
| 135. | «Бер кайгы көнендә» – 1908 |
| 136. | «Аң» – 15 декабрь 1912 |
| 137. | «Хәстә хәле» – 12 гыйнвар 1913 |
| 138. | «Шиһаб хәзрәт» – 1 гыйнвар 1913 |
| 139. | «Даһигә» – 1913 |
| 140. | «Толстой сүзе» – 1913 |
| 141. | «Шөһрәт» – 1 март 1913 |
| 142. | «Кыйтга» – 1 март 1913 |
| 143. | «Тәфсирме? Тәрҗемәме?» – 4 март 1913 |
| 144. | «Мөхәрриргә» – 10 март 1913 |
| 145. | «Толстой сүзе» – 4 март 1913 |
| 146. | «Толстой сүзләре» – 4 март 1913 |
| 147. | «Буш вакыт» – 1913 |
| 148. | «Мәктәп» – 28 март 1913 |
| 149. | «Бисмилләхир-рахмани рахим. Аллаһ Тәбаракә вә Тагалә» – 1909 |
| 150. | «Ана догасы» – 1909 |
| 151. | «Туган тел» – 1909 |
| 152. | «Бабай» – 1909 |
| 153. | «Уянмас йокы» – 1909 |
| 154. | «Ай һәм Кояш» – 1909 |
| 155. | «Җир йокысы» – 1909 |
| 156. | «Кышка бер сүз» – 1909 |
| 157. | «Кошларга» – 1909 |
| 158. | «Сабыйга» – 1909 |
| 159. | «Карлыгач» – 1909 |
| 160. | «Кышкы кич» – 1909 |
| 161. | «Кошчык» – 1909 |
| 162. | «Бишек җыруы» – 1909 |
| 163. | «Бәхетле бала» – 1909 |
| 164. | «Яхшы җырлар» – 1909 |
| 165. | «Бала белән Күбәләк» – 1909 |
| 166. | «Мәктәптә» – 1909 |
| 167. | «Эш беткәч уйнарга ярый» – 1909 |
| 168. | «Арба, Чана, Ат» – 1909 |
| 169. | «Кярханәдә» – 1909 |
| 170. | «Кәҗә белән Сарык хикәясе» – 1909 |

| | |
|---|---|
| 171. | «Мияубикә» – 1909 |
| 172. | «Сабыйлар җыруы» – 1909 |
| 173. | «Яңгыр» – 1909 |
| 174. | «Эш» – 1909 |
| 175. | «Туган авыл» – 1909 |
| 176. | «Чыршы» – 1909 |
| 177. | «Яңгыр илә Кояш» – 1909 |
| 178. | «Гомер юлына керүчеләргә» – 1909 |
| 179. | «Җәй көнендә» – 1910 |
| 180. | «Күгәрчен» – 1910 |
| 181. | «Иссез чәчәк» – 1910 |
| 182. | «Баскыч» – 1910 |
| 183. | «Яз хәбәре» – 1910 |
| 184. | «Карга» – 1911 |
| 185. | «Җил» – 1911 |
| 186. | «Эшкә өндәү» – 1911 |
| 187. | «Иртә» – 1911 |
| 188. | «Елның дүрт фасылы» – 1910 |
| 189. | «Ана белән бала» – 1910 |
| 190. | «Халык моңнары» – 1909 |
| 191 | «Сак-сок»бәете» – 1909 |
| 192. | «Су анасы» – 1908 |
| 193. | «Таз» – 1908 |
| 194. | «Ата илә Бала» – 1908 |
| 195. | «Тургайлар. Ашыйбыз» – 1909 |
| 196. | «Имтияз алган бала» – 1910 |
| 197. | «Һәр ялтыраган алтын түгел» – 1910 |
| 198. | «Безнең гаилә» – 1910 |
| 199. | «Гали белән Кәҗә» – 1910 |
| 200. | «Ялкау Маэмай» – 1910 |
| 201. | «Кичә һәм бүген» – 1910 |
| 202. | «Һәркемнең ашыйсы килә» – 1910 |
| 203. | «Шаян Песи» – 1910 |
| 204. | «Фатыйма белән Сандугач» – 1910 |
| 205. | «Ак Бабай» – 1910 |
| 206. | «Кызыклы Шәкерт» – 1910 |
| 207. | «Бичара Куян» – 1910 |
| 208. | «Чылбырдагы әт» – 1909 |
| 209. | «Шүрәле» – 1907 |
| 210. | «Хатыннар хөррияте» – 1909 |
| 211. | «Бер шәехнең» – 1909 |
| 212. | «Яз галәмәтләре» – 1909 |
| 213. | «Бер мәнигъ тәрәккыйгә» – 1909 |

| | |
|---|---|
| 214. | «Бер газета идарәсе хәленнән» – 1909 |
| 215. | «Саташкан» – 1909 |
| 216. | «Улмы? Ул» – 1909 |
| 217. | «Егет илән кыз» – 1909 |
| 218. | «Мөхәммәдиядән» – 1909 |
| 219. | «Тешләре ямсу матурга» – 1909 |
| 220. | «Урланган мәгънә» – 1909 |
| 221. | «Печән базары яки яңа Кисекбаш» – 1909 |
| 222. | «Безне урынсызга ямсилыйлар» – 1909 |
| 223. | «Вөждан хәсрәте» – 1909 |
| 224. | «Әнә-менә» – 1909 |
| 225. | «Минһаж» – 1909 |
| 226. | «Ике юл» – 1909 |
| 227. | «Номерга төшкән искеләр» – 1909 |
| 228. | «Ысулы кадимче» – 1909 |
| 229. | «Ишан» – 1909 |
| 230. | «Бәгъзе зыялыларымыз» – 1909 |
| 231. | «Хәзерге өйләнүчеләр» – 1909 |
| 232. | «Күрсәтә» – 1909 |
| 233. | «Ике иптәш арасында» – 1910 |
| 234. | «Хасият» – 1910 |
| 235. | «Танса» – 1910 |
| 236. | «Могъҗиза» – 1909 |
| 237. | «Өйләнү – түгел сөйләнү» – 1910 |
| 238. | «Авылда авырып яту» – 1912 |
| 239. | «Бәрәңге вә гыйлем» – 1912 |
| 240. | «Пушкин вә мин» – 1912 |
| 241. | «Мөнтәкыйд» – 1912 |
| 242. | «Йолдыз»дан да курка» – 1912 |
| 243. | «Рамазан гаетендә Иблиснең шайтаннарга хитабы» – 1911 |
| 244. | «Борын» – 1911 |
| 245. | «Тотса мәскәүләр якаң?» – 1912 |
| 246. | «Кайда? Кем?» – 1910 |
| 247. | «Граммофонда татар җырлары» – 1910 |
| 248. | «Гаилә тынычлыгы» – 1909 |
| 249. | «Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә» – 1909 |
| 250. | «Сибгатуллин» – 1910 |
| 251. | «Зур бәшарәт!» – 1910 |
| 252. | «Авыл җырлары» – 1910 |
| 253. | «Озын көйгә бер җыр» – 1912 |
| 254. | «Төрекчәдән» – 1912 |
| 255. | «Өч хакыйкать» – 1912 |
| 256. | «Көйле нәрсә» |
| | Балалар кыйсеме |
| 257 | «Бисмилләһир рахмән и рахим. Аллаһү Тәбаракә вә Тәгалә (Таян Аллаһка)» – 1909 |
| 258 | «Ана догасы» – 1909 |
| 259 | «Туган теле» – 1909 |
| 260 | «Бабай» – 1909 |
| 261 | «Уянмас йокы» – 1909 |
| 262 | «Ай белән кояш» – 1909 |
| 263 | «Җир йокысы» – 1909 |
| 264 | «Кышка бер сүз» – 1909 |
| 265 | «Кошларга» – 1909 |
| 266 | «Сабыйга» – 1909 |
| 267 | «Карлыгач» – 1909 |
| 268 | «Кышкы кич– 1909» |
| 269 | «Кошчык» – 1909 |
| 270 | «Бишек җыруы» – 1909 |
| 271 | «Бәхетле бала» |
| 272 | «Яхшы хәбәрләр» – 1909 |
| 273 | «Бала белән күбәләк» – 1909 |
| 274 | «Мәктәптә» – 1909 |
| 275 | «Эш беткәч уйнарга ярый» – 1909 |
| 276 | «Арба, чана, ат» – 1909 |
| 277 | «Кярханәдә» – 1909 |
| 278 | «Кәҗә белән сарык хикәясе» – 1909 |
| 279 | «Мияубикә» – 1909 |
| 280 | «Сабыйлар быруы» – 1909 |
| 281 | «Яңгыр» – 1909 |
| 282 | «Эш» |
| 283 | «Туган авыл» – 1909 |
| 284 | «Чыршы» – 1909 |
| 285 | «Яңгыр илә Кояш» – 1909 |
| 286 | «Гомер юлына керүчеләр» – 1909 |
| 287 | «Җәй көнендә» – 1909 |
| 288 | «Күгәрчен» – 1909 русчада |
| 289 | «Иссез чәчәк» – 1909 |
| 290 | «Баскыч» – 1909 |
| 291 | «Яз хәбәре» – 1909 |
| 292 | «Карга» – 1909 |
| 293 | «Җил» – 1909 |

| | |
|---|---|
| 294 | «Эшкә өндәү» – 1909 |
| 295 | «Иртә» |
| 296 | «Елның дүрт фасылы» |
| 297 | «Ана илә бала» |
| 298 | «Халык моңлары» (Шагыйрьнең үзе интиҗап итеп җыйган халык моңнары) |
| 299 | «Озык көйләргә» |
| 300 | «Пешми калган җырларның нәмүнәләре» |
| 301 | «Ярты гыналар» |
| 302 | «Ристоннар җыруы» |
| 303 | «Сак-сок бәете» |
| 304 | «Бәетләр» |
| 305 | «Су анасы» |
| 306 | «Таз» |
| 307 | «Ата илән бала» |
| 308 | «Яхшы Җырлар» |
| 309 | «Гали белән кәҗә» |
| 310 | «Ялкау маэмай» |
| 311 | «Кичә һәм бүген» |
| 312 | «Һәркемнең ашыйсы килә» |
| 313 | «Шаян песи» |
| 314 | «Фатыйма белән сандугач» |
| 315 | «Ак бабай» |
| 316 | «Кызыклы шәкерт» |
| 317 | «Бичара куян» |
| 318 | «Чылбырдагы эт» |
| Нәсер кыйсеме | |
| 319 | «Мөкаддимә» |
| 320 | «Исемдә калганнар» |
| 321 | «Язучыдан» |
| 322 | «Игтидар» |
| 323 | «Тәфкиле көе» |
| 324 | «Ашказар көе» |
| 325 | «Сак-сок көе» |
| 326 | «Кәсимский Ибрай» |
| 327 | «Җизнәкәй» |
| 328 | «Башмак көе» |
| 329 | «Халык әдәбияты» |
| 330 | «Хәтимә» |
| 331 | «Бер лыгырдау» |
| 332 | «Төрлегә дөнья тону» |
| 333 | «Гашыйк уты» |
| 334 | «Көйле нәрсә» |
| 335 | «Милләтче» |
| 336 | «Милләт» |
| 337 | «Ахыркүрешүләр» |
| 338 | «Актык сүзләр» |
| 339 | «Бозау кадәрле зур фәлсәфә» |
| 340 | «Исемнәребез хакында» |

Габдулла Тукай – халык шагыйре. Аның иҗатында безнең халыкның бар холкы чагылыш тапкан. Иҗаты безне кешегә таныту өчен түгел, үзебезне-үзебезгә тану өчен, үзебезне төрле чирләрдән тәрбияләү, дәвалау өчен бик мөһим.

Тукай шигырьләрен гакыйл кеше («акыллы» башка мәгънәдәрәк килеп чыга) кайчан укыса, үзенә шул вакытта кирәк хикмәтен таба.

Юкка гына илдән чыгып читкә киткән мөһаҗирләр бу мәҗмуганы үзләре белән алмаганнар, хәтта 1933 елда Токиода «Матбагаи исламиядә» яңадан гарәп хәрефләре белән татарча бастырып, бөтен дөньяга таратканнар. Татарстан милли музеенда шундый берничә экземпляр саклана. Аның берсен Казанда Тукай музее ачылганда Америкадан кайткан Салих һәм Шәмсия Апакайлар музейның беренче директоры Госман Әкрам улы Хәбибуллинга тапшырып калдырганнар. «Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның йөз еллыгы уңае белән Казандагы Г. Тукай музеенә һәдия. Музей эшендә зур уңышлар теләп, бөек шагыйребезгә тирән ихтирам, ярату хисләре белән Салих һәм Шәмсия Апакайлар. Сан-Франциско шәһәре, Калифорния, Америка, 11 июнь, 1986» (ТР Милли музее, кт № 20687-1).

Титул битендә уң якта өстә китапның Салих һәм Шәмсия Апакайларга кадәрге хуҗасы «И.А. Деушев 30.IV.1933 гг. Харбин» дип русча язып куйган.

1913 елда «Уянгач беренче эшем» мәкаләсендә 27 яше тулыр-тулмас Габдулла Тукай үзенең иҗади мирасына түбәндәгечә бәя бирә:

«Ярты төш Мисалендә үтеп киткән 7 сәнәлек бер мөддәт эчендә минем тарафтан шактый гына мәнзумат язылып ташланган. Ул мәнзумат, вак-вак диваннарга тәдвин ителеп, төрек-татар галәменең һәр ягына таралган. Гәрчә һичбер диванның басылу саны икедән артмаган булса да, алар шактый вә хәтта күп таралган, һәр тарафта: «Бер казакъта гына түгел, бездә дә бер оста такмакчы булды», – дип, минем такмаклар мисал итеп күрсәтелгән. Шулай булган. Заман кичкән. Сулар аккан...

Менә Алла юл ачты, «бүлмә» себерергә бушадым. Себереп тә чыгардым. Әй, җир йөзендәге төрек баласы, галимме син, хәкимме син, падишаһмы син, теләнчеме син, инде мин сине өемә кертергә оялмыйм, инде син кем булсаң да, мин сиңа такмак китабымны мәгаль ифтихар һәдия итә алам.

Әле күптәнме, берәү диваннарымның берсен кесәсеннән чыгарса, калтырый идем. Кешеләр алдында укып җибәрсәләр, бүркемне дә кимичә, урамга кача идем. Җаннан кадерле кешемне, шул такмакларымны сораса, мәхрүм итәргә мәҗбүр була идем. Фәиннә мәгаль госри йөсра.

Тиз арада үзем браковать итмәгән вә үзем яраткан шигырьләрдән җыеп, 400 сәхифәле зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга чыгарырга карар бирдем.

Валлаһел муаффикъ».

Гомумән, бу җыентыкның һәр сүзе шагыйрьнең үз мирасыннан халкына җиткерәсе килгән редакциясе. Безнең буын шушы васияти редакцион вариантны алдагы буыннарга кирилл хәрефләре белән татарча һәм сүзен-сүзгә рус, инглиз телләренә тәрҗемә ясап, китаплар итеп, бастырып таратсын иде.

***Абзалина Рәмзия Әсрар кызы,***
*Татарстан Республикасы Милли музее өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*И.Г. Закирова*

## ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫНЫҢ УРМАНЧЕ МӘКТӘБЕ

Статья приурочена к 80-летию доктора филологических наук фольклориста Ф. Урманчеева. Обозначены основные вехи творческой и научно-организационной деятельности выдающегося ученого.

**Ключевые слова:** Ф. Урманчеев, татарская фольклористика, Казанская школа фольклористов, изучение татарского эпоса.

Хәзерге вакытта Россия фольклорчылары телендә «Казан фольклор мәктәбе» дигән төшенчә әйләнешкә кереп килә. Бу фольклор фәнендә Фатих Урманчеев мәктәбе дигән сүз.

Татар фольклор фәнен дөнья фәне югарылыгына күтәргән Фатих Ибраһим улы Урманчеев 1936 елда Омск өлкәсенең Азов районы Кызыл Маяк авылында туа. Булачак галим татар фольклоры белән Омск педагогия институтында укыганда кызыксына башлый, анда укыган елларында халык авыз иҗатын өйрәнү түгәрәгенең старостасы була. Әнисенең мөнәҗәтләр укуын, авылдашларының җыр-әкиятләрен тыңлап үскән студент егет татар фольклорының серләрен аңларга омтыла. Фатих Урманчеевның ерак Себердәге эшчәнлеге турында Казан галимнәренә дә хәбәр ирешеп, аны Казанга, аспирантурага укырга чакыралар. Ул 1962 елда Казанга килеп, Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор бүлегенә аспирантурага керә һәм 1968 елда Хәмит Ярми җитәкчелегендә «Совет чоры татар халык иҗаты жанрларының үсеш юллары» дигән темага диссертация яклый. Шул еллардан Фатих Урманчеевның фән дөньясында эшчәнлеге башлана. Дөрес, яңадан Институтка әйләнеп кайтканчы, күп еллар Алабуга педагогика институтында проректор вазифасын башкара, 1980–1984 елларда Венгриянең Эгер шәһәрендә студентларга рус әдәбияты курсыннан лекцияләр укый.

Фатих Ибраһимович, 1989 елда Ташкент шәһәрендә татар халык бәетләренә багышланган докторлык диссертациясен уңышлы яклап, филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә ала.

Ф.И. Урманчеев 1992 елда Институтка кире әйләнеп кайта. Ул вакытта фольклористикада үзенең сүзен әйткән, күп санлы мәкаләләре, саллы монографияләре белән татар фольклорын дөнья аренасына чыгарган галим булып җитешә. Галим татар фольклористикасы тарихында беренче булып дастан жанрын өйрәнә башлый. «Ак Күбек», «Җир Төшлек», «Түләк», «Алпамыш», «Җик Мәргән», «Кузы Көрпәч һәм Баян-Сылу», «Алтаин Саин Сүмә» һәм башка дастаннарны тикшерүгә багышланган күп

санлы фәнни мәкаләләр «Советская тюркология», «Советская этнография» журналларында басылып чыга. Алабугада эшләгән вакытында татар халкының эпосын тикшерүгә багышланган «Героический эпос татарского народа» дигән монографиясен тәмамлый. Венгриягә киткәнче үк бу хезмәтен нәшриятка тапшыра. Монография 1984 елда 3300 тираж белән басылып чыгып ул татар фольклорчыларының гына түгел, азәрбайҗан, кыргыз, казакъ, үзбәк, нугай һәм башка халык галимнәренең дә өстәл китабына әйләнә. Төрле өлкәләрдән Казанга килгән галимнәр беренче эш итеп шул китапны үзендә булдырырга омтыла. Чыккан елында ук раритетка әйләнгән бу хезмәт хәзерге көнгә кадәр фәнни кыйммәтен югалтмый. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, галимнең соңрак чыккан хезмәтләрен дә шул ук язмыш көтә.

1992 елның 1 сентябреннән Фатих Урманчеев бүлек мөдире вазифаларын башкарырга алына. Галим бүлектә эшләгән галимнәргә югары бәя биреп һәм ул вакытта алда торган бурычлар-максатларны искә алып, «Мәсьәләнең иң җитдие – күп еллар буена төзелеп һәм ныгытылып килгән ышанычлы нигез булуда иде. Шул 90 нчы еллар башында бүлек алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе – фәнни кадрлар мәсьәләсе булып чыкты. Чөнки бүлек шактый “олыгайган”. Анда – нибары өч фән кандидаты, бер генә аспирант та, бер генә фән докторы да юк... Чын күңелдән эшкә керешкәч, мәсьәләнең бу ягы да шактый тиз хәл ителде: чөнки элек-электән бүлекнең фәнни потенциалы бик нык һәм зур иде», – ди.

Әйтергә кирәк, теоретик яктан гаять әзерлекле, киң эрудицияле, шул ук вакытта кешелекле Фатих Ибраһимовичның бүлек җитәкчесе вазифаларын башкарырга алынуы бик урынлы була. Хәмит Ярминең традицияләрен дәвам итеп классик фольклор фәненә хезмәт иткән галим Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеген бүгенге көндә «Казан фольклор мәктәбе» дип атала торган бүлек дәрәҗәсенә күтәрә.

Ф.И. Урманчеев бүлек җитәкчесе буларак эшчәнлеген фәнни кадрлар әзерләүдән башлап җибәрә. Бу урында Урманчеевның, беренче чиратта, хөсетлекнең нәрсә булуын белмәүче кеше булуын әйтеп китү урынлы булыр. Чөнки бүлектә әзер диссертацияләр булып та, аларны тикшерүгә кую берничә елга чигерелә бару күренеше булган. Ф.И. Урманчеев тиз арада әзер диссертацияләр белән танышып, аларны бүлектә тикшерүгә чыгара, ярты юлда калган эшләрне өйрәнеп, алга таба ничек дәвам итәргә киңәшләр бирә, кайбер диссертацияләрне редакцияләп чыга. Бүлектә эшләүче галимнәр кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен тәмамлап якларга чыга. Берничә ел эчендә фольклористика белгечлеге буенча Хуҗиәхмәт Мәхмүтов докторлык, Айсылу Садыйкова, Рәшит Ягъфәров, Ленар Җамалетдинов кандидатлык диссертацияләре яклый. Шул рәвешле бүлек

фәнни яктан әзерлекле, җитлеккән галимнәр белән ныгый бара.

Шушы вакытта халык иҗаты бүлеге «Татар халкының этник тарихы» дигән темага фәнни эшчәнлеген башлап җибәрә. Һәр галим татар фольклорының аерым бер теоретик мәсьәләсен өйрәнә башлый.

Ф.И. Урманчеев халык иҗаты бүлегенә аспирантлар кабул итүне торгыза. Бүлек өчен дә, югары уку йортлары өчен дә кадрлар әзерләү дә шушы ук елларда башланып китә. Бу эшнең нәтиҗәсе дә озак көттерми. Халык иҗаты бүлегендә беренчеләрдән булып аспирантура узып К.М. Миңнуллин 1996 елда «Татар поэзиясендә җыр жанры», Л.Ә. Кариева 2000 елда «Татар мифологиясе: тарихи-чагыштырма һәм типологик аспектта» дигән темаларга кандидатлык диссертацияләре яклыйлар. Башка регионнарда яшәгән галимнәр белән дә хезмәттәшлек башлана. Бүлектә Төмәннән килеп В.И. Хәйруллина аспирантура уза һәм 1999 елда «Идегәй» эпосы һәм аның тарихи нигезләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

1995 елдан бүлеккә аспирантлар кабул итү планлы рәвештә алып барыла башлый. Ел саен баштарак бер, соңрак елга 4–5 кешегә кадәр яңа аспирантлар кабул ителә. Бүлектә диссертация язып, эшләрен тәмамлаган яшь галимнәр яклауга чыга.

Шушы елларда Ф.И. Урманчеев, бүлекнең өлкәнәя баруына борчылып, аны яшь кадрлар белән ныгыту эшен дә алып бара. Бүлеккә эшкә, 1998 елда Ф.И. Урманчеев җитәкчелегендә диссертацияләрен тәмамлап, Илсөяр Закирова һәм Лилия Мөхәммәтҗанова килеп кушыла, 2000 елда Марат Садыйков эшли башлый. Фәнни җитәкче үзенең шәкертләренә остаз булып калып, алга таба да аларга докторлык диссертацияләре өчен темалар сайларга ярдәм итә. Һәр катлаулы фәнни проблеманы чишүдә булыша, яшь галимнәргә фән дөньясына фатихасын бирә.

Аның җитәкчелегендә дистәләгән кеше кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклый, фәнгә җитлеккән белгечләр әзерләнә.

Фатих Урманчеев үзе берничә фәнни юнәлештә эшли. Бу – татар һәм гомумән төрки эпосны фәнни яктан тикшерү һәм анализлау, татар мифларын беренчеләрдән булып тикшерү, әдәбият белән фольклор бәйләнешләрен өйрәнү.

Ф.И. Урманчеевның татар эпосына багышланган «По следам белого волка» (1994), «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» (1997), «Народный эпос «Идегей» (1999) дигән монографияләре дә дөнья күрде. 2002 елда «Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек» дигән хезмәте басылып, вакытлы матбугат битләрендә югары бәя алды. Берничә елдан бу дәреслек белән эшләр өчен төзелгән хрестоматия да басылып чыга.

Фатих Урманчеевның соңгы елларда нәшер ителгән зур хезмәте янәдән бер тапкыр татар фольклорчыларының фәндә беренчеләрдән булуын исбатлый. Галимнең өч томлык «Татар

мифологиясе» дигән энциклопедик характердагы хезмәтендә татар эпосының аерым сюжетлары, мотивлары, эпик геройлар турында бай мәгълүмат бирелә (2008, 2009, 2011). Бу хезмәт күпчелек төрки халыклар өчен янәдән өстәл китабына әйләнде. Хәзерге вакытта ул рус телендә басмага әзерләнә.

Алдарак әйтелгәнчә, Фатих Урманчеев җитәкче булып килү белән бүлек төп игътибарын татар халык иҗатын теоретик яктан өйрәнүгә юнәлтә. Бу елларда бүлек хезмәткәрләре зур һәм әлегә кадәр өйрәнелмәгән теоретик мәсьәләләрне тикшерүгә хезмәт куя.

2015 елда Ф.И. Урманчеевның «Тюркский героический эпос» дигән монографиясе дөнья күрде. Хезмәттә төрки эпос, сюжетны тәшкил иткән төп мотивлар анализлана. Яңа гына басылып чыккан хезмәткә тиешле бәя биргән рецензияләр әле булыр дип уйлыйбыз. Әлбәттә, гаять катлаулы бу монография шактый тар даирәне – бары әзерлекле галимнәрне күздә тотып эшләнгән. Татар фәненең бу дәрәҗәгә чыгуы безнең өчен горурлык хисе тудыра. Афәрин, Остазым!

**Ф.И. Урманчеевның басылып чыккан монографияләре:**


Халык авазы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

Эпические сказания татарского народа. – Казань: Изд. Казан ун-та, 1980.

Героический эпос татарского народа. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984.

Дастаннарга лаек замана. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.

По следам белого волка. – Казань: Изд-во ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1994.

Волшебный клубок. Муса Джалиль и народное творчество. – Казань: Изд-во ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1995.

Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.

Народный эпос «Идегей». – Казань: Фэн, 1999.

Лиро-эпос татар Среднего Поволжья. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002.

Татар халык иҗаты. Дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. Икенче басмасы – 2005.

Татар халык иҗаты. Хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2004.

Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. – Казан: Мәктәп, 2002.

Роберт Миңнуллин: Шигъри осталык серләре. – Казан: Мәгариф, 2005.

Каһарманнар йолдызлыгы. Тарихи-фольклористик очерклар. – Казан: Матбугат йорты, 2006.

Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. – Казан: Мәгариф, 2008, 2009, 2011.

Тюркский героический эпос. – Казань: ИЯЛИ, 2015.



***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ХАЛЫК ҖӘҮҺӘРЛӘРЕННӘН ЯКТЫ АЛЫП...

## (Күренекле тюрколог, фольклорчы галим Фатих Урманчега – 80 яшь)

Статья приурочена к 80-летию доктора филологических наук фольклориста Ф. Урманчеева. Обозначены основные страницы биографии, вехи творческой и научно-организационной деятельности выдающегося ученого.

**Ключевые слова:** Ф. Урманчеев, татарская фольклористика, Казанская школа фольклористов, изучение татарского эпоса.

Татар фәнендә чал тарихның үзе кебек үк борынгы, бай, четерекле, тирән һәм тәэсирле, бүгенгенең рухи тамырларын тәшкил иткән, «халык иҗаты» дип аталган гаҗәеп мәгънәле бер өлкә барлыгы мәгълүм. Төбендә энҗе-мәрҗәннәр тулы мул сулы дәрья белән дә чагыштыралар аны. Дәрьяның мең гасырлардан ук килүче чишмә башы кайда, ул үз ташкынына нинди генә эреле-ваклы елгаларны иярткән дә, үзгәрешләрнең ниндиен кичергән, кай тарафларны урап, кайсы гына диңгез-океанга ни сәбәпле барып кушылган, дәрья узган юлның бәрәкәтле туфрагында нинди асыл гөлләр шыткан, кайсы агач нинди уңыш биргән? Халкыбызның шушы гаять үзенчәлекле җәүһәрләре бүгенге фән-техника казанышлары чорында да игътибарны җәлеп итә, ихтыярсыз сокландыра, үткәнебез өчен горурлык тудыра, киләчәккә өмет кабыза икән, димәк, фәннең әлеге тармагында талантлы галимнәребез шактый күп көч куйган. Халкыбыз мирасының тарих тузанына күмелеп калмавына да, тиешле югарылыкта халыкка җиткерелүенә дә, кардәш һәм кардәш булмаган халыклар сафында горур яңгырарлык ядкәрләребезнең сакланып калуында да зур өлеше бар бу шәхесләрнең.

Гомере буе халкыбызның шушы гаять үзенчәлекле хәзинәсен барлаучы, аның биниһая могҗиза булуына үзе әллә кайчаннан төшенгән, башкаларга да бу өлкәнең мавыктыргыч серләрен ачучы, фольклор дөньясына дәшеп, үз артыннан ияртә белүче көчле фикерле, күренекле татар галимнәрен әллә ни күп дип әйтеп булмый. Фәннең шактый катлаулы, филология һәм тарихи фәннәрдән генә дә түгел, күпмедер дәрәҗәдә фәлсәфә, дин гыйлеме, политология һ.б. өлкәләрдән дә гаять киң мәгълүматлы булуны таләп итә торган фольклористика өлкәсенә мөкиббән чын галимнәребезне исә гомумән бармак белән генә санарлык.

Сүзебез – фольклор әсәрләрен гасырлар тирәнлегеннән сөзеп алып, безнең чорга якынайту, кыйммәтен билгеләп, киләчәк

буыннарга тапшыру белән шөгыльләнүче эрудит-галим Фатих ага Урманчеев турында. Әйе, бөтен гомерен халкыбызның эпик һәм лиро-эпик мирасын туплауга, шул ядкәрләрне өйрәнүгә, халыкның үз байлыгын үзенә кире кайтаруга багышлаган фидакяр зат ул Фатих Ибраһим углы. Аның хакында татарның мәгълүм галимнәре, язучылары һәм хәтта шагыйрьләре шактый язды. Барысы да Фатих Урманчеевның милли җанлы затлы галим булуын ассызыклаган. Әмма мондый шәхесләребез хакында каткат сөйләү дә һич артык тоелмый, чөнки үзе дә шагыйрь җанлы Фатих аганың үзеннән дә, сүз сөрешеннән дә, басылган хезмәтләреннән дә теләсә кайсы чор өчен һәм теләсә кайсы катлам өчен тансык җуелмас кыйммәтләр – затлылык, галимлек, яхшы мәгънәсендәге эрелек, аксакаллык, масштаблылык, ваклыклардан һәрвакыт өстен кала белгән олуглык, шулар белән бергә нечкә күңеллелек бөркелә. Табигый ки, болар – һәркемне тартып тора торган күркәм сыйфатлар һәм аларның сирәк кешедә очрый торганнары...

Фатих аганы хезмәтләре аша студент вакытымнан ук күпмедер белсәм дә, аның үзе белән аралашып эшләү бәхетенә Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына килгәч ирештем. Язмышымның бәхетле сукмагы үз вакытында институтның нәкъ менә шушы олпат шәхес җитәкчелек иткән халык иҗаты бүлегенә алып килүне мин тормышымдагы иң уңышлы вакыйгалардан дип саныйм. Күз алдыгызга китерегез: фән дөньясына күз салырга омтылган яшь аспирант һәм төрки дөньяда исеме билгеле зур галим. Алар арасында килешеп эшләүнең генә уңай нәтиҗәләргә китерәчәге билгеле. Бүгенге көндә үз өлкәсендә дистәгә якын фән кандидатын, берничә фән докторын әзерли алган икән, галимнең миссиясе инде үтәлгән дип санарга да мөмкиндер. Үзең әзерләгән яшьрәк буын синең хезмәтләреңне өстәл китабы итеп тота икән – бу инде уңыш дигән сүздер. Гап-гади кебек тоелган мөнәсәбәтләр артына шушы зур галимнең фәнни тырышлыгы гына түгел, оста педагогик эшчәнлеге, сизгер психолог булуы, эшкә дәртләндерә белүе, алдан күрүчәнлеге, кече күңеллелеге һәм, әлбәттә, башка гаҗәеп сыйфатлары белән бергә, үз урынында үзенең булуы, галим кеше нинди була дигәндә, аның шәхси үрнәгенең югары дәрәҗәдә торуы яшеренгән. Фатих аганың шәкертләре, бүген инде үзләре дә фән докторлары, минем белән ихластан килешерләр дип уйлыйм: ул – киләчәк буын турында алдан уйлап, сиздерми генә кайгырта белә торган чын остаз. Күренекле галим Хәмит Ярмиләр нигез салган, бүгенге көндә фән дөньясында танылу алган Казан фольклор мәктәбенең иң якты йолдызы, олы ихтирамга лаек зур шәхес ул Фатих ага.

Быелның 28 маенда алыштыргысыз остазым, күренекле фольклорчы галим Фатих Урманчеевның олуг юбилее – аңа

80 яшь. Кешенең уртача гомере әллә ни озын булмауны искә алганда, бу яшькә җитә алу, әлбәттә, үзе үк зур бәхет. Әмма гомер юлыңны заяга үтмәде дип әйтә алу кешегә тагын да зуррак канәгатьлек бирә торган нәтиҗәдер, мөгаен. Фатих Ибраһим улы – нәкъ менә шундый бәрәкәтле нәтиҗәгә ия, Себер киңлекләренең тугыз гына йортлы бер авылында дөньяга килеп, үз гомерендә халкы өчен шактый зур эшләр эшләргә өлгергән, төрки фән дөньясында мәгълүм зат.

Фатих Ибраһим улы Урманчеев 1936 елның 28 маенда Омск өлкәсенең Азов районы, Кызыл Маяк авылында туган. 1955 елда Омск дәүләт педагогия училищесын, 1960 елда Омск дәүләт педагогия институтының киңәйтелгән тарих һәм филология факультетын тәмамлаган. Студент елларында ук халык иҗаты белән кызыксына, доцент В.А. Василенко җитәкләгән фольклор түгәрәгенең старостасы булып, түгәрәк эшчәнлегендә актив катнаша, рус студентлары алдында татар халык җырлары, бәетләренә багышланган эчтәлекле чыгышлар ясый, Мәскәүдә чыгып килә торган «Русский фольклор» альманахында исә бу хакта мәгълүматлар басыла. Булачак галимнең халык иҗаты белән кызыксынуы шушы чорда ук башлана.

Институтны тәмамлаганнан соң ул туган ягындагы Сосновка авылы урта мәктәбендә ике елга якын укыта. Ф. Урманчеевта өметле яшь белгечне күреп алган Казан галимнәре И. Надиров һәм Э. Касыймов 1962 елда аны Татарстан башкаласына, Г. Ибраһимов исемендәге институтка аспирантурага чакыралар. Егет тәкъдимне кабул итә, язмышы аны менә шулай нурлы Казан белән бәйли.

Аспирантураны тәмамлагач, 1965–1969 елларда Ф. Урманчеев шул ук институтның халык иҗаты һәм халык сәнгате тарихын өйрәнү секторында кече фәнни хезмәткәр булып эшли, 1968 елда «Татар совет халык иҗатында төп жанрларның үсеш юллары» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1961–1971 елларда ул – Казан дәүләт педагогия институтының рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасында әүвәл ассистент, соңыннан укытучы-доцент хезмәтендә. 1971 елдан Ф. Урманчеев Алабуга педагогия институтында дүрт ел буе институтның читтән торып уку бүлеге проректоры, 1975 елдан уку-укыту эшләре буенча проректоры була. Язмышы һәм СССР Мәгариф министрлыгы тәкъдиме галимне чит җирләрдә дә йөртә: 1980–1984 елларда ул Венгриядә махсус командировкада булып, Эгер шәһәрендәге педагогия институты студентларына рус әдәбияты тарихын укыта. 1984 елда яңадан Алабугага кайтып, педагогик эшчәнлеген дәвам итә. Ә 1989 елда галим Ташкентта докторлык диссертациясе яклап, 1990 елда әдәбият кафедрасы профессоры дигән гыйльми исем ала. Ф. Урманчеевның әле чит илгә киткәнче үк язып тәмамланган, докторлык диссертациясенә бәрабәр, әмма ул еллар өчен гаять шикле саналган «Татар халкының героик эпо-

сы» дип аталган зур хезмәте исә китап булып бераз соңрак дөнья күрә.

1992–2009 елларда галим – Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1996 елдан – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) халык иҗаты бүлеге мөдире, аннан соңгы елларда – бүлектә баш гыйльми хезмәткәр.

Ф. Урманчеевның иң зур хезмәтләре татар халык иҗатының эпик һәм лиро-эпик жанрларына багышланган: «Халык авазы: Татар халык бәетләре тарихыннан» (1974), «Эпические сказания татарского народа» (1980), «Героический эпос татарского народа» (1984), «Дастаннарга лаек замана: Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия» (1990), «По следам Белого волка: ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племен» (1994), «Волшебный клубок: Муса Джалиль и народное творчество» (1995), «Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә» (1997), «Народный эпос «Идегей» (1999), «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь: Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин шигъриятенә бер караш» (2002), «Лиро-эпос татар Среднего Поволжья» (2002), «Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре» (2005), «Каһарманнар йолдызлыгы: тарихи-фольклористик очерклар» (2006), «Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек. 3 томда» (2008–2011), «Тюркский героический эпос» (2015)... Гыйльми эшчәнлегендә төп урынны халык иҗаты алып торса да, галимнең эзләнүләре күпкырлы. Аны язма әдәбият, этнография, тарих, мифология мәсьәләләре тирәнтен кызыксындыра, ул бу мәсьәләләрне һәрвакыт гаять оста итеп татар фольклоры белән бәйли. Ф. Урманчеевның һәр язганы, чын галимнәр хезмәтенә хас булганча, фәндә яңа сүз булып кабул ителә.

Аерым китап булып басылып чыккан дистәдән артык фәнни монографиясе, ул төзегән, татар мифологиясенә багышланган өч томлык уникаль энциклопедиясеннән тыш та әле юбиляр галимебез – вузлар өчен татар халык авыз иҗатыннан төзелгән иң беренче дәреслек (2004) һәм хрестоматия (2004), көндәлек матбугатта фольклор, тарих темаларына һәм тарихи шәхесләр турында, язучы-прозаиклар һәм бигрәк тә шагыйрьләр иҗатына, әдәбият-мәдәниятнең актуаль проблемаларына, гыйльми хезмәтләргә багышланган өч йөзгә якын фәнни мәкалә, очерклар, рецензияләр һ.б. авторы.

Ф. Урманчеев – Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1996), Халыкара төрки академия академигы (1997), 1996 елда Татарстанның Мактау грамотасы белән бүләкләнде, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе язучылар берлеге әгъзасы.

Фән юлы матур Фатих аганың. Тормыш юлы аңа да чал чәчләр өстәде, әлбәттә. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең бер хәдисендә болай диелгән: «Кешеләрнең иң яхшысы – озын гомер итеп, гамәлләре яхшы булганы». Гомере озын булып,

яхшы гамәлләренең җимешләрен тагын да татырга язсын Фатих агага. Фикер колачы гел шундый киң булып, әйткән сүзе һәрвакыт зиһен ачыклыгына этәрсен, фәндә ул юл күрсәткән шәкертләре аңа зур куаныч-шатлыклар китерә торсын. Яңа фәнни казанышлар, тән һәм җан саулыгы, күңел тынычлыгы, озын гомер телибез фольклорчы галим Фатих Ибраһим улына!

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*
*e-mail: lilmuhat@mail.ru*

*Ризаэддин Фәхреддин*

# КӨТЕБЕ СИТТӘ

Предлагаемый вашему вниманию отрывок труда Ризаэддина Фахруддина посвящен вопросам исламского источниковедения, в частности, авторитетным трудам по хадисам. В нем автор знакомит читателя с основными сборниками хадисов, дает информацию об их изданиях, толкованиях, сокращенных вариантах и указателях. Публикуется по изданию: Фәхреддин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Хәдис вә сөннәт галимнәре кашында мәгъруф улан көтебе ситтә вә шәрехләре, мөәллифләренең тәрҗемәи хәлләре, хәдис гыйлеме хакында бәгъзе бер кирәкле файдаларны мөштәмил рисаләдер. Гыйльме хәдистән. Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1910. Б. 58–76.

**Ключевые слова:** Ризаэддин Фахруддин, хадисы, сборники хадисов, издания, толкования.

## «Көтебе ситтә»

Хәдис гыйлеменең асылы һәм нигезе итеп әһәмият бирелгән «Көтебе ситтә», икенче төрле әйткәндә, «Өммеһате ситт», «Сыйхах ситтә» болар: «Сахих Бохари», «Сахих Мөслим», «Сөнән Әби Дауд», «Җамигъ Тирмизи», «Сөнән Нәсаи», «Сөнән Ибне Маҗә».

«Көтебе ситтә»не болай бәян итүебез күпчелек галимнәр фикере буенча. Кайберәүләр[1] «Сөнән Ибне Маҗә» урынына имам Малик хәзрәтләренең «Әл-мөваттаэ»ны санаганнар, кайберләре алтынчы китап булырга «Мөснәд әд-Дарими» лаек дигәннәр[2]. Без бу җирдә шуның өчен «Сөнән Ибне Маҗә» белән «Әл-мөваттаэ»ның һәр икесен сөйләячәкбез. «Мөснәд әд-Дарими хакында мәгълүматыбыз булмаганлыктан, нөсхәсенең басылу-басылмавын белмәгәнлектән һәм бу көнгә кадәр ул китапны күрмәгәнлектән, аның хакында бәхәсләшергә көчебез булмады.

Боларның исемнәрен санаган китапларның әүвәлге икесе «сахихайн», калган дүртесе «сөнән әрбәга»; «Сөнән Ибне Маҗә» белән «Әл-мөваттаэ»дан башкалары «Көтебе хамсә» дип билгеле.

Бохари белән Мөслим «Сахих»ларында булган хәдисләр хакында Бохари белән Мөслим тарафыннан берүк фикердә булган мәгънәсе белән «мөттәфәкъ галәйһи» диләр. Сахих хәдисләрнең бөтенесе дә «Сахихайн»да (Бохари һәм Мөслимнең ике «Сахих»ы) булу мәҗбүри түгел, Бохари һәм Мөслим үзләре дә моны мәҗбүри итмәгәннәр. Шул сәбәпле, бу ике «Сахих» хәдисләреннән арттырып төзелгән башка «Сахих»лар да бар:

---

[1] Болардан Морад Рәзин әс-Сәркастый булып, аңа исә Мәҗдеддин Ибне әл-Әсир ияргән. «Фәтех әл-мөгыйс». Б. 33.

[2] Бу сүзне әйтүче Галяи белән Нәвави. Фәтех әл-мөгыйс. Б. 33, «Тәдриб әр-рави». Б. 57.

«Сахих Ибне Хиббан», «Сахих Ибне Хөзәймә», «Әл-мөстәдрәк[1] лил-Хаким» кебек китаплар бу җөмләдән. Әмма «Сахихайн»да булган хәдисләрнең һәрберсенең сахих дип кистереп әйтергә мөмкинме, монда гыйлем әһелләре арасында зур бер низаг бар[2].

**«Сахих әл-Бохари»**

«Җамигъ әс-сахих» дип танылган булган бу хезмәт, Корьәншәрифтән соң, ислам галәмендә иң ышанычлы һәм хөрмәтле китапларның берсе, бәлки, беренчеседер. Анда булган хәдисләрнең аз гына саны искәрмәгә керә, калганнарының дөрес хәдисләр булуында галимнәр бер фикердә булганнар һәм мөмкин кадәр эчтәлеге белән гамәл кылуны ваҗиб дип күргәннәр[3].

Бу хезмәт эчендә 100дән артык китап һәм 3450 баб (бүлек) булып, кабатланулары белән санаганда хәдисләре 9082 һәм кабатлануларны төшереп калдырганда 2602[4]. Кабатланган хәдисләрдә күп вакытта иснадлар башка-башка була. Иснадлары белән бергә кабатланган хәдисләр бары тик 23. Исемнәре белән телгә алынган шәехләре 289 булып, аларның Мөслим риваятендә булмаганнары 134. Хөрмәтле рәсүл әфәндебез хәзрәтләреннән өч кенә арадашчы белән риваять ителгән хәдисләр кабатланулары белән 22 һәм кабатлануларын санамаганда 16. Иң ерак чылбыр 9 арадашчы белән сөйләнелә.

Сахих Бохариның бөтен хәдисләре 183 сәхабә-арадашчылары белән риваять ителеп, аларның 31 е хатын-кызлар. Хәдисләре иң күп булган сәхабәләр болар: Әбү Һөрәйрә (446 хәдис), Әнәс бине Малик (268 хәдис) Габдулла бине Габбас (217 хәдис), хәзрәти Гайшә (242 хәдис), Җабир бине Габдулла әл-Әнсари (90 хәдис).

Имам Бохари бу китап хакында: «Һәрбер хәдисне китабыма керткән вакытта иң элек тәһарәт алып, соңра, ике рәкәгать нәфел намазы укыйм, аннан соң хәдисне яза идем; мин бу хәдисләрне 600 000 хәдис арасыннан сайлап алдым[5] һәм [китабын] төзер өчен дә ун ел гомеремне

---

[1] Бу хезмәттә Хәким тарафыннан, Бохари һәм Мөслим шартларына туры килгән хәлдә, «Сахих»ларына кермәгән хәдисләр җыелган. Фәкать бу китап хәдисләре хакында күп тәнкыйть бар, диләр.

[2] Бу сорауга дөрес җавап бирүчеләр дә «мөттәфикъ гәләйһи»дән 52, тик Бохари риваятеннән 68, Мөслим риваятеннән 100, барлыгы 220 хәдисне искәрмә итәләр. Тәдриб әр-рави. – Б. 43.

[3] Шәрх Нәвави галә Мөслим. Т. 1. Б. 36.

[4] Фәтех әл-могыйси шәрхү әлфийят әл-хәдис. Б. 13.

[5] Бу сүзләрдә шәрекъ күпертүе булмаса, яхшы булыр иде, Бохари үзе күпертмәс, бәлки, аңа иснад иткән бер равидән шундый нәрсә чыгып, башкалар шуңа ияргәннәр. Алты йөз мең хәдис иснадлары белән бергә «Сахих әл-Бохари» кадәр 66 томлык бер китап булырга тиешле, диючеләр бар. Фәкать китап басу сәнәгате барлыкка килүдән элек кешеләрдә ятлау куәтенең бик көчле булуы һәм, аерым алганда, гарәпләрдә зиһен адәм ышанмаслык дәрәҗәдә куәтле булуы турында хәбәр китерелсә, югарыда телгә алынган сүзләр хаклыктан ерак булмас. Ибне Габбас, Хәммад әр-Равия, Әбү әл-Галәэ әл-Мәгарри, Әбү Рәяш, Әсмәгый, Ибне әл-Кәлби, Ибне Габдун әл-Әндәлүси, Ибне әл-Мөрәххәл һәм башкаларның зиһеннәре һәм ятлаулары хакында булган хәбәрләр хәйран калырга мәҗбүр итә.

сарыф иттем, Аллаһ Тәгалә белән үз арамда дәлил булачагына өмет итәм», – дип сөйләгән.

Бу китапны турыдан-туры төзүченең үзеннән риваять итүчеләрнең 90000 гә җитүе һәм аларның иң ахыргы вафат булганы Әбү Тальхә Мансур бине Мөхәммәд булуы (329 да вафат) риваять ителә.

**Басылган нөсхәләре.** Сахих әл-Бохари бөек бер китап булган хәлдә, берничә тапкыр басылып, һәр мәртәбә басылганда меңләгәнчә нөсхәләре таралган. Нинди җирләрдә һәм кайсы елларда басылуы моннан мәгълүм булыр:

1) Дәһли, (?) том, 1270 (1854);
2) Мисыр, 10 том, 1279 (1862);
3) Лейден, 3 том, 1285 (1868);
4) Болак, 8 том, 1296 (1879);
5) Мисыр, 4 том, 1309 (1892);
6) Болак[1], 8 том, 1313 (1895);
7) Истамбул, 8 том, 1315 (1897);
8) Мисыр («Фәтех әл-бари» исемле), 1319 (1901);
9) Мисыр, 8 том, 1320 (1902).

Бу басмаларның иң дөресе һәм иң гүзәле 6 нчы номер белән күрсәтелгән «Болак» басмасы, диләр.

**Басылган шәрехләре (аңлатмалары).** Бохари «Сахих»ына тулысынча җиренә җиткереп шәрех язуны бөек галимнәр кыен хезмәтләрдән санаганнар һәм язылган шәрехләрнең күбесеннән риза булмаганнар. Хәтта ки Ибне Хальдун: «Үземнең күп шәехләремнән ишеттем, Аллаһ Тәгалә аларга рәхим кылсын: Бохари китабын шәрехләү – өммәт өчен бурыч», – ди[2]. Максаты исә: «Бохари китабына шәрех язу өммәт өстендә бурыч иде, ләкин бу бурычның һаман үтәлгәне юк», – дип әйтү була. Ләкин Ибне Хальдуннан соң, Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани белән Гайни тарафыннан гүзәл шәрехләр язылган. Шуның өчен Ибне Хальдун сүзләренә каршы, Кятиб Чәләби: «Ибне Хәҗәр әл-Гаскаланиның һәм Гайнинең шәрехләре белән, бәлки, теге бурыч үтәлгәндер», – ди[3]. Бу шәрехләр хакында да замандашыбыздан бер кемсә: «Ибне Хәҗәр белән Гайни шәрехләрендә сөйләүне һәм хәдисләрне яраклаштыру, тарихи вакыйгаларны аңлату һәм хөкемнәрне чыгарулар камил булса да, иҗтимагый хәлләр һәм бүгенге халык тормышына караган шәрехләр җитәрлек түгел, бәлки, тулысынча юк, шуның өчен өммәт өстендә булган бурыч һаман өстеннән төшмәде», – ди.

Һәрхәлдә, Бохари «Сахих»ына төрле заманнарда һәм төрле мәмләкәтләрдә танылган мәшһүр галимнәр тарафыннан озынлыкта һәм кыскалыкта, төрле караштa шәрехләр язылган. Болардан без бары тик басылган шәрехләрне бер җирдә язачакбыз[4].

---

[1] Бу басма солтан Габделхәмид акчасына 5000 нөсхә басылган.

[2] Т. 1. – Б. 126.

[3] Кәшф әз-зонун. – Т. 2. – Б. 426.

[4] Бохари шәрехләре белән «Кәшф әз-зонун» һәм башка хезмәтләрдән алып төзүчеләренең вафат еллары тәртибендә «Сахих Бохари»га булган шәрехләрдән 27 китап исеме язган идек. Соңра, китабыбыз озын булмасын, дип, бастыру вакытында бары тик басылган шәрехләрне телгә алып, башкаларын төшереп калдырдык һәм «Көтебе ситтә»нең башкалары хакында да шул рәвешле иттек.

1) **«Фәтех әл-бари».** Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани (852) хезмәте булган бу шәрех, «Сахих әл-Бохари» шәрехләре арасында иң хөрмәтлеләреннән. Ибне Хәҗәр аны 817 дә башлап, 842 нең рәҗәб аенда тәмамлады һәм шундый бер нигъмәткә ирешү сәбәпле, шул елның шәгъбән аенда (юбилей уңаеннан) олуг бер бәйрәм ясады. Замандашлары булган бөек затлар бу мәҗлестә бергәләп катнаштылар. (Читләрдән котлау телеграммалары җибәрелмәве ул вакытта телеграмма булмау сәбәпле булган). Бу мәҗелес өчен 500 динар (якынча 1875 сум) тотылган. Китап тәмам булу хәбәре дөньяга таралуы белән һәр тарафта булган ислам падишаһлары һәм әмирләре нөсхә итеп алдырдылар һәм нөсхәсе дә 300 динар (якынча 1215 сум) бәрабәренә язылган. Бу хезмәт Мисырда берничә тапкыр буларак, 1301 дә Сиддыйк Хәсән әл-Баһвапали акчасына, икенче мәртәбә 1319 да әл-Хишаб тарафыннан унбер томда басылдылар. Бу хезмәт мөхәддисләр каршында кыйммәтле булуына дәлил йөзеннән болар җитәр булса кирәк, «Сахих әл-Бохари»га шәрех язуны сораучыларга Шәүкәни: «Җиңгәннән (фәтехтән) соң һиҗрәт юк», – дип җавап биргән.

2) **«Гомдәт әл-кари».** Бәдреддин әл-Гайни (855) хезмәте булган бу шәрехнең төзүче каләме белән язылган нөсхәсе Мисырда Әзһәр китапханәсе янында булган «Китапханә»дә, 21 томда. 821 нең рәҗәб аенда башлап, 847 дә җөмадел-әүвәл аенда тәмамлады. Ибне Хәҗәр тарафыннан төзелгән булган «Фәтех әл-бари» нөсхәсен үрнәк итеп алып торган һәм шуннан файдаланган. Хәтта ки кайбер урыннарда тоташтан берәр биткә кадәр күчерә. Моннан башка, Рөкнеддин әл-Карими[1] шәреханнән дә күп нәрсәләр алган һәм файдаланган. Хәтта Гайни шәрехен мактап сөйләүчеләргә Ибне Хәҗәр: «Гайни Рөкнеддин шәреханнән файдалана, Рөкнеддин шәрехе беткәннән соң, күрерсез, Гайни сүзләре дә азаер (чөнки Рөкнеддин шәрехе тәмам түгел)», – дигән; чыннан да шулай булган. Гайни шәрехе ни өчендер үзе исән вакытта «Фәтех әл-бари» дәрәҗәсендә шөһрәт тапмаган. Ихтимал ки, бу нәрсә Ибне Хәҗәр шәреханнән соң тәмам булганнан һәм Ибне Хәҗәр кебек зур мәҗелесләр ясап танытмавыннан, хәнәфиләргә караганда бу вакытта Мисырда шафигыйларның мәртәбәләре югары булуыннандыр. Шулай булса да, Гайни шәрехе файдалы шәрехләрдән булуын галимнәр таныганнар. Ибне Хәҗәр белән Гайни – һәр икесе дә бер заманда бер-берсенә якын буларак Мисырда тормыш итәләр һәм һәрберсе хәдис гыйлеменең

---

[1] Бу кемсә үзәк нигезе кыпчак башкаласы булган Сарай шәһәреннән. Исеме Әхмәд бине Мөхәммәд бине Габделмөэмин булып, кушаматы да Рөкнеддин. Кулларында калтырау булганлыктан, «Әл-мөртәгыйш» дип билгеле булды. Соңра, Мисырга барып, Җамигъ әл-Әзһәрдә дәрес бирде. «Гараиб эн-нәвадир» исемле бу хезмәттән файдаланганнан, гаебен танып: «Аннан соң мин һиҗри 800 елга кадәр төньяк илләренә сәфәр кылгач, анда кайбер остазларымнан “Гараиб эн-нәвадир” китабын таптым», – дип искә ала.

белгечләреннән иде. Аерым-аерым шәрехләр язган җирдә икесе бергә язган булсалар иде, шәрехләре тагын да бик гүзәл һәм файдалы булган булыр иде. Фәкать исламда ике-өч кеше бергә китап төзү гадәте булмаган яки бик сирәк булган. Моннан башка, бу хезмәтләр үз шәкертләренә дәрес бирү ысулы белән язылган һәм, шул сәбәпле, бер-ике кемсәнең бергәләп эшләве мөмкин булмаган. Бу шәрех Истамбулда 1309 да 11 томда басылган.

3) **«Иршад әс-сари».** Төзүчесе Әхмәд бине Мөхәммәд бине Әбү Бәкер әл-Касталани (933). Бу шәрех 1267 дә Болакта һәм 1304 тә, 1326 да Мисырда басылган. Әүвәлге басмасы 10 томда, өченчесе 12 томда булып, икенче басмасы хакында мәгълүматым юк. Нигездә, бу шәрех Ибне Хәҗәрнең «Фәтех әл-бари»еннән алынган, фәкать исемнәрне дөресләве, һәр исем очраганда кабатлавы шәкертләр һәм, аерым алганда, мөдәррисләр өчен кулай булган.

4) **«Төхфәт әл-бари».** Шәйхелислам Әбү Зәкәрия әл-Әнсари (926) төзүчесе булган бу хезмәт өченче басма «Иршад әс-сари» белән бергә басылган.

5) **«Ән-нур әс-сари».** Хәсән әл-Гадәви (1303) төзүчесе булган бу шәрех 2 нче басманың китап читендә басылган.

6) **«Хашият әс-Синди».** Әбү әл-Хәсән әл-Мәдәни әс-Синди төзүчесе булган бу хезмәт 5 нче басманың китап читендә басылган.

Ислам дөньясында укудан һәм файдаланудан күбрәк язу һәм укытуга камил теләк булу сәбәпле, «Сахих әл-Бохари»га язылган шәрехләр, аңлатулар хисапсыз дәрәҗәдә күп булып, инде бу хезмәтләрнең күбесе Европа һәм Мисыр китапханәләрендә җыелып торалар. Фәкать өйрәтүчеләр һәм дәрес бирүчеләр өчен «Иршад әс-сари», хәдис гыйлеменә омтылучы һәм осталык булдыру максатында булганнар өчен «Фәтех әл-бари», хәнәфи мәзһәбенчә, хәдисләрдән хөкем чыгара белү теләгендә булганнар өчен «Гомдәт әл-кари» җитәрлек булганлыктан, шулар белән башкалардан хаҗәтсез булырга мөмкин. Бер-берсенең нөсхәсеннән булган озын шәрехләр гомерне әрәм итүгә һәм күп вакытта гыйлемне бетерүгә сәбәп була. Ибне Хальдун китапның күп булуы гыйлем алудан тыя, дип саный[1].

**Кыскартылганнары.** Китапларның кыскартылганнары үз дәрәҗәләренә җитми. Аерым Бохари «Сахих»ы кебек мөбарәк бер китапның кыскартылганы ышанычлы булу җәһәтеннән асылына тиңләштерелми. Кайбер китап төзүчеләр үзләренең китапларының кыскартылуына һич риза булмыйлар, имеш. Имам Мәсгуди «Мәруҗ әз-зәһәб» кереш сүзендә: «Кем аның мәгънәсен үзгәртсә, берәр рөкенен алып ташласа, ачык бер билгесен бетерсә, үзгәртсә, кыскартса яки бездән башка берәүгә нисбәт итсә, аңа Аллаһның ачуы булсын һәм сабырлыгы җитмәслек төрле бәлаләргә дучар булсын һәм Аллаһ аны башкаларга гыйбрәт итсен!» – ди. Якут Хәмәви

[1] Т. 1. Б. 274.

«Мөгъҗәм әл-бөлдан» кереш сүзендә: «Бу китапны күчерүчегә, файдаланучыга минем хакым бар: язганнарымны бозып, үзгәртеп, урыннарыннан күчереп, тырышлыгымны бетермәсен, чөнки кайберәүләр берәр сүзне кирәксенмәскә мөмкин, ә башкалар ул сүз өчен үлеп торалар. Әгәр дә минем нәсыйхәтемне үтәсәгез, Аллаһ сезне изгеләрдән кылсын, әгәр сүземне тотмасагыз, Аллаһ кыямәт көнендә тиешле җәзасын бирсен!» – дигән. Шуңа карамастан, Хәмәвинең бу үтенүенең имам Сөютыйга тәэсире булмаган, ул «Мөгъҗәм әл-бөлдан»ның кулларын, аякларын һәм канатларын сындырып кыскарткан. Төзүче [моңа] ризамы-түгелме, «Җамигъ әс-сахих»ны кыскарткан затлар да булган. Бу көндә басылган кыскартмалар болар:

1) «Җәмегъән-ниһаяти фи бәдәэ әл-хайри вә әл-гаяһ». 675 тә вафат булган Габдулла бине Сәгъд бине Хәмзә тарафыннан кыскартылган. 1302 елда ташбасма белән Мисырда басылды, янында Габделмәҗид әш-Шурнуби шәрехе дә бар.

2) «Әт-тәҗрид әс-сарих». Төзүчесе 893 тә вафат булган Шиһабеддин Әбү әл-Габбас Әхмәд бине Әхмәд бине Габделлатыйф әш-Шәрҗи әз-Зөбәйди[1]. 1287 дә бер томда Мисырда «Болак» нәшриятында басылган. Моңа исә 1307 дә вафат булган Әбү әт-Тайиб Сиддыйк бине Хәсән әл-Хөсәени әл-Каннуҗи әл-Бохари тарафыннан «Гаунә әл-бари лихилли әдилләт әл-Бохари» исемле бер шәрех язылып «Нәйл әл-әүтар»ның китап читендә Мисырда 1297 дә басылды.

**Әсмаи риҗәл.** «Сахих Бохари»да телгә алынган кемсәләрнең тормыш юллары белән таныштыру хакында язылган хезмәтләрдән мәшһүрләре болар:

1) «Әсмаи риҗәл әл-Бохари»[2], Әбү Наср әл-Кәлябази (378).

2) «Әл-игълям бимән зүкира фи әл-Бохари мин әл-әгълям», Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани (852).

3) «Әл-җәмгъ бәйнә китабәй әл-Кәлябази вә Әби Бәкер әл-Исбаһани», Әбү әл-Фадыл әл-Мәкъдисинеке (507). Бу хезмәт Хәйдәрабад әддәкәндә ике томда басылган.

4) «Куррат әл-гайни фи дабтый әсмаи риҗәл әс-сахихайн». Габделгани әл-Бахрани. 1 томда Хәйдәрабад әддәкәндә басылган.

**Бабларының (бүлекләренең) тәрҗемәләренә (аңлатуларына) булган шәрехләр.** «Шәрхү тәраҗими әбваб әл-Бохари». Шаһ Вәлиулла әд-Дәһләви (1176). Бу хезмәт тә Хәйдәрабад әддәкәндә басылган.

**Күрсәткечләре.** «Мифтахү сахих әл-Бохари». Истамбулда Фатих Җамигы мөдәррисләреннән Мөхәммәд Шәриф әт-Тукади. Бу хезмәт 192 биттә 1313 тә Истамбулда басылган. Хәдис-шәрифләрнең беренче сүзе хәтердә булса, бу күрсәткечтән карап, кирәк булган хәдисне

---

[1] Замандашларыбыздан мөхтәрәм Мөхәммәд Зәһәни хәзрәтләре бу китапны Хөсәен бине Мөбарәк әз-Зөбәйди исемле затка нинди дәлилгә нигезләнеп иснад итүен аңламадык. Әл-хәкаик. Т. 1. Б. 8.

[2] Бу китапның исемен белмәвем сәбәпле, «Әсмаи риҗәл әл-Бохари» дип яздым.

табарга мөмкин була. Шул яктан, бу китап файдалы хезмәтләрдән.

### «Сахих Мөслим»

«Җамигъ әс-сахих» һәм «Әл-мөснәд әс-сахих» дип танылган бу китап «Көтебе ситтә»нең икенчесе булып, Бохари «Сахих»ы белән бергә икесе «Сахихан» һәм «Сахихайн» дип билгеле. Әбү Гали әл-Хөсәен ән-Нисабури Мөслим «Сахих»ын хәтта Бохари «Сахих»ыннан өстен күргән һәм кайбер Көнбатыш галимнәре дә бу фикерне алганнар. Тик бу әһәмиятле бер мәсьәлә түгел. Чөнки төзелеше буенча – Мөслим «Сахих»ы һәм иснадларның ышанычлыгы буенча – Бохари «Сахих»ы гүзәл икәнлеге турында күпчелек галимнәр бер фикердә торганнар.

«Сахих Мөслим» өч йөз мең хәдис сайлап алган, хәдисләрнең саны кабатланулар белән 12000 һәм кабатланулардан башка 4000. Иң яхшы сәнәдле хәдисләр Расүлуллаһ хәзрәтләреннән дүрт арадашчы белән сөйләнелеп, болар якынча 80.

Мөхәддисләр, тикшергәннән соң, «Сахих Мөслим»дә булган бу хәдисләрне аерып алып, хаталы булганнарын игълан иткәннәр: 1) Көсуф намазын рәсүлуллаһ өч рөкүгъ белән укыды дигән хәдис (т. 1, б. 247); 2) Җирнең шимбә көн барлыкка китерелүе хәдисе (т. 2, б. 340); 3) Әбү Суфьян, мөселман булганнан соң, кызы Өмме Хәбибәне рәсүлуллаһ хәзрәтләренә бирүе хакында булган хәдис (т. 2, б. 264). Фәкать болар гаять аз һәм дә гамәл кылуга карамаганнар[1].

**Басылган нөсхәләре.** «Сахих Мөслим» бу көнебезгә кадәр бу урыннарда басылган:

1) Калькутта, 1265 (1849); 2) Болак, 2 том, 1290 (1873); 3) Мисыр, 1327 (1909).

**Басылган шәрехләре.** «Шәрех ән-Нәвави» (676). Бу шәрех «Сахих Бохари» шәрехе булган «Иршад әс-сари» нөсхәләре аңлатмасында ике тапкыр басылган.

**Әсмаи риҗәл.** Басылган «Әсмаи риҗәл» Бохари «Әсмаи риҗәл»ен сөйләгәндә үтте, шунда мөрәҗәгать ителә.

**Күрсәткечләре.** Аңа күрсәткеч буларак Истамбулда Фатих Җамигый мөдәррисләреннән Мөхәммәд Шәриф әт-Тукади «Мифтахү сахихый Мөслим» исеме белән бер китап төзеп, 52 биттә бастырган. Хәдисләрнең беренче сүзләре алфавит тәртибе белән бирелгән.

### «Сөнән Әби Дауд»

«Сөнән Әби Дауд» «Көтебе ситтә»нең өченчесе булып, хәдис фәнендә кабул ителгән хөрмәтле бер хезмәт. Фикыһ мәсьәләләрен җыю буенча хәтта аны «Сахихайн»нан дә артык күрүчеләр бар. Бөек галимнәрдән булган Ибне әл-Әгъраби: «Кулында

---

[1] Шулай ук «“Нәхнү нәҗи яумәл-кыямә ган кәзә вә кәзә унзур” (“Без кыямәт көнендә киләчәкбез һәм моны кара”) хәдисе дә (Т. 1. Б. 70) хаталы булган», диләр. Гүя, дөресе: «Нәхнү нәҗи яумәл-кыямә галә күм» булып «күм» сүзе «кәзә» рәвешендә язылган, мәгънәсен килештерә алмаган бу кемсә китап аңлатмасына «асылында шулай тикшер» мәгнәсендә булган «кәзә унзур» дип язган, соңра, шул сүз мәтен буларак күчерелгән була.

Коръән-шәриф белән «Сөнән Әби Дауд» булган кемсә һәрбер китаптан хаҗәтсез булыр», дигән. Бу хезмәттә сөләсияттән (өч кешедән торган иснадлы) бер генә хәдис барлыгы риваять ителә. Әбү Дауд бу китапны төзегәннән соң Әхмәд бине Хәнбәл хәзрәтләренә күрсәткән һәм, югарыда күрсәтелгәнчә, яхшы дип табылган. Имам Газали, мөҗтәһидләр өчен «Сөнән Әби Дауд» җитәрлек булачагын әйткән һәм шафигыйлардан күп затлар Газалинең бу фикере белән килешкәннәр. Әбү Дауд белән Тирмизи хакында: «Һәр икесе, һичшиксез, мөҗтәһид иделәр, фәкать карашларда берсе Әхмәд, икенчесе Исхак бине Раһуя мәзһәбенә карадылар», диләр.

**Басылган нөсхәләре.** «Сөнән Әби Дауд» бер тапкыр 1280 дә Мисырда һәм икенче тапкыр 1283 тә ташбасма белән Дәһлидә басылган.

**Басылган шәрехләре.** «Дәрәҗатү миркат әс-согуд». Бу гасыр башында вафат булган Гали эд-Дәмнати тарафыннан язылган һәм 1298 дә Мисырда басылган.

### «Әл-мөҗтәба»

«Көтебе ситтә»нең дүртенчесе – имам Нәсаи тарафыннан җыелган «Әл-мөҗтәба». Югарыда күрсәтелгән хәзрәтләре иң элек «Әс-сөнән әл-көбра» исемле бер китап төзеде, соңыннан, аны төзәтеп, кыскартып «Әл-мөҗтәба» һәм икенче исем белән дә «Әс-сөнән әс-сугра» китабын мәйданга китерде. Һәр ике китап «Сөнән эн-Нәсаи» дип танылган булса да, «Көтебе ситтә»дән саналганы «Әлмөҗтәба»[1]. Бу китап мәртәбәсен «Сахихайн»нан соң гына санаучылар бар. Хәтта кайберәүләр: «Имам Нәсаи «Сөнән»е («Әл-мөҗтәба») дәрәҗәсендәге хөрмәтле бер китап ислам дөньясында төзелмәде», – диләр. Көнбатыш галимнәреннән кайберәүләр имам Нәсаи китабын Бохари «Сахих»ыннан да алдынгы санаганнар. «Көтебе ситтә» эчендәге бары тик бу хезмәттә Әбү Хәнифә хәзрәтләреннән берникадәр хәдис риваять ителгән. Бу китап исемен кайберәүләр «н» белән «Әл-мөҗтәна» рәвешендә язганнар.

**Басылган нөсхәләре.** «Әлмөҗтәба» 1847 һәм 1882 дә бер том буларак ташбасма Канпурда, 1312 дә ике томда Мисырда басылды.

**Басылган шәрехләре.** 1) «Зәһер әр-руба». Имам Сөютый төзүчесе булган бу хезмәт «Әл-мөҗтәба»нең һәрбер нөсхәсе белән бергә басылган. 2) «Шәрхү Әби әл-Хәсән әл-Мәдини әс-Синди. Өченче басманың китап читендә басылган. 3) «Гареф зәһер әр-руба». Гали эд-Дәмнати хезмәте булган бу шәрех 1299 да Мисырда басылган.

---

[1] Хәдис китапларының «раваһү эн-Нәсаи» яки «раваһү әл-хамсә» яки «раваһү әс-ситтә» дип әйтелүләренең максаты: шул «Әл-мөҗтәба» хәдисләре [күздә тотыла]. Кятиб Чәләбинең: «Зәкиеддин әл-Мөнзири “Сөнән Әби Дауд”ны кыскартып, “Әлмөҗтәба” дип исем куйды һәм аңа да Сөютый “Зәһер әр-руба” исеме белән шәрех язды», диюендә ялгышлык булса кирәк. Чөнки Сөютый «Зәһер әр-руба»се имам Нәсаинең үз китабына шәрех.

**«Җамигъ эт-Тирмизи»**

«Көтебе ситтә»нең бишенчесе – төзүчесе имам Тирмизи булган «Җамигъ әт-Тирмизи» һәм «Сөнән әт-Тирмизи» исемнәре белән билгеле булган китап.

Имам Тирмизи, бу китапны төзегәннән соң, Хиҗаз, Гыйрак, Хорасан галимнәренә тәкъдим иткән һәм алар, тикшергәннән соң, мактаганнар. Төзелеше гүзәл, кабатланулары аз булып, дәлилләрен, сәхабәләр һәм табигыйннар мәзһәбләрен, шөбһәле булу ихтималы булган равиләрнең күньяләрен бәян итеп китүе, хәдисләрнең төрләрен һәм кимчелекләрен күрсәтүе буенча, бу китап «Сөнән» китаплары арасында файдалану өчен иң җиңеле. Бу китап хакында: «Мөҗтәһид өчен дә, мөкаллид (кайсыдыр галимгә ияргче) өчен дә җитәрлек, “Җамигъ Тирмизи” булган өйдә, гүя, пәйгамбәр үзе килеп сөйләп торыр», – дигән булганнар. Бу хезмәттә сөләсияттән (өч кешедән торган иснадлы) фәкать: «Кешеләргә шундый заман килер: алар арасында динендә сабыр итүче утлы күмер тотучыга тиң булыр» хәдисе генә бар. Шәйхелислам Әбү Исмәгыйл Габдулла әл-Әсбаһани «Җамигъ Тирмизи» хакында: «Минем уйлавымча, бу китап Бохари белән Мөслим «Сахих»ларына караганда да файдалырактыр», – дип әйтүе риваять ителә[1]. Шуңа карамастан, кайбер хәдисләре тәнкыйть ителгән[2].

**Басылган нөсхәләре.** «Җамигъ Тирмизи» 1844 тә һәм 1849 да ташбасма белән Дәһлидә, 1292 дә 2 томда Болакта басылган.

**Басылган шәрехләре.** «Нәфегъ куәт әл-могътәзи», Гали әд-Дәмнәти хезмәте булган бу шәрех Дәһлидә басылган нөсхәнең китап читендә басылган.

**«Сөнән Ибне Маҗә»**

«Көтебе ситтә»нең алтынчысы, күпчелек галимнәр санавынча – «Сөнән Ибне Маҗә». Хәдисләренең саны 4000 булып, арада хөрмәтле рәсүлдән өч кенә арадашчы белән риваять ителгән өч хәдис бар.

Моны исә башлап алтынчы китап итеп санаучы әл-Фадыл бине Таһир әл-Мөкаддәси булган. Әмма Мәҗдеддин бине әл-Әсир: «Ибне Маҗә «Сөнән»е фикыһ буенча караганда, файдалы бер хезмәт булса да, хәдисләре сафлык җәһәтеннән «Көтебе хәмсә» дәрәҗәсендә түгел, бәлки, арада мөнкәр (кире кагылучы) хәдисләр дә бар», – дип аның урынына «Әл-мөваттаэ»ны алтынчы китап итеп караган. Ибне Маҗәнең Казвин (шәһәр исеме) фазыйләте хакында риваять иткән хәдисе (т. 2, б. 92–93) – мәудуг, диләр.

[1] Тәзкирәт әл-хөффаз. Т. 3. Б. 38.

[2] Ибне әл-Каййим: «Хөрмәтле рәсүл белән Әбү Талибнең Шам сәфәре хакында озын хәдистә булган: «Әбү Бәкер аның белән Билалны җибәрде» дигән җөмлә хакында (Җамигъ Тирмизи. Т. 2, б. 203.): «Бу ачык хата, чөнки Билал ул вакытта булмаска тиеш иде», – дигән (Зад әл-мәгад. Т. 1. Б. 17). Ибне Тәймия: «Мин – гыйлемнең шәһәре һәм Гали – аның ишеге» хәдисе хакында «ялган» ди (Әл-мәҗмугат әл-көбра. Б. 337). Имам Тирмизи «Гали казанышлары» бүлегендә: «Мин – хикмәт йорты һәм Гали – аның ишеге», дип бер хәдис сөйли (т. 2, б. 214). Ибне Тәймия максаты бу хәдисме, гаҗәп?

Шулай ук аягүрә бәвел итүдән тыеп, Җабирдән риваять иткән хәдисе хакында да мөхәддисләр зур низаглар чыгара[1]. Сөләсият буларак биш хәдис барлыгы риваять ителә.

**Басылган нөсхәләре.** «Сөнән Ибне Маҗә» 1282 дә һәм 1889 да ташбасма белән Дәһлидә, 1313 тә ике томда Мисырда басылды.

**Басылган шәрехләре.** 1) «Мәсабих әз-зөҗәҗә», имам Сөютый (911) хезмәте булган бу шәрех 1282 дә басылган булган нөсхәнең китап читендә чыккан. 2) «Шәрхү Әби әл-Хәсән әл-Мәдәни әс-Сәнәди (1138). Бу шәрех 1313 тә басылган нөсхәнең китап читендә басылган. 3) «Инҗах әл-хаҗәти галә «Сөнән Ибне Маҗә». Габделгани бине Әби Сәгыйд әл-Гомәри (1296) хезмәте булган бу шәрех «Мәсабих әз-зөҗәҗә» белән бергә берничә басманың китап читендә басылган.

### «Әл-мөваттаэ»

«Көтебе ситтә»нең алтынчысы – Мәҗдеддин бине әл-Әсир атаганча, имам Малик хәзрәтләре тарафыннан төзелгән «Әл-мөваттаэ». Имам Малик бу китапны 100000 хәдистән сайлап алып, кырык ел төзегән. Иң беренче мәртәбә бабларга аерылып язылган хәдис китабы бу «Әл-мөваттаэ» булып, сәхабәләр һәм табигыйннар сүзләре кертелеп, бөтен хәдисе якынча 1720 кадәр була. Аның эчендә мөснәд 600, мөрсәл 222, мәукуф 613, табигыйн сүзләре 285.

«Әл-мөваттаэ»ны үзеннән турыдан-туры риваять итү максаты белән җиһанның дүрт тарафыннан гыйлем әһелләре төркем-төркем булып имам Малик янына килгән булганнар. Арадашсыз буларак бер меңнән артык адәм риваять итүе риваять ителә. Бу җөмләдән Шафигый, Мөхәммәд бине әл-Хәсән, Ибне Вәһеб, Ибне әл-Касыйм кебек мәшһүр фәкыйһләр (фикыһ галимнәре); Яхъя бине Сәгыйд әл-Каттан, Габдрахман бине Мәһди, Габдерраззак кебек хәдис имамнары; Һарун әр-Рашид, әл-Әмин, әл-Маэмун кебек хәлифәләр була иде. Имам Малик үзе исән вакытында «Әл-мөваттаэ» бөтен ислам дөньясына танылган булып, нөсхәсе һәрбер вилаятькә таралган. Әбү Йосыф хәзрәтләренең «Әл-әмали» исемле хезмәте һәм имам Мөхәммәднең «Әл-асар»ы «Әл-мөваттаэ» белән бер заманда дөньяга чыкса да, шөһрәт һәм игътибарда аралары җир белән күк арасы шикелле калган.

Имам Шафигый «Әл-мөваттаэ» хакында: «Коръән-шәрифтән соң иң дөрес китап», – дигән

---

[1] 1) Ибне Маҗәнең: «Җабир радыяллаһү ганһү әйтте: «Рәсүлуллаһ (саллаллаһү галәйһи вә сәлләм) басып бәвел итүдән тыйды» хәдисе шәрехендә «Нәйл әл-әутар» төзүчесе: «иснадында Гали бине Фадыл бар, ул [хәдис] – мәтрүк (яраксыз). Моңарчы пәйгамбәр галәйһиссәламнең басып бәвел итүдән тыя торган бер хәдис тә дөрес түгел, дип әл-Хафиз (Ибне Хәҗәр) сүзен китергән идек», – ди. Бу бәхәстә Ибне әл-Кайyим «Зад әл-мәгад»та: «Пәйгамбәр саллаллаһү галәйһи вә сәлләмнән басып, утырып бәвел итүе дә риваять ителде, шуңа күрә икесе дә сөннәт», – ди. Болар исә Ибне Маҗә риваятен тәнкыйтьләү була. Казвин хәдисе хакында «Мизан әл-игътидәл»дә (т. 1, б. 224): «Ибне Маҗә үзенең китабын бу ялган хәдисне кертеп ямьсезләде», – ди.

булган[1]. Казый Гаяз: «Ислам галәмендә «Әл-мөваттаэ» дәрәҗәсендә адәмнәрнең игътибарына тиң булган бер китап юк», – дигән.

«Әл-мөваттаэ»да булган бер фазыйләт – мөхәддисләр арасында иң дөрес булганлыгы белән танылган иснадлардан күбесен үз эченә алганлыгыннан. Бу иснад Әхмәд бине Хәнбәл, Исхак бине Раһуя каршында: Мөхәммәд бине Мөслим бине Шиһаб Зөһри – Сәлим бине Габдулла – Габдулла бине Гомәр. Гали бине әл-Мәдәни һәм башкалар каршында: Мөхәммәд бине Сирин – Гобәйдә бине Гомәр һәм Салман – Гали бине Әбү Талиб. Яхъя бине Мәгыйн белән Нәсаи каршында: Ибраһим Нәхәгыйи – Галькамә – Габдулла бине Мәсгуд. Әбү Бәкер бине Әбү Шәйбә һәм башкалар каршында: Мөхәммәд бине Мөслим бине Шиһаб Зөһри – Зәйнелгабидин Гали бине әл-Хөсәен – әл-Хөсәен бине Гали – Гали бине Әбү Талиб. Имам Бохари каршында: Малик – Нәфигъ – Габдулла бине Гомәр.

**Басылган нөсхәләре.** «Әл-мөваттаэ» нөсхәләре берничә булып, араларында кайбер аермалар булуы риваять ителә. Бүгенге көндә ике төрле нөсхәсе басылды. Берсе Яхъя бине Яхъя әл-Масмуди риваяте булып, 1280 дә Түниста һәм ташбасма белән ике томда Мисырда, 1291 дә Дәһлидә, 1889 да Лаһорда басылган. Икенчесе исә Мөхәммәд бине әл-Хәсән әл-Шәйбани риваяте булып, 1291дә Лудьяниҗдә һәм Габделхәй әл-Ләкнәви дөресләве белән ике тапкыр ташбасма белән басылган. Быел 1327 (1909) елда «Мәгариф» акчасы белән Казанда басыла башлады[2].

**Басылган шәрехләре.** 1) «Шәрхү Зәркани», Мөхәммәд бине Габделбакый бине Йосыф Зәркани (1122) хезмәте булган бу шәрех 1280 дә 4 томда Мисырда басылды. 2) «Әл-мосаффа». 3) «Әл-мөсәввә». Һәр икесе Вәлиулла әд-Диһләви әл-Гомәри (1239) хезмәте булып, беренчесе фарсыча, икенчесе гарәпчә. Һәр икесе Һиндстанда басылган. 4) «Әт-тәгъликъ әл-мөмәҗҗид», имам Мөхәммәд риваятендә булган бу шәрех Габделхәй әл-Ләкнәви (1304) хезмәте булып, Һиндстанда һәм Казанда имам Мөхәммәд риваяте булган басылган мәтеннәрнең китап читендә чыккан.

*Басмага әзерләде:*
***Айдар Гайнетдинов,***
*филология фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

[1] Имам Шафигый бу сүзен «Җамигъ Суфьян Сәүри», «Мөсаннәф Хәммад бине Сәлмә» кебек хезмәтләрдән [кыйммәтен] арттыру максаты белән сөйләгән. Аның заманында Бохари һәм Мөслим «Сахих»лары юк иде.

[2] «Мәгариф» тарафыннан безгә бүләк ителгән нөсхәсеннән бу хезмәтнең 1328 (1910)да рабигыль-әүвәл аенда тәмам булганлыгы аңлашылды. Бөтенесе 394 биттә булып, китап читендә Габделхәй әл-Ләкнәвинең «Әт-тәгъликъ әл-мөмәҗҗид»е [белән] бергә гүзәл кәгазь һәм гүзәл хәрефтә хәдис китабына лаек рәвештә басылган.

УДК 745.51

*Л.М. Шкляева*

# УРТА ИДЕЛ БУЕ ТАТАРЛАРЫНЫҢ АГАЧКА РӘСЕМ ТӨШЕРҮ СӘНГАТЕ ҮСЕШЕНЕҢ ТАРИХИ-МӘДӘНИ ЭТАПЛАРЫ

Статья посвящена татарской художественной обработке дерева. Современный этап развития этого искусства берет начало в 1990-х гг. Распространенными остаются традиционные цветочно-растительный и орнитоморфный мотивы орнаментальных узоров в декоре сельских строений. Вместе с тем появляются дома, лишенные своеобразия национальной эстетики. Проявляется негативное влияние процессов глобализации. В целом художественная резьба по дереву периода конца XX – начала XXI вв., включающая творчество мастеров различных этнических групп татар и охватывающая деятельность народных и профессиональных исполнителей остаётся обширной исследовательской областью для искусствоведов.

**Ключевые слова:** татарское декоративно-прикладное искусство, художественная обработка дерева, орнаментальные узоры.

Урта Идел буе татарларының сәнгате тарихын өйрәнү төбәктәге тасвирый мәдәниятнең күпмилләтле булуы сәбәпле шактый катлаулана. Шулай да, тикшеренүчеләрнең фәнни ачышлары[1] татар мәдәниятенең формалашу процессына чынлап та туры килә торган фактлар, традицияләр һәм күренешләрне табарга, ачыкларга мөмкинлек бирә һәм иҗади сәнгатьнең барлык феноменнарын да үз эченә алган этносның тормыш дәвам иткән һәр территориядәге халык сәнгатенең эчтәлегендә чагылыш тапты [Айдаров; Валеева; Валеев, 1970; Валеев, 1969; Валеева-Сулейманова; Червонная, 1987; Худяков, 1923].

Без Урта Идел буе татарларының үзенчәлекле итеп агачка рәсем төшерү сәнгатенең үсешен, чыганакларыннан башлап бүгенге көнгә кадәрге тарихи чорларын аерып куеп, бердәм, бербөтен процесс итеп карыйбыз (безнең эрага кадәр бер мең ел элек – XXI гасыр башлары). Үсеш этапларының хронологик тәртибе тарихи-мәдәни хәлләр белән бәйле иҗади сәнгатьнең барлыкка килү вакыты, формалашуы һәм сүнүгә йөз тотуына бәйле.

Күп кенә сәнгать белгечләре[2] татар халкы һәм аның ата-бабалары меңьеллык дәүләт тарихына ия дип исәпләүче галимнәрнең фикерләре белән килешәләр һәм үткән тарихыбызга түбәндәгеләрне кертәләр: күчмә тормыштагы гуннар империясе; Төрки каганат; Кубрат ханның Бөек Болгарстаны; Хазар каганаты[3]; Идел Болгарстаны (монголларга кадәрге этап, Алтын Урда этабы). Соңыннан Казан

ханлыгы чоры килә. Аннан Россия эпохасы башлана: урта гасырлар чоры, капитализм, социализм һәм хәзерге көннәр. Кайбер фикер каршылыклары төрле этапларның вакыт аралыгын билгеләү мәсьәләсенә генә кагыла.

Татарларның декоратив-гамәли сәнгате үсешенең хронологиясен, агачка бизәкләр ясауны да кертеп, беренчеләрдән булып Ф. Вәлиев[4] интерпретацияли. Агачка бизәк төшерү эволюциясенең түбәнге вакытлы чикләрен нигезләү өчен сәнгать белгече византия дипломанты Приска Панийскийның[5] Атилланың агач сарае турындагы төгәл мәгълүматына мөрәҗәгать итә [Валеев, Валеева-Сулейманова, 2002]. Атилла – 434 елдан 453 елгача гуннар белән идарә итә, үз дәүләтенә төрки [Смирнов, с. 139–147], герман һәм башка кабиләләрне берләштерә, Рейннан Иделгә кадәр булган зур территорияләрдә дәүләт төзи. Ф. Вәлиев, мөгаен, татарларның төрки мәдәниятькә карауларына таянып эш иткәндер һәм аларны хаклы рәвештә төрки сәнгать традицияләрен кабул итеп алучылар дип санаган. Белгечнең фикерен Татарстанның күпчелек галимнәре хуплый[6]. Урта Идел буе татарларының агачка уеп рәсем ясау сәнгатенең генетик нигезләрен анализлаганда төрки сәнгать чыганаклары мәсьәләсе калкып чыга.

Төрки халыкларның гомуми сәнгать тарихы эшләнү стадиясендә. «Төрки Академия» халыкара фәнни үзәге (Астана, 2014)[7] (аңа Казакъстан, Азәрбайҗан, Үзбәкстан һәм Төркия галимнәре керә)[8] тарафыннан төрки сәнгать тарихын чорларга бүлүнең методологик проблемалары әзерләнгән. Төрки дөнья илләренең кайбер галимнәре[9] борынгы төрки тарих скифларга[10] тугандаш булган халыкларның тарихы белән башланып китә дип исәпиләр. Монда территориягә кагылышлы мирас түгел, ә дөньяга караш буенча буыннан буынга күчә бару күз алдында тотыла. «Скифлар дөньясы»ның киңәйтелгән мәгънәсенә хуҗалык итү һәм мәдәният өлкәсендә охшаш билгеләре (скиф җанвар стиле (безнең эрага кадәр VII–III гасыр) сәнгатенең предметларын да кертеп) булган кабиләләргә дә кертелде. Борынгы төрки этносны формалаштыруда скиф һәм хун компонентларының роле турындагы карашлар белән галимнәр җәмәгатьчелеге вәкилләренең шактый өлеше килешә. Гипотеза археологик материалларда раслау таба. Мәсәлән, төрки каганат чоры эшләнмәләрендә «скиф элементы» катламына түгәрәк бляха (калай, сбруй жизе) – умбоны (сүзлектә юк), дүрт таҗ яфракчыклы бляшкалар, ә «хун» катламына түгәрәк тимер җепләр һәм кулланышта булган дүрт яфрак-чәчәксыман бизәк формасындагы бизәнү әйберләре керә [Савинов, с. 138]. Соңыннан төрки телле халыклар, төрки каганатларда яшәүчеләр тарафыннан эшләнгән эстетикага һәм аны техник ысуллар белән гамәлгә ашыруга өстенлек бирә башладылар. Ф. Вәлиев күрсәткәнчә, «агачка уеп рәсем төшерү сәнгате элек-электән күренекле урын алып торган [Валеев, 1975, с. 8]. Татарларда агачка бизәк ясау

сәнгате безнең эрага кадәр 1 мең ел элек башланган.

Моңа төрки каберлекләрдә табылган (безнең эрага кадәр 1 мең елның икенче яртысы) әйберләр мисал булып тора. Алар агачка уеп ясалган бизәкләр белән бизәлгән [Кубарев, с. 114–115][11]. Орнаментның семантикасы төрле мәгънәдә аңлатыла. Тәре формасындагылары Бөек тәңренең барлыгын символлаштырырга мөмкиннәр[12]. Галимнәр төрки мәдәниятнең нигезен тәшкил итүче характерлы билгеләрнең берсе тәңречелек дип күзаллыйлар. Төрки халыкларның нәфис иҗатында бүгенге көнгә кадәр Тәңре һәм Умай образлары популяр санала, аларның агачка уеп ясалган символик сурәтләре киң таралган һәм Урта Идел буендагы авыл өйләрендәге бизәкләр белән тыгыз бәйләнештә.

Казан татарларының архитектурасында агачка рәсем ясау сәнгатенең эволюциясе болгар чорының башларына каравын Ф. Вәлиев VII–X гасырлар белән бәйли, чөнки нәкъ менә шушы чорда бу елларда төрки телле «яшәүчеләр» барлыкка килә [Валеев, 1975, с. 8]. С. Червонная Идел буендагы болгарларның сәнгате тууын башкача аңлата[13] – VIII гасырның икенче яртысы белән бәйли [Червонная, 1987]. Шуның белән бергә ул инде VI–VII гасырларда ук «Татарстан җирләренә Төрки каганатның кабиләләре үтеп керүен» билгеләп үтә.

Ф. Вәлиевнең фикерләре бүгенге заманның археологик күрсәткечләре белән раслана. Алар Урта Иделгә болгарларны күчерүнең беренче дулкыны Кубрат ханның Бөек Болгарстаны җимерелү белән бәйле икәнлеген дәлиллиләр. Урта Идел болгарлары акрынлап агач өйләрдә яши башлыйлар. Шәһәрләр барлыкка килә [Хузин, 2005, с. 156], VII гасырның икенче яртысы – VIII гасырның беренче яртысына хас булганча һәртөрле һөнәрчелек һәм нәфис сәнгать үрнәкләре белән шөгыльләнүче Идел буе болгар-мастерлары барлыкка килә [Багаутдинов, Хузин, 2006, с. 116]. Уеп ясау сәнгате үзенә генә хас булган үзенчәлекләре белән аерылып торган, ул бигрәк тә даланың җанвар стиле һәм угро-фин компонентларының күренә башлавы белән бәйле.

Даталардагы төрлелек болгарларның Иделгә икенче миграцион дулкынына да карый. Әгәр «737 елда Хазар каганаты гарәпләрдән җиңелгәннән соң болгарларның шактый өлеше Урта Иделгә китсә» [Халиков, 1969, с. 74], VIII гасырда инде «Хазар каганатыннан күченгән болгарларның Идел буена» [шунда ук, с. 54] эстетик яктан өстенлек бирү йогынтысы барлыкка килә башлый. Салтова-маяцкие (?) үсемлек мотивлары болгар чорының тәүге вакытларында декоратив-гамәли сәнгатьнең төрле предметларында сурәтләнгән[14]. Хәзерге тикшеренүчеләрнең бер өлеше [Измайлов, с. 128] IX гасыр азагында болгарларда дружина оешмасы шактый үсеш ала һәм дәүләт төзелә башлый дигән нәтиҗәгә килә, ә Ф. Вәлиев исә моны монгол чорына кадәрге мәдәният үсеше белән бәйли, аның вакытын XIII гасырның башы – X гасыр белән билгели.

Аның фикерен Д. Вәлиева да куәтли һәм Идел Болгарстаны дәүләте Х гасырда барлыкка килгән дип саный [Валеева, 1983]. Идел Болгарстаны 922 елда ислам динен кабул итә һәм акрынлап мөселман дөньясы болгарга үзенең мәдәниятен кертә башлый, бигрәк тә орнаментлылык һәм шартлы декоративлылык кебек сәнгатьнең төп иҗади принципларын [Червонная, 2008]. Шуның белән беррәттән, Х гасыр азагына кадәр Идел Болгарстанында Хазар каганатының йогынтысы зур була [Зимоньи, с. 24] (965 елда Святослав хазарларны тар-мар итә). Салтово-маяцкие чәчәк мотивлары җәннәт бакчасы идеясен гәүдәләндерүче декоратив формаларны үстерү өчен үзенчәлекле база буларак хезмәт итәләр. Нәтиҗәдә ислам сәнгатендә киң таралган чәчәк-үсемлек орнаментлары элементларыннан торган композицияләр киң тарала башлый. «Болгарларның декоратив-гамәли сәнгатендә төрки һәм көнчыгыш традицияләренең берләшүе үсеш ала» [Измайлов, с. 556].

Тел берлегенә, матди һәм рухи мәдәniяткә нигезләнгән болгар халкын кушу шактый соң, XII–XIII гасыр башларында була. «Идел-Кама Болгарстаны җирләрендә, хәзерге вакытта, монгол чорына кадәрге 170 тирәсе шәһәрчек билгеле [Хузин Ф. Булгария – страна городов, 2006, с. 152]. «Болгарларда агачка уеп рәсем ясау сәнгатенең таралышына Биләрдә табылган 21×9×1 сантиметрлы имән пластинка дәлил була ала. Табылдыкның датасы XIII гасыр белән күрсәтелгән. Пластинка үсемлек характерындагы бизәк белән уелган бордлар белән бизәлгән» [Валеев, Валеева-Сулейманова, 2002, рис. 9]. Агачны сәнгатьле эшкәртүне мөстәкыйль һөнәрчелеккә әйләндерү очракларының булмавына кагылышлы мәгълүматлар шактый.

«XIII–XV гасырларда Джучи империясе кысаларында, соңыннан урыс чыганакларында – “Алтын Урда” исемен алган татар этник берлеге барлыкка килә башлый» [Валеева-Сулейманова, 1995]. Дәүләткә Урта Азия, хәзерге Казакъстан җирләренең төньяк-көнбатыш һәм үзәк өлешләре, Төньяк Кавказ, кыпчак кабиләләре һәм Идел Болгарстаны керә. Сәнгать белгечләре бу чорның иҗат үзенчәлекләрен төрлечә бәялиләр. Ф. Вәлиев, мәсәлән, «күчмә тормыштан килүчеләр болгарның югары игенчелек культурасына нинди дә булса яңалык алып килә алмыйлар», дип исәпли [Валеев Ф., 1975, с. 14]. Урта Идел халыклары сәнгатендә бу чорда көнбатыш стиленең йогынтысы зур була. Алтын Урда чорындагы Идел Болгарстаны халкының тирә-юньгә мөнәсәбәте Болгар төзелешләрендәге орнаментлы бизәкләрдә һәм күпсанлы кабер ташларында чагылыш тапкан.

Татарның урта гасыр дәүләте – Казан ханлыгында (1445–1552 еллар) агач сәнгате үзенчәлекле, декоратив бизәкләргә бай булган югары дәрәҗәгә ия була [Сказания...]. Агачны сәнгатьле эшкәртү мөстәкыйль һөнәрчелеккә әйләнә [Валеев, 1975, с. 20]. XV–XVI гасырларда татар сәнгате традицияләренең

үрнәкләре (Казан ханлыгы чоры) Казан артында мул тормышта яшәүче татарлар төзегән йорт-җирләрдә дә күренә һәм алар VIII гасырда Россия чорындагы татарларның агачка уеп рәсем ясау сәнгатенең төрлелеген билгели [Валеев, 1975, с. 20][15]. Торак йортлардагы декорның гадәттән тыш үзенчәлеге XV–XVI гасырдагы кирпичташ корылма полихромиясендә чагылыш таба [Воробьев, с. 2]. Төзелеш композициясенең сәнгатьле элементлары булып чокып, контурлы техника, тармаклы, нурлы-таҗ яфраклы рамнар белән бизәлгән фронтон (өйнең алгы ягында түбәнең ике кыегы белән чикләнгән өчпочмак формасындагы өлеше) карнизлар һәм куышлар санала [Бикчентаев, 1957]. Буйлы һәм очлаеп торган куыш формалары «көнбатышның таш-кирпич архитектурасы күренешләренә якын» була [Валеев, 1975, с. 30]. Фронтон ачыклыклар төрле бизәкләр хасил итүче агач тәрәзә рамнары белән тулыландырылган[16].

Сәнгать белгечләре арасында Казан ханлыгының вакыт аралыкларын билгеләү (XV гасыр уртасы – XVI гасыр уртасы), Казан ханлыгын Руська кушу датасы һәм Россия империясенә (1552–1917 еллар) әйләнүе буенча фикер каршылыклары юк. «Агач архитектурасына килгәндә, милли үзенчәлекләр соңгы гасырлар дәвамында аз үзгәреш кичерделәр. Россия чорының XIX гасыр уртасы – XX гасыр башы өйләренең алгы күренешләре, коймалар, бигрәк тә капкалар полихром декор уемнары белән баетылуы белән аерылып тора [Гайнутдинов, 1960, 1983]. Тәрәзә йөзлекләренең ачык орнаментлары сакланган. XIX гасырның икенче яртысында бай авыл төзелешләренең тышкы күренешендә казан архитектурасы классицизм стиленең йогынтысы аеруча сизелә башлый [Дульский, 1920; Нугманова Г. Архитектура.., 2000; Нугманова Г. Татарская.., 2000]. Өйләрнең тышланган почмакларына пилястр (бер ягы белән стенага кереп торган дүрт кырлы колонна) күренеше бирелә. Фасад һәм фронтон күренешен сәнгатьчә хәл итү өчен симметрик төстә урнашкан тар колонна һәм фризлар (стена, идән, түшәм, келәм кебекләрнең читенә бизәкләп ясалган кайма) үтеп керә [Айналов, Валеев, Кадырова...; Маковецкий, с. 30–50]. Агачка бизәк ясау сәнгате торак экстерьерларын бизәү өчен генә түгел, ә бәлки һәртөрле кирәк-ярак, сандык, йорт җиһазы кебек әйберләр эшләгәндә дә киң кулланыла башлый. Сәнгать белгечләре[17] XIX гасыр башында милли стильнең бер билгесе итеп бай татар өйләре интерьерындагы уемлап ясалган ишекләрне күрсәтәләр. Н. Халитов билгеләп үткәнчә, XIX гасыр башында «Шәһәр һәм авыл архитектурасының үсеше төрле юллар белән бара» [Халитов, 1991, с. 62].

Урта Идел буе татарларының агачка рәсем төшерү сәнгатенең совет чорындагы эволюциясенең чикләре фәнни әдәбиятта төгәл билгеләнгән. Түбәнге чик революциядән соңгы 1920 еллар белән, ә югары чик 1990 еллар белән исәпләнелә. Сугышка

кадәр һәм сугыштан соң өйләрнең экстерьерына уеп рәсем ясау сәнгате контурлы һәм пропильле техника белән эшләнгән төгәллек белән характерлана. Геометрик, соляр һәм зооморф мотивлар белән бергә чәчәкле-үсемлекле орнаментларның өстенлек алуы да мәгълүм [Валеев, 1969]. XX гасырның 1940 еллар азагында сурәтләрнең күп төрлелеге дә күзгә ташлана. Биш почмаклы йолдызлар, күккә күтәрелүче ракеталар, урак белән чүкеч һ.б. шундый элементларны үз эченә алган кампозицияләр дә барлыкка килә. «50 елларда авыл төзелешләрен бизәгәндә яңа сәнгать чаралары барлыкка килә, мәсәлән, фронтоннарны декорлаштырганда» [Валеев, 1975, с. 68]. Капкалар кисеп ясау ысулы белән чагыштырмача аз бизәләләр. 1957 елның март аенда ТАССР дәүләт музееның гыйльми советы секциясендә Әтнә, Дөбъяз, Тукай, Балтач һ.б. районнарны өйрәнгән А.Г. Бикчәнтәев чыгыш ясый. Тикшеренүенең максаты милли торак йортларны төзегәндә кулланылучы традицион планлаштыру ысулларын өйрәнү һәм авылдагы төзелеш практикасына шуларны киң масштабта кертү була [Бикчентаев, 1957].

Агачка сурәт ясау сәнгате 1960 елларда киң колач ала һәм 20 елдан артык дәвам итә. Дистә еллар дәвамында (1960–1973) Ф. Вәлиев экспедицияләргә йөреп материал туплый. Ул бер үк вакытта Урта Идел буе татарларының архитектура-сәнгать традицияләрен дә өйрәнә. Сәнгать белгече үзенең тикшеренүләрендә йортларны матурлауның традицион принципларын декоратив бизәлештә (резкой орнаментации и полихрамной раскраске) күрергә мөмкин булуын билгеләп үтә [Валеев, 1975, с. 60]. XX гасырдагы агачка уеп сурәт ясауның төп үзенчәлекле билгеләре аерым татар авылларында сакланып калган. Мәсәлән, Баксан авылындагы[18] күпчелек өйләрдәге тәрәзә йөзләренең югары өлешен пар аккошлар сурәтләре бизи.

Бүгенге көндә агачны үзенә бер төрле сәнгатьле итеп эшкәртү башлыча өйләрнең, коймаларның һәм капкаларның экстерьерында декорация буларак сакланып калган. Узган гасырның 90 нчы елларында яңа үсеш этабы башлана. Торак йортларны уеп ясау ысулы белән бизәгәндә йорт хуҗалары үзләренең нинди дингә карауларын да ачыктан-ачык күрсәтә башладылар. Бу бигрәк тә Нижегород татар осталарының иҗатында ачык чагыла. Авыл төзелешләрендәге декорда һаман да шул традицион чәчәкле-үсемлекле һәм орнитоморф мотивларның орнаметлы бизәкләре зур өстенлек алып тора. Шуның белән бергә татар өенә, аның чын йөзенә туры килмәгән, милли эстетик үзенчәлекләрдән азат булган торак йортлар да барлыкка килә башлады. Глобальләштерү процессының тискәре йогынтысы сизелә. Тулаем алганда, агачка рәсем төшерү сәнгате XX гасыр азагы XXI гасыр башларында, татарларның бөтен этник группаларына караган осталар иҗатын да, халык һәм профессионалларның эшчәнлеген дә кертеп караганда, сәнгать белгечләре өчен киң тикшеренү объекты булып кала бирә.

Урта Идел буендагы татарларның агачка үзенчәлекле рәсем төшерү сәнгатенең үсеш тарихы шуны күрсәтә – күп гасырлар дәвамында эволюцион процесс, үзенә аеруча этник үзенчәлекләрне туплап, халыкның үткән тарихи язмышын сурәттә чагылдырып һәм орнаментлы бизәкләрнең символик мәгънәви эчтәлеген бирергә тырышып, өзлексез дәвам иткән.

## Искәрмәләр

[1] А.Х. Халиков, Ф.Ш. Хузин, А.Г. Ситдиков и др.

[2] Ф. Валеев, Д. Валеева, Г. Валеева-Сулейманова, Р. Султанова, Н. Халитов и др.

[3] Большая часть болгар после распада Великой Болгарии оказалась в составе Хазарского каганата, археологически представленного салтово-маяцкой культурой [3, с. 119].

[4] Фуад Хасанович Валеев (1921–1984) – доктор искусствоведения.

[5] Приск Панийский (др.-гр.) – византийский дипломат, историк и писатель V века. В 447 году был в составе посольства к вождю гуннов Атилле. Работа «Византийская история и деяния Атиллы в восьми книгах» не сохранилась. Позднейшие историки Евгарий, Иордан, Константин Багрянородный использовали труды Приска Панийского.

[6] У татарского народа нет единого этнического корня. Среди его предков были кроме волжских булгар, многие степные племена (от гуннов до кыпчаков и ногайцев), местные финно-угры, славяне и др. [37, с. 4].

[7] Р.Г. Абдуллаева, К.Б. Акилова, А.С. Галимжанова, В.Г. Керимли, Э.А. Саламзаде и др.

[8] В искусствознании Казахстана, Азербайджана, Узбекистана и Турции существуют национальные истории искусства.

[9] Решение конференции, организованной Международным научным центром «Тюркская Академия» (Астана, 2014).

[10] По определению, принятому большинством ученых, скифы – это ираноязычные племена, обитавшие в Северном Причерноморье в VIII в. до н.э. – IV в.н.э.

[11] 13 – деревянные подвески, 16 – деревянные бляхи из кургана 3 (Уландрык I по В.Д. Кубареву); 14 – деревянная подвеска, 15 – деревянная бляха из кургана 1 [23].

[12] Тенгри – древнетюркское божество [25, с. 500]

[13] Светлана Михайловна Червонная (р. 1936 г.) – доктор искусствоведения.

[14] Артефакты Большетарханского могильника.

[15] «Отдельные постройки датируются не ранее конца XVIII века» [9, с. 9].

[16] Такой тип оконных переплетов напоминает азербайджанские шебеке.

[17] Двери в доме купца Бакирова в с. Большой Менгер [35, с. 96].

[18] Мамадышский район РТ.

## Әдәбият

*Айдаров С.С.* Архитектурные проблемы теории и истории архитектурно-градостроительного развития региона Концепция отражения регионального своеобразия архитектуры Татарстана // Вестник архитектуры и урбанистики № 2 (5). Казань, 2013. С. 19–22.

*Айналов Р.А., Валеев Р.М., Надырова Х.Г., Хайрутдинов Р.Р., Чудинова Т.С.* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Казань: Мастер Лайн, 1999. 458 с.

*Багаутдинов Р., Хузин Ф.Ш.* Ранние булгары на Средней Волге // История татар с древнейших времен: в 7 т. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. 956 с.

*Бикчентаев А.Г.* Сельское жилище Татарской АССР. Казань: Татполиграф, 1957. 31 с.

*Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Токсубаева Л.С.* Декоративное оформление сельского жилища в Казанском Поволжье. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 28 с.

*Валеева Г.Ф.* Булгарское искусство // История татар с древнейших времен: в 7 т. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. 956 с.

*Валеева Д.К.* Искусство волжских булгар (X – нач. XIII вв.). Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 132 с.

*Валеев Ф.Х.* Архитектура и искусство Волжско-Камской Булгарии // Ученые записки Казанской государственной консерватории, вып. 4, Казань, 1970.

*Валеев Ф.Х.* Архитектурно-декоративное искусство казанских татар. Сельское жилище. Йошкар-Ола: Марийское кн. изд-во, 1975. 91 с.

*Валеев Ф.Х.* Орнамент казанских татар. Казань: Татаполиграф, 1969. 203 с.

*Валеев Ф.Х, Валеева-Сулейманова Г.* Древнее искусство Татарстана. Казань, 2002.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Декоративное искусство Татарстана 1920 – начала 1990-х годов. Казань: Фэн, 1995. 192 с.

*Воробьев Н.И., Валеев Ф.Х.* Народное прикладное искусство татар Поволжья. М.: Наука, 1964. 9 с.

*Гайнутдинов И.Г.* Деревянное зодчество казанских татар. Резные решетки на тесовых оградах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1960. – 15 с.

*Гайнутдинов И.Г.* Сельская усадьба казанских татар середины XIX в. // Архитектурное наследство. М.: Стройиздат. № 31, 1983. С. 57–65.

*Дульский П.М.* Искусство казанских татар. М.: Центральное издательство народов С.С.С.Р., 1925. 58 с.

*Дульский П.М.* Несколько слов по поводу орнаментировки татарских памятников 16–17 веков // Материалы по охране, ремонту и реставрации памятников ТССР. Казань: отдельный оттиск в пятидесяти экземплярах, 1929. 27 с.

*Дульский П.М.* Классицизм в казанском зодчестве. Казань: Госиздат, 1920. 20 с.

*Зимоньи И.* Западноевропейские письменные источники о булгарах // История татар с древнейших времен: в 7 т. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. 956 с.

*Нугманова Г.Г.* Архитектура казанских татар: российское законодательство и этноконфессиональные особенности // Нугманова Г.Г. Истоки и эволюция художественной культуры тюркских народов. Казань, 2008. С. 216–222.

*Нугманова Г.Г.* Татарская городская усадьба Казани середины XIX – начала XX века: автореф. дис. ... канд. ист. наук. М.: ГИИ, 2000.

*Измайлов И.* Ислам и мусульманская культура в Волжской Булгарии // История татар с древнейших времен: в 7 т. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. 956 с.

*Кубарев В.Д.* Курганы Улындрыка. Новосибирск: Наука, 1987. 299 с.

*Маковецкий И.В.* Заметки о памятниках деревянной архитектуры Поволжья // Сообщения института истории искусств №1. М.: Изд-во академии наук СССР, 1951. С. 30–50.

*Неклюдов С.Ю.* Тенгри // Мифы народов мира: энциклопедия. М.: Российская энциклопедия, 1994. Т. 2. С. 500–501.

*Савинов Д.Г.* Народы южной сибири в древнетюркскую эпоху. Л.: ЛГУ, 1984. 174 с.

Сказания А. Курбского. СПб.: Изд. Устрялова, 1868. 23 с.

*Ситдиков А.Г., Хузин Ф.Ш.* Древняя Казань глазами современников и историков. Казань: Фест, 1996. 448 с.

*Смирнов А.П.* Гуннский элемент в культуре волжских булгар. М., 1971. С. 139–147.

*Червонная С.М.* Современное исламское искусство народов России. М.: Прогресс-традиции, 2008. 552 с.

*Червонная С.М.* Искусство Татарии. История изобразительного искусства с древнейших времен до 1917 г. М.: Искусство, 1987. 352 с.

*Халиков А.Х.* Древняя история Среднего Поволжья. М.: Наука, 1969. 396 с.

*Халиков А.Х.* Приказанская культура. М.: Наука, 1980. 128 с.

*Халитов Н.Х.* Памятники архитектуры Казани XVIII – начала XIX веков. М.: Стройиздат, 1991. 192 с.

*Халитов Н.Х., Халитова Н.Н.* Стили и формы средневековой архитектуры Казани: историко-архитектурное исследование. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 351 с.

*Худяков М.* Казанский музейный вестник № 1. Казань: Комбинат Издательства и Печати Т.С.С.Р., 1924. С. 23–28.

*Худяков М.В.* Деревянное зодчество казанских татар // Казанский вестник № 1–2. Казань, 1923.

*Хузин Ф.Ш.* Предисловие к тому // История татар с древнейших времен: в 7 т. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. 956 с.

*Хузин Ф.Ш.* Булгария – страна городов // История татар с древнейших времен: в 7 т. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. Казань: РухИЛ, 2006. 956 с.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 351.852.13

***Н.В. Герасимова***

# 1920 ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАННЫҢ КАНТОН (РАЙОН) МУЗЕЙЛАРЫНДАГЫ СӘНГАТИ КОЛЛЕКЦИЯЛӘРНЕҢ ТОРЫШЫ

## (ТАССР мәгариф халык комиссариаты (ТНК) Академүзәге музей комиссияләре анкетасы буенча)

В статье предпринята попытка изучить состояние художественных коллекций кантонных музеев в середине 1920-х гг. Формирование данных коллекций осуществлялось преимущественно силами местных отделов народного образования из предметов, национализированных или закупленных у местного населения, и потому носило хаотичный характер. В дальнейшем коллекции пополнялись экспонатами из музейного фонда Татарской республики. Анкеты Музейной комиссии Академцентра ТНКП являются ценным источником, позволяющим установить адреса музеев, кадровый состав, наличие художественных коллекций. Также анкеты позволяют выявить круг проблем, с которым сталкивались кантонные музеи.

**Ключевые слова:** музейное дело в 1920-х гг., кантонные музе ТАССР, деятельность Музейной комиссии Академцентра ТНКП.

1923 елның 1 сентябреннән ТАССР музей эшләрен оештыру ТНКП Академүзәге каршындагы махсус музей комиссиясе [Собрание узаконений…, с. 1] карамагына тапшырыла (бу комиссия музей эшләре һәм сәнгати, борынгы һәйкәлләрне, шулай ук табигатьне саклау буенча 1919 елның августыннан эшләүче бүлек нигезендә оешкан була). ТАССРдагы сәнгати һәм борынгы архитектура, скульптура, рәсем сәнгате һәм башка зур әһәмияткә ия һәйкәлләрне саклау шушы комиссия җаваплылыгына күчә. Музей бүлеге ярдәме белән 1920 еллар башында ук республиканың кайбер шәһәрләрендә берничә төрле коллекцияләрдән торган җирле край музейлары оеша. Музей комиссиясе алар эшчәнлегенә юнәлеш бирә: фондлар формалаштыруга ярдәм итә, аңлашылмаган сорауларына ачыклык кертә, мөмкинлегеннән чыгып, финанс ярдәме дә күрсәтә.

Комиссия, кантон музейлары эшчәнлеген контрольдә тоту максатыннан, музейларга отчет формасындагы анкеталар җибәрә. Аларның күбесе Татарстан Республикасы Милли архивында саклана. Ул анкеталар Татарстанда музейлар төзелеше тарихы белән кызыксынучыларга күп кенә сорауларны ачыкларга ярдәм итәләр. Иң мөһиме: аларда музейның төгәл атамасы, адресы, эшли башлау датасы, коллекцияләр тупланмасының чыганаклары, һәр бүлектәге һәм барлык экспонатлар исемлеге теркәлгән, кайбер анкеталарда музейда эшләүчеләр турында мәгълүматлар бар, учреждениедәге үзгәрешләр һәм андагы эш тәртибе күрсәтелгән. Анкеталарны өйрәнү вакытында

ачыкланганча, ул чорда республикада Зөя (Свияжск), Тәтеш, Алабуга, Мамадыш шәһәрләрендәге контон музейларында сәнгати коллекцияләр тупланган булган.

1920 елда, республикада беренче булып, Алабуга шәһәренең Морская урамындагы Заитов йортында җирле край музее эшли башлый (мөдире – Е.С. Кроль) [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 719, л. 88]. Анкеталарда бу музейның сәнгати коллекциясе хакында мондый юллар бар: «...55 картин, несколько альбомов русской живописи Третьяковской галерей, 80 вещей фарфора и хрусталя, бронзовые статуэтки, отобранные у местной буржуазии» [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 719, л. 11]. 1923 елда башкачарак мәгълүматлар теркәлгән: картиналар саны 56, ә фарфордан һәм хрустальдән эшләнгән экспонатлар 65 кенә [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 719, л. 89]. 14 экспонатның ничек юкка чыгуы турында бернәрсә дә әйтелмәгән.

Тәтештә оештырылган җирле край музее турында мондый юллар сакланган: «...был основан 11 июня 1920 года по инициативе внешкольного подотдела Тетюшского КОНО. Часть экспонатов – национализирована, часть привезена Казанью и куплена Политпросветом...» [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 491, л. 81]. Бу мәгълүматлар 1923 елның 28 июнендә музей комиссиясенә тапшырыла. Әмма шушы ук елның 27 июлендә комиссиягә яңа анкета җибәрелә. Анда ассызыклап болай диелгән: «...экспонаты музея приобретались исключительно на средства наробраза, путем закупки последних в кантоне или Казани» [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 491, л. 92]. 1922 елда музейдагы барлык 632 экспонатының 226 сы сәнгати коллекциягә карый [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 313, л. 50]. Алардан тыш музейда 173 томны тәшкил иткән (күп өлеше сәнгатькә кагылышлы) китапханә була [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 313, л. 50]. Бу мәгълүматларга нигезләп 1926 ел анкетасында музейга түбәндәге характеристика бирелгән: «до передачи музея в Педтехникум имел не краеведческий, а художественный характер. Первым по количеству экспонатов нужно считать отдел живописи. Искусство здесь представлено:

1. В фамильных портретах дворян Сазоновых

2. Живописи новейших художников: Фешин, Зарубин, Дубовской, Гауш

3. Акварельных рисунках: Рерих, Бучкури, Билибин-Чемберс, Дульский

4. Графика – Митрохин, Нарбут

Следующий по количеству идет отдел фарфора и бронзы: чайная и столовая посуда старинного рисунка, подсвечники восточных стилей (египетский, ассирийский китайский), фарфоровые и бронзовые статуэтки и др. вещи. Есть в ограниченном количестве мрамор, терракота и шитье бисером» [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 957, л. 23].

Гомумән Тәтеш музее анкеталары мәгълүматка бай һәм тәфсилле язылган. Моннан тыш, фәкать шушы музейда гына тупланмаларның җентекләп төзелгән

исемлеге бар [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 491, лл. 94–96], ул, экспонатлар санын гына түгел, коллекциянең сәнгати кыйммәтен күзалларга һәм һәр экспонатның язмышын эзлекле өйрәнергә мөмкинлек бирә. Әмма музей хезмәткәрләре анда тупланган экспонатларның һәммәсенең дә кыйммәтен аңлап бетермиләр, әйтик түбәндәге әсәрләрнең сәнгати кыйммәте тулысынча яктыртылмаган: мәсәлән, «Христос в терновом венце» – майлы буяу, «Мадонна» – майлы буяу, Александр I һәм Николай I бюстлары – бронза һ.б. [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 957, л. 23].

1921 елның 2 июнендә Зөя (Свияжск) шәһәрендә (гомумбелем тибындагы) кантон музее ачыла. Ул Барановский урамындагы Успение ирләр моностыренның төп корпусында урнашкан була. Музейның сәнгать бүлегендә 1923 елда 196 предмет исәпләнә, аларның күпчелегең Казан музее фондыннан алынган фарфор һәм бронзадан эшләнгән әйберләр тәшкил итә. Алардан тыш, анкетада түбәндәге юллар да теркәлгән: «...коллекции картин, фарфора, коллекции кустарных художественных предметов, приобретенных на средства местного кантона в период времени, предшествующему открытию музея» [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 491, л. 26] (сүз, мөгаен, ул әйберләрнең шәһәр кешеләреннән алынган булуы турында бара). Музей ачылганнан соң шәһәр халкы андагы коллекцияләрне баетуга өлеш кертүләрен дәвам итәләр: әйтик, 1925 ел отчетында, аерым гражданнар китергән «книги, картины, рукописи» исәбенә бүлеккә тагын 9 экспонат өстәлде, диелгән [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 957, л. 31].

1923 елда Мамадыш кантоны җирле край музее үзенең эшен башлап җибәрә (ул элеккеге Серебряков типографиясе бинасында урнашка). Аның анкетасы аеруча кызыклы. Анда фактларга коры аңлатма гына бирелмәгән, музей тормышы хисчән тасвирлама белән яктыртылган: «Средств на музей нет. Никаких. Штатов на музей нет. Никаких. Заведующий – он же технический работник, идейный, сторож, уборщик – и что угодно. Материалы нет. Никаких» [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 719, л. 11]. Алга таба анкетага музейның директор тарафыннан төзелгән (аның фикеренчә, бик яхшы) планы теркәлгән. Кызганычка каршы, директор анда үзенең тулы булмаган имзасын гына калдырган, шуңа күрә әлегә аның шәхесен ачыклау мөмкин түгел. Директор музей эшенә бик игътибарлы булса да, анкетада экспонатлар исемлеген тулы ачыкламаган, ә күләм күрсәткечләре белән генә чикләнгән: «картин в музее: масло – 12, акварель – 6, пером – 1, театральных постановок – 86, кустарной промышленности – 2, скульптуры – 3, прикладного искусства – 6. Итого 249 экспонатов» [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1, е.х. 491, л. 51].

1922 елда Козьмодемьянск музее да ТАССР мәгариф халык комиссариаты Академүзәге карамагында була, гәрчә ул ТАССР оешканнан соң аның территориясенә кермәсә дә. Кызганычка

каршы, Козьмодемьянск музее экспонатлары хакындагы статик мәгълүматлар да, шулай ук, 1921 елда музейның тормышы турында кыскача хисап белән генә чикләнелгән [НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 313, л. 54]. Әйтик, анкетадан күренгәнчә, сәнгати коллекциядә 305 тасвирый сәнгать, 11 сынлы сәнгать, 197 фарфордан эшләнгән экспонат булган. Башка бернинди дә мәгълүмат юк. Өйрәнелгән материалларга таянып 1920 еллар уртасында кантон музейларындагы сәнгати коллекцияләренең торышы хакында шундый нәтиҗәгә киләсең: әлеге коллекцияләр, нигездә халык мәгарифенең җирле бүлекләре тарафыннан национализацияләнгән яки җирле халыктан сатып алынган предметлар хисабына тупланган, шуңа күрә алар билгеле бер тәртипкә салынмаган. Коллекцияләрнең кыйммәти дәрәҗәсе һәм сыйфаты аларның элекке хуҗаларының сәнгати зәвыгын чагылдыра. Коллекцияләрне анкеталарга нигезләп характерлау мөмкин түгел, чөнки анда экспонатларның тасвирламалары юк (фәкать Тәтеш музее гына бу яктан аерылып тора). Алга таба кантон музейлары Татарстан автономияле республикасы музей фондындагы экспонатлар хисабына тулыландырылган. Шулай да, искә алынган җитешсезлекләргә карамастан, музейларның адресларын, анда эшләүчеләрне ачыклауда, сәнгати коллекцияләрне барлауда анкеталар мөһим чыганак булып санала. Шулай ук анкеталар шул чор музейларына хас проблемаларны – квалификацияле кадрлар җитмәүне, коллекцияләр формалаштыру, хезмәткәрләргә түләү һәм кантон музейлар урнашкан биналарны гамәлдә тоту, суык чакта ягып җылыту өчен (әйтик, музей карарга килүчеләрнең анда май аеннан башлап, октябрьгә кадәр генә, ягъни көннәр җылы торганда гына йөри алганнар) акча җитмәвен тулы күзалларга мөмкинлек бирә.

**Чыганаклар**


Собрание узаконений и распоряжений рабочего и крестьянского правительства Автономной Татарской республики. Казань: Издание ЦИК и СНК АТССР. №47. 1923.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 719, л. 88.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 719, л. 11.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 719, л. 89.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 491, л. 81.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 491, л. 92.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 313, л. 50.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 957, л. 23.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 491, лл. 94–96.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 957, л. 23.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 491, л. 26.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 957, л. 31.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 491, л. 51.

НА РТ. Ф. Р-3682, оп. 1 е.х. 313, л. 54.



***Герасимова Наталья Владимировна,***

*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

*И.К. Заһидуллин*

# КИЛӘЧӘККӘ ҮСЕШ ЮЛЛАРЫН БИЛГЕЛӘП
## (Җиде томлык «Бик борынгы заманнан башлап татар тарихы» басылып бетү уңаеннан)

Статья написана по случаю издания последних томов семитомной «Истории татар с древнейших времен», подготовленной в Институте истории им. Ш. Марджани АН РТ. Освещаются причины и предпосылки подготовки академического труда, определяется научная новизна издания, дается краткая характеристика каждому тому.

**Ключевые слова:** семитомная «История татар с древнейших времен», татарский народ, развитие исторической науки в Татарстане, С.Г. Кляшторный.

XX гасырның күренекле татар зыялыларыннан берсе Йосыф Акчура, 1908 елда Төркиягә бөтенләйгә китеп барырга карар кылгач, «Вакыт» газетасында татар мәгарифенә багышланган мәкаләләр бастыра. Ул үзенең «Мәдрәсәләрдә тарих дәресе укыту турында» исемле хезмәтендә: «Без халкыбыз тарихын булдыру бурычын үзебез үтәргә тиешле. Моңа без бурычлыбыз. Милләтебез тарихыннан сибелгән, таралган нәрсәләрне үзебез эзлик. Булдыра алган кадәрен табып-җыеп, мәйданга куйыйк. Шул юлда хезмәт итәргә сәләтле, яраклы эзләүчеләрне, алар эшен оештыручы оешмалар булдырыйк», – дип яза [Акчура, 2012, б. 39]. Күренекле җәмәгать эшлеклесенең бу фикере ул заман зыялыларының уртак теләген әйтеп бирә. Шушы иҗтимагый заказны үтәп, бер төркем галимнәр әлеге юнәлештә актив эшлиләр һәм матур нәтиҗәләргә ирешәләр. Хәсәнгата Гәбәши, Ш. Мәрҗани фикерләрен үстереп, «Төрек ыруглары» (1897), «Мохтасар тарих кавем төрки» (1898), «Мөфассал тарихе кауме төрки» (1909) шәкертләргә уку әсбаблары итеп китаплар яза һәм беренче тапкыр төрки тарихны этапларга аера. Ш. Мәрҗани яклаган болгарчылык теориясе нигезендә фәнни эзләнүләр алып барган Гайнетдин Әхмәров «Болгар тарихы» (1909), «Казан тарихы» (1910) һәм башка хезмәтләре белән укучыларны сөендерә.

Зәки Вәлиди мәдрәсәләр өчен уку әсбабы буларак язган «Төрек-татар тарихы» (1912) һәм «Кыскача рәсемле төрек-татар тарихы» (1915) хезмәтләрендә төрки-татар тарихын Евразия масштабында карый, аны үзенчә этапларга бүлә. Һ. Атласи «Себер ханлыгы» (1911), «Сөен-Бикә» (1914), «Казан ханлыгы» (1920), хезмәтләрен язып дан казана.

ТАССР оешкач, 1921 елда республиканың Халык мәгарифе наркоматы каршында ачылган Академик үзәк милли тарихны өйрәнү һәм язуны яңа дәрәҗәгә күтәрә. Ул фәнни эзләнүләрне координацияли, яңа фәнни оешмалар, структуралар булдыра, монографияләр һәм татар

мәктәпләре өчен дәреслекләр язуны һәм бастыруны оештыра, Мәскәү һәм Ленинград галимнәрен җәлеп итеп, фәнни кадрлар әзерләүне җайга сала. 1920 нче еллар башында татар тарихын һәм әдәбияты тарихын өйрәнү юнәлешләренә нигез салучыларның – Г. Ибраһимовның, М. Худяковның, В.Ф. Смолинның, Г. Рәхимнең, Г. Гобәйдуллинның, Г. Сәгъдинең, Җ. Вәлидинең, Н.И. Воробьевның һ.б.ларның – хезмәтләре дөнья күрә [Абдрашитова, с. 101–111].

1920 нче еллар азагында СССРда тарихны сыйнфый көрәш һәм социалистик революция теорияләре буенча язу алга сөрелә башлый. Большевиклар тарафыннан күпләп оештырылган, этник нигезен төрки халыклар тәшкил иткән союздаш һәм автоном республикаларда, өлкәләрдә тагын бер кызыклы күренеш күзәтелә. С.Г. Кляшторный бик хаклы ассызыклаганча, «Башта пантюркизм идеяләренә каршы буларак табигый рәвештә барлыкка килгән автохтон концепция Урта Азиядә һәм Идел-Урал төбәгендә «милли бүлгәләнүнең» табигый дәвамы, нәтиҗәсе була. Нәкъ менә шушы концепция бу төбәкләрдә яшәгән һәр халыкның тарихын аеру, төбәкара тарихи процессларны «милли агымнарга» бүләр өчен, милли тарихны халыклар бүген биләгән җирләр белән бәйләү өчен идеологик нигезгә әйләнә» [Кляшторный, 2006, с. 13]. Тарихтагы уртак тамырларны һәм охшашлыкны юкка чыгару өчен, татар халкы тарихын республика чикләреннән чыкмыйча, биредә яшәүче башка халыкларныкы белән бергә өйрәнү мәҗбүр итеп куела. Автохтон концепциянең ТАССРда «тамырлануы» «Татарны өйрәнү фәнни җәмгыяте»н (1923–1931) алыштырырга тиеш булган һәм Совет халык комиссариаты 1928 ел 10 июль карары нигезендә Татарстанны өйрәнү үзәге оешуда чагылыш таба. Аның максаты итеп «һәрьяктан Татарстанның табигатен, халкын, аның тормыш-көнкүрешен, тарихын, мәдәниятен, җитештерү көчләрен» өйрәнү билгеләнә. Шулай итеп, татар халкының тарихын һәм мәдәниятен фәнни тикшерүләр ТАССР, Казан губернасы чикләренә урнаштырыла.

КПСС Үзәк комитетының 1944 ел 9 август карары, татар галимнәренең «Идегәй» дастанын өйрәнүе мисалында, фәнни җәмәгатьчелекне Алтын Урда тарихын идеаллаштыруда, милләтчелектә гаепләгән була, шул сәбәпле һәм автохтон концепция нигезендә, Евразия дәүләте булган Алтын Урда мирасыннан йөз чөереп, Идел буе болгарлары тарихын өйрәнүгә игътибар арта.

Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институты тарихчылары тарафыннан әзерләнгән һәм 1951, 1955, 1960, 1968, 1973, 1980 елларда дөнья күргән «ТАССР тарихы» китабы әлеге автохтон концепция нигезендә эшләнде. Урта Идел төбәге, ТАССРның чикләре борынгы күчмәннәр яшәгән җирләрнең читенә туры килү сәбәпле, борынгы төрки чор әлеге китапларда чагылыш тапмады, Алтын Урда чоры Болгар дәүләте чикләрендә генә өйрәнелде.

1980 нче елларда Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих институты дүрт томлык «Татарстан тарихы» язу эшен башлап җибәрде. 1989 елда Институтның тарих бүлеге алдына «Татар халкы тарихы» исемле күмәк хезмәт язу бурычы куелды. 4 томлык хезмәтнең беренче ике томы «Татар халкы тарихы буенча очерклар» исеме белән бастыруга әзерләнде, ләкин дөнья күрми калды. Аның өчен дип җыелган бер бәйләм фәнни мәкаләләр «Материалы по истории татарского народа» (Казань, 1995) исемле баш астында дөнья күрде.

Илдә башланган демократик үзгәрешләр, сүз һәм фикер иреге, КПССның дәүләти статусы үзгәрү һәр республикада сәяси активлыкка, милли һәм мәдәни яңарышка, үсешкә юл ачты. 1991 елда Татарстанда Фәннәр академиясе оешты, 1994 елда Татар энциклопедиясе институты барлыкка килде, һәм ул яңа бер юнәлешне алып китте. 1996 елда Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан аерылып чыгып оешкан Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының төп максаты итеп тарихи дөреслекне чагылдырган җиде томлык татар тарихын язу билгеләнде.

Бу елларда Россия тарих фәне идеологик һәм теоретик мәсьәләләрдә торгынлыкка керде. Галимнәр, марксистик-ленинчыл концепциядән баш тартып, сыйныфлар көрәше тарихны алга этәрүче төп көч дигән кагыйдәне танымый башлады. Бу күренешләр Татарстанга да хас иделәр. Иң мөһиме – демократия казанышлары һәм Татарстанның суверенитет юлыннан атлавы бу проектка һәм фәнни, һәм иҗтимагый, һәм сәяси төсмер бирде. Шулай итеп, илгә килгән хөррияттне Татарстанда гуманитар өлкәдә эшләүче галимнәр нәтиҗәле файдаландылар. Китаплар совет елларында күнегелгән цензура күзәтүе астында эшләнмәде. Хезмәтнең үзәгенә фәннилек куелды. Иң яхшы белгечләрне җәлеп итү, мәкаләләрне фәндәге соңгы ачышларны күздә тотып, булган табышларга нәтиҗә ясап эшләү томнарны төрле өлкәләрендәге фәнни казанышларны исәпкә алып башкарырга мөмкинлек бирде. Көчләп тагылган автохтон концепциядән баш тарту милли тарихны Евразия масштабында өйрәнүгә юл ачты. Бу яңалык Казанда революциягә кадәр формалашкан һәм 1920 елларда яңа сулыш алган татар милли историографиясе традицияләрен тергезде һәм нәтиҗәдә Евразиядә көн итүче татарлар тарихы язылды.

Географик кысаларны киңәйтү методологик үзгәрешләргә һәм фәнни оештыруда күп яңалыкларга китерде. Евразия киңлекләренә чыккач, Россиядәге һәм чит илләрдәге фәнни үзәкләр, галимнәр белән хезмәттәшлек итмичә, мондый масштаблы проектны тормышка ашырырга мөмкин түгеллеге ачыкланды. Моңарчы күбрәк Урта Идел буеның үткәнен өйрәнгән Татарстан тарихчылары Россия һәм чит илдәге коллегаларын хезмәттәшлеккә чакырдылар. Иң яхшы белгечләр катнашындагы шушындый фәнни кооперация томнарны уңышлы башкарып чыгарга нигез булды.

Борынгы һәм урта гасырлар тарихын язганда игътибар үзәгенә милли дәүләтчелек институтлары куелды. Шуңа 1, 2, 3, 4 томнарны, галимнәр коллективлары җәлеп итеп, эзлекле рәвештә хуннардан алып Россиягә кушылганчыга кадәрге чорга кадәр төрки-татар дәүләтләре тарихын язуның беренче тәҗрибәсе дип атарга мөмкин. Биредә сәяси тарих, милли дәүләтчелек һәм аның традицияләре, идарәчеләре, Евразиядәге халыкара мөнәсәбәтләр, халыкларның социаль халәте, көнкүреше, икътисади үсеше, мәдәнияте һәм башка темалар яктыртылды. Академик хезмәтнең беренче томының фәнни редакторы С.Г. Кляшторный китапка керешендә болай дип язды: «Төрки кабиләләрнең V–X гасырларда Үзәк Азиядән көнбатышка күчеше Евразия киңлекләрендә кимендә ике хәрби-сәяси союз оештыру тәҗрибәсен бирде: V–X гасырларда угыр һәм төркиләр союзы, XIII–XV гасырларда монголлар һәм төркиләр союзы» [Кляшторный, 2002, с. 14]. Аның сүзен дәвам итеп, XVI гасырның икенче яртысыннан башлап Россиянең этник нигезен рус һәм төркиләр тәшкил иткәнен искәртәсе килә. Бу барышның барлык этапларында да төркиләр, татарлар дәүләт төзүче этнос, халык буларак катнашалар. Киңрәк фикерләгәндә, академик хезмәтнең бу томнары ил тарихының кайбер мөһим күренешләрен яңача шәрехли.

Россиягә кушылганнан соңгы вакыйгалар (5 һәм 6 нчы томнар) цивилизацион карашны өстенлекле итеп кую нигездә өйрәнелде һәм язылды. Узган заман вакыйгаларына мондый караш татарларның социаль тормышын, иҗтимагый фикер үсешен, мәдәни барышын, ут күрше булып гомер итүче халыкларның үзара файдалы бәйләнешләрын, бер-берсенең хуҗалык тормышын һәм мәдәниятләрен баету тәҗрибәсен, татарларның төрки халыклар тарихында һәм ислам дини фикере үсешенә керткән өлешләрен ачыкларга, татар милләте формалашу үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирде.

Соңгы, җиденче томны ТАССРны һәм Татарстан республикасын үзәккә куеп язу, беренче тапкыр буларак, монографик планда ике республиканың тарихын дәвамлы яктыртырга мөмкинлек тудырды.

Шулай итеп, академик хезмәтне дәүләтчелек һәм цивилизацион караштан чыгып язу этносның Евразиядә, Россиядә үткәне, төрки һәм мөселман дөньясында тоткан урыны турында яңа сүз әйтергә юл ачты.

Китапларны әзерләүдә тарихчылар, археологлар, этнографлар, текстологлар, нумизматлар, картографлар, телчеләр, әдәбиятчылар, сәнгать белгечләре, архитекторлар, музей хезмәткәрләре һәм тагын кайбер тармак галимнәре катнашты. Һәр томның структурасы редколлегиягә яңа бурычлар куйды, аларны башкарып чыгу өчен махсус рәвештә яңа темаларны һәм чыганакларны барлау кирәк булды, чөнки шул яңа сюжетлар һәм материаллар томнарны тулы канлы фәнни хезмәтләр ясап чыгарырга, татар тарихын һәм мәдәниятен

комплекслы өйрәнергә мөмкинлек бирде.

В 1998 елның сентябрендә Институтта урта гасылар тарихы бүлеге оешты, безнең бүлектә 1999–2012 елларда җидетомлыкның дүрт китабы – 1, 2, 3 һәм 6 нчы томнары әзерләнде. Проектның баш редакторлары Р.С. Хәкимов һәм М.Г. Госманов фатихасы белән мин 1999 елда 1 нче томның җаваплы сәркатибе сыйфатында Петербургта Көнчыгышны өйрәнү институты филиалының тюркология һәм монголистика секторы җитәкчесе С.Г. Кляшторный белән очраштым. Шул вакыттан эш башланып китте. Мин, шулай ук, 2 нче томның җаваплы редактор урынбасары (2003–2005) һәм 6 нчы томның фәнни редакторы (2008–2012) сыйфатында академик хезмәтне әзерләүдә катнаштым.

Санкт-Петербург фәнни мәктәбенең күренекле вәкиле С.Г. Кляшторный белән хезмәттәшлек академик басманы эшләү методикасын булдырырга ярдәм итте. Галим мөһим фәнни темалар буенча махсус рәвештә конференция-семинарлар уткәреп кенә калмады, аларны фәнни редакторның һәм авторларның үзара аралашу, фикерләшү һәм язган текстларны тикшерү урынына әверелдерде.

2003 елның 5 маенда Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты бинасында Татарстан Президенты М.Ш. Шәймиев катнашында тәкъдир ителгән 1 нче томның структурасы башка томнарны язганда үрнәк булды. Томнарның төзелеше түбәндәгечә: фәнни җитәкченең «Кереш сүзе»; тарихи чыганакларны һәм әдәбиятны анализлаган мәкаләләр; авторлар биргән рәсем-схемалар белән баетылган фәнни мәкаләләр; йомгак, кушымта – тарихи чыганаклардан өзекләр; файдаланылган чыганаклар һәм әдәбият исемлеге һәм күрсәткечләр (географик, сәяси, этник терминнар һ.б.).

Һәр хезмәтнең урыны фән үсешенә керткән яңалыгы белән билгеләнә. «Бик борынгы заманнан башлап татар тарихы»ның яңалыгы нидән гыйбарәт? Бу сорауга җавап йөзеннән һәр томны күздән кичерик.

1 нче том [История татар..., т. 1] халкыбызның борынгы төрки тамырларын барлый, күчмәннәр цивилизациясенең төп билгеләре, хуҗалык тормышы, дәүләтчелек институтлары белән таныштыра, ул заманда Евразияне хуҗалык итү ягыннан фәкать күчмәннәр генә үзләштерә алуын искәртә, аларның Көнчыгыш белән Көнбатышны тоташтыручылар булуын һәм, гомумән, дөнья үсешенә керткән рольләрен билгели.

«Идел буе Болгар дәүләре һәм Бөек Дала» дип исемләнгән 2 нче том [История татар..., т. 2] Идел буе Болгар дәүләте, аның халкы һәм мәдәнияте буенча берничә буын археологлар һәм тарихчылар бөртекләп туплаган тарихи мәгълүматларны системага салып, иң соңгы фәнни ачышларга нигезләнеп язылды. Көнбатыш Европаның бу дәүләтеннән тыш, китапта Хәзәр каһанлыгының, Бөек Болгар дәүләтенең, Дунай Болгарстанының, күчмәннәрнең,

Төнья Кавказдагы, Себердәге төркиләрнең сәяси, икътисади, социаль тарихы яктыртыла, ислам цивилизациясенең Урта Иделгә таралуы ассызыклана.

Алтын Урда турындагы 3 нче том [История татар..., т. 3] Россиядә шушы мәшһүр дәүләткә багышланган беренче академик хезмәт язу тәҗрибәсе буларак бәяләнергә хаклы. Җучи Олысының барлыкка килү, чәчәк ату һәм таралуы киң тарихи панорамада бирелә һәм бик тәфсилләп (дәүләтнең хакимият институтлары, административ идарә структурасы, хәрби сәнгате, эчке һәм тышкы сәясәте, шәһәрләре, халыкларның хуҗалык строе, мәдәнияте) бәян ителә. Шуларга йомгак рәвешендә «Алтын Урда цивилизациясе» дигән төшенчә кертелә.

4 нче томда [История татар..., т. 4] Алтын Урда варислары буларак халыкара мәйданда аваз салган төрки-татар дәүләтләре (Кырым, Казан, Төмән/Себер, Әстерхан ханлыклары, Нугай Урдасы, Касыйм йорты) бер иҗтимагый-сәяси күренеш итеп карала, шул ук вакытта аларның һәрберсенең сәяси тарихы, төрки-татар этносларының оешуы хакында языла.

Шулай ук 2015 елда басылып чыккан 5 нче том [История татар..., т. 5] хронологик яктан XVI гасырның уртасын – XVIII йөзне үз эченә ала. Ят телле, динле һәм гадәтле дәүләттә яши башлау татарлар өчен зур сынау була. Китапта халкыбызның шушы зур авырлык белән барган, канкойкыч баш күтәрүләр чиратлашкан, яңа хакимияткә, яңа тәртипләргә ияләнү процессы тасвирлана, төрле социаль катлам вәкилләренең хокукый хәле, аларның ил социаль тормышында катнашу дәрәҗәләре ачыклана, татарларда икътисад үсеше, милли мәдәниятнең халәте хакында сүз алып барыла.

2013 елда басылган 6 нчы томда [История татар..., т. 6] ил буйлап чәчелеп көн күрүче татарларның хуҗалык итүе һәм социаль халәте, аларның төп сословие-социаль төркемнәренең хокуклары анализлана, комплекслы рәвештә мөселман һәм православие дини институтларының хокукый хәле, үсеш үзенчәлекләре яктыртыла. Мөселман милләте формалашу һәм бу барышта татар элита вәкилләренең роле һәм Мәхкамәи Шәргыя Ырынбургияның урыны билгеләнә. Томның иң зур бүлеге мәдәният үсешенә багышланган – биредә мәдәни процесслар аша татар милләте оешу идеологиясе яктыртыла.

7 нче том [История татар..., т. 7], иҗтимагый-сәяси күренешләргә зур игътибар биреп, катлаулы өч тарихи чорда татар халкының тарихын яктырта: XX гасыр башы, ТАССР яшәгән 1920–1992 еллар һәм Татарстан Республикасы һәм бу елларда татар дөньясы.

Йомгаклап әйткәндә, җиде томлык «Бик борынгы заманнан башлап татар тарихы» – берничә буын татар галимнәре һәм төрки-татар мәсьәләсе белән шөгыльләнгән һәм шөгыльләнүче Россия, чит илләрдәге коллегаларыбызның күмәк фәнни хезмәте җимеше. Әлбәттә, томнарда җитешсезлекләр, кимчелекләр, хаталар да юк түгел.

Илдәге яңа иҗтимагый-сәяси шартлардан файдаланып, бу проектны безнең буын тарихчыларга тормышка ашырырга насыйп булды. Иң мөһим нәтиҗә – губерна дигән төбәкчелек тарихын атлап чыгып, Евразия күләмендәге татар тарихы язылды һәм киләчәккә татарны өйрәнү фәненең үсеш перспективалары билгеләнде.

Җиңүче халык гына үз тарихын яза, дигән гыйбарә бар. Зыялыларыбызның хыялы, ниһаять, тормышка ашты – фидакяр галимнәребез көче белән милли тарихыбыз язылды. Алга карап фикер йөрткәндә, татар милләтенең киләчәк тарихын язу безнең барыбыздан тора, дип әйтәсе килә.

**Әдәбият**

*Абдрашитова И.М.* Из истории Научного общества татароведения (1923–1929 гг.) // Ученые записки Казанского государственного педагогического института. Вып. 150. Сб. 7. Казань, 1975. С. 101–111.

*Акчура Й.* Мәдрәсәләрдә тарих дәресе укыту турында // Чын мирас. 2012. № 7. Б. 39–41.

История татар с древнейших времен. В 7 томах. Т. 1. Народы степной Евразии в древности / науч. редактор С.Г. Кляшторный. Казань: Рухият, 2002. 551 с.

История татар с древнейших времен. В 7 томах. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь / отв. ред. Ф. Хузин. Казань: РухИЛ, 2006. 959 с.

История татар с древнейших времен. В 7 томах. Т. 3. Улус Джучи (Золотая Орда). XIII–XV вв. / науч. редактор М. Усманов. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2009. 1155 с.

История татар с древнейших времен. В 7 томах. Т. 4. Татарские государства XV–XVIII вв. / науч. редакторы И. Гилязов, Б. Измайлов. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – 1180 с.

История татар с древнейших времен. В 7 томах. Т. 5. Татарский народ в составе Русского государства (вторая полвина XVI–XVIII в.) / науч. редактор И. Миргалеев. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. 1031 с.

История татар с древнейших времен. В 7 томах. Т. 6. Формирование татарской нации XIX – начало XX в.) / науч. редактор И. Загидуллин. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2013. 1171 с.

История татар с древнейших времен. В 7 томах. Т. 7. Татары и Татарстан в XX – начале XXI в. / науч. редактор Р. Салихов. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2013. 1007 с.

*Кляшторный С.Г.* Предисловие // Кляшторный С.Г. Памятники девнетюркской письменности и этнокультурная история Центральной Азии. СПб.: Наука, 2006. С. 5–34.

*Кляшторный С.Г.* Предисловие к тому // История татар с древнейших времен. В 7 томах. Т. 1. Народы степной Евразии в древности / науч. редактор С.Г. Кляшторный. Казань: Рухият, 2002. С. 12–16.

***Илдус Котдус улы Заһидуллин,***
*тарих фәннәре докторы, Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының Яңа тарих бүлеге мөдире*

*А.М. Ахунов*

## МӨСЕЛМАН ПЕТЕРБУРГЫНА СӘЯХӘТ

Россия тарихы мөселман халыкларының үткәне белән бәйле күп төрле мөһим вакыйгаларга бай. Татищев белән Карамзин заманыннан соң алар хакындагы киң планда тикшеренүчеләр аз булгандыр, һәм алар фәнни әйләнешкә дә кертелмәгән.

Әлбәттә, болар хакында яздылар да, сөйләделәр дә, тик алар Кавказга һәм Төркестанга булган буйсындыру, яулап алу походлары белән бәйләп күтәрелде. Ил-көн тыныч вакытта Россия мөселманнары тормышы, миссионерлар, этнографлар һәм Көнчыгышны өйрәнүче белгечләрдән башка, беркемне дә кызыксындырмагандыр. Аларның да китаплары киң катлау публика өчен түгел, ә үз коллегалары – белгечләр төркеменә генә юнәлгән була.

XIX гасырның беренче яртысында А.С. Пушкинның «Подражание Корану», Барон Бранбеусның (О.И. Сеньковский) «Восточные повести» кебек француз әдәбияты йогынтысында кабынып киткән көнчыгышка иярү модасы бик тиз юкка чыга. Россиянең гади халкы үз янәшәсендә гомер кичерүче Мөхәммәт өммәте тарафдарлары хакында бик аз белә. Руслар – үз тормышы, татарлар үз тормышы белән яши. Инглиз язучысы Редьярд Киплинг бик хаклы рәвештә болай дип язган: «Запад есть Запад, Восток есть Восток, и вместе им никогда не сойтись». Ә бит 1917 елда Россия империясендә мөселманнар саны 20 миллион исәпләнә.

Тик Россиянең үз «Көнчыгышы» була. Хәтта, Манчестер университеты профессоры В. Тольц махсус термин тәкъдим итә – «Собственный Восток России» [Тольц]. «Мусульманский Петербург: исторический путеводитель» дип исемләнгән яңа китап нәкъ менә шундый «Россиянең үз Көнчыгышына» багышланган.

Зур күләмле, иллюстрацияләргә бай бу басма ике авторның – ислам белгече, икътисад фәннәре докторы, РФА Африка институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Р.И. Беккин белән Петербургны өйрәнүче А.Н. Таһирҗанованың озак елар дәвамындагы җентекле хезмәтләренең нәтиҗәсе. Алар икесе дә Санкт-Петербургта туып үскәннәр һәм шунда гомер кичерәләр, ә бу китап Нева буендагы шәһәрнең формалашуына һәм гөрләп үсеп китүенә шактый өлеш керткән мөселман ата-бабалары истәлегенә хөрмәт билгесе.

Юлкүрсәткеч буларак, бу басма тиешле кагыйдәләргә нигезләнеп төзелгән. Анда бүлекләр, параграфлар юк, алар урынына авторлар шәһәр буйлап маршрутлар тәкъдим итәләр. Маршрутлар өч өлешкә бүленгән: «Санкт-Петербург», «Отдельные примечательные объекты, не вошедшие в маршруты», «Пригроды Петербурга и Ленинградская область».

Авторлар китапның кереш өлешендә билгеләп үткәнчә, басмада күрсәтелгән маршрутлар биналар түгел, ә аерым хөрмәткә лаек шәхесләр белән бәйле. «С Петербургом связаны биографии многих выдающихся российских деятелей-мусульман по вероисповеданию: ученых, зодчих, врачей, военных, купцов-меценатов и др. В городе на Неве проходили мусульманские съезды, печатались мусульманские газеты, работали мусульманские общественные и религиозные организации. И все это оказывало влияние на жизнь не только петербургаских мусульман, но и их единоверцев, проживавших в других частях империи», – дип яза китап авторларының берсе – Р. Беккин.

Петербургта мөселманнар XVIII гасыр башыннан яшиләр, алар шәһәренең тарихын һәм мәдәни йөзен формалаштыруга петербурглылар беррәттән өлеш кертkәннәр. Шуны истә тоту мөһим: XIX гасыр ахырында татар җәмәгатьчелегендә, аеруча аның зыялылары арасында, рус мәдәнияте белән кызыксыну көчәя. Татарлар рус телен һәм әдәбиятын өйрәнә башлыйлар, рус китапларын һәм журналларын укыйлар, рус театрларына йөриләр. Әмма бу, алар үз туган телләрен, татар мәдәниятен оныталар, аннан читләшәләр, дигән сүз түгел. Петербург мисалында без татар-мөселманнарның шәһәр тормышына табигый кушылып китә алуларын ачык күрәбез.

Маршрут № 1 Петроград ягы буйлап сузылган. Анда йөргәндә, без Петербургның беренче төзүчеләре 1695–1696 елларда Петер I нең Азовка походы вакытында әсир төшкән төркиләр икәнен беләбез. Төньяк башкала төзелешенә соңрак Россия мөселманнарын – нигездә татар крестьяннарын һәм бистә кешеләрен дә тарталар, алар анда салкыннан, ачлыктан һәм гадәттән тыш авыр яшәү шартларыннан меңәрләп кырылалар. Тора-бара алар Петербургның дымлы, юеш климатына ияләшәләр, шәһәрдә яшәп кала башлыйлар һәм хәтта үзләренең Татар бистәсен нигезлиләр. Вакытлар узу белән ул бистә юкка чыга, аның кайчандыр булганлыгын фәкать Татар тыкрыгы (Татарский переулок) гына хәтерләтә.

Монда сүз шулай ук Россиядәге иң матур төзелешле мөселман гыйбадәтханәсе – Петербургта 1913 елда ачылган Җәмигъ мәчете турында бара, аның төзелешенә өлеш керткән архитекторлар, финанс ярдәме күрсәткән меценатлар, гомумән шәһәрнең бу өлеше белән бәйле күренекле мөселманнар турында әйтелә.

Маршрут № 2 Нева проспектын һәм аңа тоташкан урамнарны колачлый.

Монда да Россия империясе мөселманнары тормышы белән бәйле күп урыннар сакланган. Мәсәлән, «Октябрьская» кунакханәсе шуның белән кызыклы, анда чирек гасыр дәвамында рус гаскәрләре белән сугыш алып барган Дагыстан белән Чечня имамы Шамил тукталган булган. 1859 елда ул әсирлеккә алына һәм Тверьгә сөргенгә җибәрелә. Шул юлында ул Петербургка килә һәм шәһәрдә шау-шу

кузгала. Барысы да Төньяк Кавказ халыклары башлыгын күрергә телиләр. Халыкны алдауның үзенә бер төре барлыкка килә: спекулянтлар театрның барлык билетларын да алдан сатып алып, кич спектакльдә имам Шамил үзе булачак, дигән сүз тараталар. Публика театр кассаларына ташлана, әмма анда билетлар булмый. Аларны өч тапкырга артык бәя белән сатып алудан башка чара калмый. Һәм, әлбәттә инде, Шамил театрга килми.

Мойка елгасы ярындагы йортларның берсендә Петербург татарлары арасында танылган дин галиме җәмәгать эшлеклесе Гатаулла Баязитовның фатиры урнашкан булган. Соңыннан шушы ук йортта электрга көйләнгән басу җайланмасы да урнаштырыла, анда 1905 елда татар телендәге беренче «Нур» газетасы басылып чыга.

Г. Баязитов иҗтимагый өлкәдә генә түгел, дини тәгълиматчы-теоретик сыйфатында да зур абруйга ия була. 1880–1890 елларда язган һәм Россияда, кайбер чит илләрдә дә (аның китапларының кайберләре төрек һәм француз телләренә тәрҗемә ителә) зур бәя алган хезмәтләре аңа киң танылу китерә. Аның «Возражение на речь Эрнеста Ренана» (СПб., 1883) хезмәте аеруча хуплау таба, анда автор күренекле француз галиме Э. Ренанның, ислам белән төгәл фәннәр яраклаша алмый, дигән төп идеяләренә каршы чыга.

Маршрут № 3 «Район пяти углов – мусульманский квартал Петербурга» дип атала. Биш почмак районы һәм килеп тоташкан урамнар XIX гасыр урталарына кадәр татарлар тупланып яшәгән урын була. Нәкъ менә шунда К. Заслонова (элекке Глазовая) урамында «Өлфәт» татар газетасы редакциясе урнаша (әмма ул, хөкүмәтне тәнкыйтьләгән өчен, 1907 елда ябыла). Аның баш мөхәррире татарның күренекле җәмәгать һәм дин эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимов була, соңыннан ул эмиграциягә китә, Япониядә мөселманнар җәмгыятенең җитәкчесе була.

Маршрут № 4 Кышкы сарайдан башлап, Россиянең дәүләт эшлеклесе, дипломат, галим, чыгышы белән борынгы татар нәселенә барып тоташкан Дмитрий Кантемир (1673–1723) резиденциясенә кадәрге мәйданны били. Гаҗәеп мөһим вакыйгаларга бай Д. Кантемир язмышы детектив романнарда урын алырлык, аның төп борылышлары «Путеводитель»дә дә чагылыш тапкан.

1762–1904 елларда Кышкы сарай Россия патшаларының рәсми резиденциясе булып саналган. Сарай хезмәткәрләренең шактый өлешен (100 ләп кешене) татарлар тәшкил итүен белүчеләр, мөгаен, бик аздыр әле. Сафиулла Бурнашев, мәсәлән, Николай II нең кучеры булган, ә аның улы – Вәли соңрак В.И. Ленинның шәхси шоферы хезмәтен үтәгән.

Китаптагы һәм машрут тематика буенча төзелгән. Алда әйтеп үтелгәнчә, анда авторлар йортларны яки урамнарны тасвирлау бурычын куймаганнар. Алар игътибарының төп объекты – шәхесләр һәм алар белән бәйле вакыйгалар.

Мәсәлән, маршрут № 5 мәгариф, фән һәм белем бирү темасына багышланган. Анда без Кырым-татар мәгърифәтчесе Ильяс-морза Бораганский типографиясе турында белә алабыз. Мөселман типографияләренең беренчеләреннән булган бу басмаханәне Ильяс-морза Петербургта 1893 елда ачкан. Фәннәр академиясе типографиясе хакындагы мәгълүматлар да кызыклы, анда императрица Екатерина II әмере белән 1787 елда Россиядә беренче тапкыр гарәп графикасы нигезендә Коръән басылган.

Маршрут №6 безне шәһәрдәге мөселман җәмгыятенең күренекле затлары – дин галиме Муса Бигиев һәм җәмәгать эшлеклесе Әминә Сыртланова белән бәйле урыннарга алып бара. М. Бигиев, танылган дини реформатор буларак кына түгел, Коръәнне яхшы сыйфатлы итеп татар теленә беренче булып тәрҗемә итүе (ул аны 1912 елда тәмамлый) белән дә тарихка кергән шәхес. Аның тәрҗемәсе эшләнеп беткәч, Корънәнең бу тексты типографик ысул белән җыела да. Әмма мондый басманың ислам канунннарына туры килү-килмәве хакында татар матбугатында көчле бәхәсләр башлана һәм М. Бигиев тәрҗемәсен бастырып чыгару тыела. Диния нәзарәтенә күп кенә шикаятьләр килә. Болардан тыш, Изге китапны бөтен мәгънәсе һәм тирәнлеге белән бирү өчен әлегә татар теленең байлыгы җитми, дигән нәтиҗә ясала.

Бу маршрут Дәүләт Думасы утырышлары уздырылган Таврический сарай турындагы мәгълүматлар белән тәмамлана. Ул утырышларда мөселман депутатлар да актив катнашкан, алар гаять зур Россия империясенедә яшәүче диндәшләренең мәнфәгатьләрен яклаганнар.

Китапның беренче өлешендә (кисәгендә) барлыгы сигез маршрут бирелгән. Юлкүрсәткеч авторлары ашыкмый гына, аерым игътибарга лаек объектлар янына туктый-туктый, безне Төньяк башкаланың төз урамнары һәм проспектлары буйлап алып баралар, элек шул урыннарда гомер кичергән күренекле мөселманнарның язмышларына бәйле вакыйгалар белән таныштыралар. Алар Санкт-Петербургның сәяси вакыйгалар кайнап торган агымы контекстында тыныч кына көн күргән башка чынбарлыкны ачып бирәләр. Авторлар биредә Петербургның дөньяви реаль җәмгыять шартларындагы мөселман дөньясының кайнап торган тулы тормышына яшерен юл ачалар.

Китапның моннан соңгы өлешләрендә дә без чүпрәкче һәм асламчы татарларының иске-москы белән алу-сату базарын үз кулларында тотуы (монополияләштерүе) хакындагы кызыклы күренешләр белән танышабыз. Көндәлек тормышта ул базарчыларны «кенәзләр» дип атаганнар. Санкт-Петербургтагы күп кенә затлы рестораннарның да хуҗалары татар-мөселманнар икәнлеген күпләр белмидер әле (үзләре кулланмасалар да,алар шәраб белән сату иткәннәр). Төньяк-көнбатыштагы тимер юл станцияләренең күбесендә эшләгән буфетлар да татарларныкы булган.

Болары түбән катлау. Шәһәр мөселманнарының югары катлау вәкилләрен күренекле татар генераллары, дәүләт Думасы депутатлары һәм иң югары дәрәҗәдәге чиновниклар тәшкил иткән. Юлкүрсәткечтә алар турында да мәгълүматлар бар.

Петербургның мөселман зираты хакында да авторлар укучы өчен җентекле өйрәнелгән материал тәкъдим итәләр. Гомумән, китапта китерелгән барлык мәгълүматларның да сыйфатына һәм дөреслегенә шик юк. Алар архивларда берничә елларга сузылган эзләнүләр, тупланган фактларның дөреслеген әллә ничә чыганаклар буенча кабат-кабат тикшерүләр нәтиҗәсе.

Китап туган якны өйрәнүчеләр һәм Петербург тарихы белән кызыксынучылар өчен генә түгел, бүгенге кебек үк күп милләтле һәм күпконфессияле ил – Россия империясенең үткәнен белергә теләгәннәр өчен дә файдалы булачак. Андагы фактлар һәм вакыйгаларның күпчелеге фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелгән. Рецензияләнгән китап үзенең утилитар максатыннан бик ерак тора. Авторның фәнни эзләнүләре нәтиҗәсе буларак, бу басма XVIII–XX гасыр башында Санкт-Петербургта руслар арасында гомер иткән мөселманнарны, аларның тарихын, мәдәниятен, дини йолаларын, типографияләрен һәм көнкүрешен өйрәнү өчен дә мөстәкыйль чыганак һәм менә дигән юлкүрсәткеч булып хезмәт итә ала.

Кайбер архив материаллары кушымтада иллюстрацияләр рәвешендә бирелгән. Шунда ук иске һәм аңлашылып бетми торган сүзләр һәм терминнар сүзлеге урнаштырылган. Китап җиңел әдәби тел белән язылган, яхшы укыла. Мөселман Петербургы буйлап юл күрсәтүче бу яңа басма илебез тарихына багышланган китап киштәләребездә лаеклы урынын биләр, дип ышанып калабыз.

**Әдәбият**

*Беккин Р.И., Тагирджанова А.Н.* Мусульманский Петербург. Исторический путеводитель. Жизнь мусульман в городе на Неве и в его окрестностях / Р.И. Беккин, А.Н. Тагирджанова. М. – СПб.: Институт Африки РАН; 2016. 640 с.: илл.

*Тольц В.* «Собственный Восток России»: политика идентичности и востоковедение в позднеимперской и раннесоветский период. М.: Новое литературное обозрение, 2013. 332 с.

***Ахунов Азат Марс улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты Халыкара багланышлар,*
*тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институтының*
*Көнчыгышны, Африканы һәм Исламны өйрәнү кафедрасы доценты*

**2016 елның 14-15 июлендә** күренекле филолог, китап белеме галиме, публицист, ТР ФА академигы Әбрар Кәримуллинның (1925–2000) якты истәлегенә багышланган V нче мемориаль Ә.Г. Кәримуллин укулары оештырылды. Укуларда Беларусь, Литва, Казакъстан, Төркия кебек чит илләрдән дә галимнәр катнашты. Милли китапчылык эшенең тарихы һәм хәзерге проблемалары турындагы әлеге гыйльми чараның беренче көне ТР Милли китапханәсендә узды. Икенче көне Саба районында һәм Әбрар Кәримуллинның туган авылы Чәбия-Чүрчидә дәвам итте. Кунаклар галимнең каберен зиярәт кылды, туган нигезе белән танышты. Авыл мәдәният йортында аның турында истәлек-хатирәләрне яңарткан матур очрашу да булды.

**21 сентябрьдә** Казан федераль университетында «Киләчәк фәне – яшьләр фәне» II Бөтенроссия фәнни форумы кысаларында «ЕАИБ илләре яшь галимнәренең фәнни-технология элемтәләрен киңәйтү һәм торгызу» темасына түгәрәк өстәл булып узды. Түгәрәк өстәл эшендә ТР ФА вице-президенты Айрат Абдуллин, ТР ФА Яшь галимнәр советы рәисе Мәдинә Сибгатуллина, ТР ФА Яшь галимнәр советы рәисе урынбасары Тимур Девятков, ТР ФА әйдәп баручы белгече Булат Ногманов, ТР ФА Яшь галимнәр советы әгъзалары Айдар Хөсәенов һәм Алия Мөбәрәкшина, фәнни хезмәткәр Альбина Москвина, лаборант-тикшеренүче Нәргиз Айтуганова, өлкән фәнни хезмәткәр Татьяна Колцова, өлкән фәнни хезмәткәр Артур Шаһидуллин, фәнни хезмәткәр Диләрә Шәйморатова катнашты.

ТР ФА вице-президенты Айрат Абдуллин үзенең котлау сүзендә тәҗрибә алышу һәм фәнни казанышлар белән уртаклашу өчен төрле илләрнең яшь галимнәре арасында туры эшлекле элемтәләр урнаштыруның кирәклеген, мөһимлеген ассызыклады.

ТР ФА Яшь галимнәр советы рәисе Мәдинә Сибгатуллина ТР ФА яшь галимнәренең халыкара элемтәләр урнаштыру эшен киңәйтүдәге проблемалары хакында чыгыш ясады. Фәнни хезмәткәр Альбина Москвина Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтындагы татар-казах элемтәләренең фән, мәгариф, мәдәният өлкәсендәге яңа формалары, матур үрнәкләре турында сөйләде. Лаборант-тикшеренүче Нәргиз Айтуганова Халыкара археология мәктәбе эшен дөньяның яшь галимнәре фәнни хезмәттәшлегенең бер тәҗрибәсе мисалында күрсәтте.

Түгәрәк өстәл эшендә шулай ук РФА яшь галимнәре советы, Кыргыз-Россия славян университеты, КФУ, башка югары уку йорты вәкилләре «Киләчәк фәне – яшьләр фәне» II Бөтенроссия яшьләр фәнни форумында катнашучылар да бар иде. Мероприятиедә югары уку йортлары, академияләр арасындагы элемтәләрне активлаштыру, хезмәттәшлекнең актуаль формалары, Россиядә һәм ЕАИБ илләрендә фән һәм мәгариф өлкәсендәге бергәлекнең торышы һ.б. мәсьәләләр күтәрелде.

Түгәрәк эшен йомгаклап, ТР ФА һәм РФА яшь галимнәре арасында хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды.

**Татарстанда** рустелле балаларны татар теленә өйрәтү буенча яңа дәреслекләр эшләнә. Аның инде 1 сыйныфлар өчен беренче кисәге әзер дияргә була. «Әлеге дәреслекләр милли мәгариф үсеше концепциясе нигезендә төзелә. Без үз

алдыбызга татар теле дәресләрен кызыклы, эффектлы булуын максат итеп куябыз. Бу шулай ук укытучыларның әзерлеге һәм укыту-методик әсбапның сыйфатына да бәйле» – ди ТР МФМ министры урынбасары Илдар Мөхәммәтов. Аның сүзләре буенча, дәреслекләрдә әлегә кадәр грамматикага зур урын бирелде: «Без балаларга телнең төзелешен өйрәттек. Балаларга сөйләм телен өйрәтергә, коммуникатив башлангычның кирәклеге хакында күп сөйләнсә дә, болар бары сүздә генә кала килде. Яңа дәреслекләрдә дә грамматикага урын бирелә – аннан башка телне чынлап та өйрәнеп булмый». Яңа дәреслекләр 1 сыйныфтан башлап төзелә, киләсе яңа уку елына аларны тулы комплектлы итеп – дәреслек, эш дәфтәре, укытучы өчен ярдәмлек рәвешендә әзерләү планлаштырыла.

**2016 елның 15 июненнән** 26 июльгә кадәр Россиянең Чиләбе өлкәсендә Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган экспедиция эшләде. Өлкәнең 12 авылында (Чибәркүл районының Попов, Варлам авыллары, Чибәркүл шәһәре, Уй районының Әмин авылы, Нагайбәк районының Париж, Остроленко, Кассель авыллары) институтның фәнни хезмәткәрләре – тел, фольклор, сәнгать белгечләре тарафыннан шактый бай материал җыелды. Җирле халыкның тел үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, йолалары өйрәнелде; музыкаль фольклор үрнәкләре җыелды, кульъязма мирас һәм эпиграфик ядкәрләр тупланды. Институтның Кульъязма һәм музыкаль мирас үзәге кульъязма һәм басма китаплар белән баетылды. Алар арасында Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»се (4 китап), «Әмин авылы тарихы» кульъязма дәфтәре һ.б. бар.

Чиләбе өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез үз гореф-гадәтләрен, йолаларын, телен һәм динен саклап калырга тырышсалар да, бу мәсьәләне хәл итүдә шартлар тудырылмаган, мөмкинлекләр чикләнгән, шуңа күрә дә алар бездән ярдәм көтә.

Шундый характердагы икенче экспедиция Институт хезмәткәрләре тарафыннан 24 июньнән 5 июльгә кадәр Казакъстан республикасының Семипалат шәһәренә оештырылды. Җирле татарларның халык авыз иҗатына, тел-сөйләш үзенчәлекләренә, топонимия, археография һәм сәнгатенә кагылышлы материал тупланды. Сәфәр нәтиҗәләре яңа хезмәтләргә ныклы нигез булыр, дип ышанып калабыз, алар шулай ук Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплекслы экспедицияләр эшен яктырткан «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә дә урын алачак.

27 июньнән 10 июльгә кадәр Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәге, текстология, халык авыз иҗаты, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать, лексикология һәм диалектология бүлекләренең фәнни хезмәткәрләре катнашында Арча белән Әтнә районнарына комплекслы экспедиция оештырылды. Ике атна эчендә 33 авылда булып, әлеге районнар буенча шактый материал тупланды. Аеруча мөһим табылдыклардан XVIII–XIX гасырга караган мемуар характерындагы әсәрләр тупланган дәфтәрләрне, хатларны атарга мөмкин. Борынгы китапларның, шул исәптән Коръәннәрнең исемлеге булдырылды. Экспедиция нәтиҗәләре «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә аерым китап булып дөнья күрәчәк.

**20–21 сентябрьдә** ТР ФА яшь галимнәре Казан федераль университетында «Киләчәк фәне – яшьләр

фәне» II Бөтенроссия фәнни форумы кысаларында «Татарстан Республикасы фәнни яшьләре» – фәнни-инновацион эшләнмәләр күргәзмәсендә катнаштылар.

Күргәзмәдә ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, ТР ФА Киләчәккә юнәлгән икътисади тикшеренүләр институты, «Гамәли семиотика» фәнни-тикшеренү институты, Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре институты яшь галимнәре үзләренең эшләрен тәкъдим иттеләр.

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре Алия Мөбәрәкшина һәм Айгөл Әхмәтова татар филологиясе буенча яшь галимнәр тарафыннан язылган монографияләргә презентация ясадылар.

ТР ФА Киләчәккә юнәлгән икътисади тикшеренүләр институты өлкән фәнни хезмәткәре, т.ф.к. Тимур Девятков яшь галимнәрнең имитацион модельләштерү өлкәсендәге эшләнмәләрен – сәнәгать, транспорт, инфраструктур проектларда кулланырга мөмкин булачак үрнәкләрне күрсәтте.

ТР ФА «Гамәли семиотика» фәнни-тикшеренү институты өлкән фәнни хезмәткәре, т.ф.к. Айдар Хөсәенов яшь галимнәрнең татар сөйләмен автомат тану, текстны анализлау эшләнмәләрен тәкъдим итте. Шулай ук Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре институты яшь галимнәре Артур Шаһидуллин, Татьяна Кольцова, Светлана Валеева әйләнә-тирәне саклау, авыл хуҗалыгы берләшмәләренең органик продукция җитештерүгә әзерлеген бәяләү буенча башкарылган проектлары белән танышырга мөмкин булды.

Күргәзмәдә катнашучылар ТР ФАдә башкарылган тикшеренүләрнең реализацияләнү потенциалы югары булуын әйтеп үттеләр.

**Казан** (Идел буе) федераль университетының Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында берничә ел рәттән халык өчен түләүсез татар теле курслары оештырыла. Быел исә татар теле курсларына килүчеләр саны башка елларга караганда күбрәк булып, язылучылар 800 ләп кеше исәпләнелә.

Язылучыларның теләге – татар телен аралашу-аңлашу чарасы буларак үзләштерү, сөйләм күнекмәләренә ия булу, татар дөньясы турында мәгълүмат алу. Курсларга пенсионерлар да, төрле оешмаларда эшләүче урта яшьтәгеләр дә, югары уку йортларында белем алучы студентлар да, мәктәп укучылары да йөри. Аларны, белем дәрәҗәләреннән чыгып, төрле төркемнәргә бүләләр: башлап өйрәнүчеләр, дәвам итүчеләр һәм урта дәрәҗәдә белүчеләр. Рус һәм башка милләт вәкилләре белән беррәттән, курсларга йөрүчеләр арасында татарлар да шактый. Аларның теләге – туган телдә тагын да камилрәк сөйләшү, татар матбугаты язмаларын аңлап уку, татарча дөрес яза алу, татар халкының милли йолаларын, гореф-гадәтләрен үзләштерү. Быелгы курсларда Казахстан, Төркия, Кытай, АКШ, Мадагаскардан килгән студентлар да татар телен өйрәнүгә теләкләрен белдергән.

Курсларны уңышлы тәмамлаучыларга сертификат биреләчәк.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**
На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**
2016. № 3

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 29.09.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59, 292-71-80
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20